ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№1 (289) - ГЫЙНВАР 2016

ТАТАРСТАН

1920 елдан нәшер ителә

Мөфтигә төп ике сорау

Иң зур бәхет – эшләп тапкан бәхет

Аксыл костюмлы ялгыз джентльмен

2016: РЕСПУБЛИКА КӘЕФЕН БЕРГӘ КҮТӘРӘБЕЗ





16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары: Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com Рөстәм Шакиров
Чыгарылыш мөхәррирләре: Фәридә Әхмәтҗанова, Ольга Тюрина
«Икътисад» бүлеге мөхәррире: Владимир Матылицкий
«Мәдәният» бүлеге мөхәррире: Ольга Туманская
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская, bond@tatmedia.com
Авторлар: Юрий Алаев, Рөстәм Галиуллин, Татьяна Лескова, Владимир Мамонтов, Лилия Нурмөхәмматова, Василина Олейник, Айдар Сәгъдиев, Лариса Усманова, Айсылу Хаҗиева, Гадел Хәеров, Лилия Шәймиева
Фотографлар: Солтан Исхаков, Илдар Мөхәммәтҗанов, Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Производство бүлеге җитәкчесе: Виктор Шуматов, shumatov.tatarstan@tatmedia.com
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Виктор Шуматов, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Әхмәрова
Тышлыктагы фото: Александр Эшкинин

Журнал 1920 елдан нәшер ителә



1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ №ФС77-37630, 01.10.2009.

Тираж: **3500** данә, шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**:

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-80

Басарга кул куелды: 21.01.2016.

Маркетинг һәм дистрибуция::
Дарья Долгова, dolgovadv@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com, тел. (843) 222-09-76

Коммерция директоры урынбасары:
Айваз Диндаров, aivazid@tatmedia.com

Үсеш буенча директор:
Гөлназ Сабитова, gulnazas@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Юлия Фәсахова, тел. (843) 222-06-05

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

РЕСПУБЛИКА КӘЕФЕ

«Бу тормышта иң мөһиме – зарланмау», – дип саный көчле рухлылар һәм тормыш тәҗрибәсе булганнар. «Һәр нәрсәдә уңай якны күрә белү», – дип өстәп куя тормыштан тәм табып яшәүче оптимистлар. «Иң мөһиме – тынычлык һәм татулык», – дип, үзенең абруйлы сүзе белән йомгак ясап куя Президентыбыз. Югарыда искә алынган яхшы кәеф «ингредиентларының» файдалы булуы белән килешми мөмкин түгел. Чөнки хезмәт энтузиазмы белән тозланып, үткен акыл белән тиешенчә тәмләнгән, яхшылап болгатылган бу «ингредиентлар», ни кызганыч, бүгенге тынгысыз чорда күпләр тарафыннан онытыла язган уникаль рецептны тәшкил итә. Әйе, акча саллырак, доллар яшелрәк, нефть карарак, ә без үзебез яшьрәк чаклар бар иде… Ләкин, билгеле булганча, заманаңы сайлап булмый, димәк ки, узганнарны сагынып утырудан да мәгънә юк. Гади генә, әмма тәмле һәм файдалы «ингредиентлардан» һәр көн өчен яхшы кәеф тудырып, бүген һәм нәкъ менә биредә яшәргә кирәк. Зәвык-омтылышларыбыз гаять төрле булса да, соңгы нәтиҗә – муллык тойгысы һәм эшләргә теләк уятып торучы җылы бер хис – мөһим. Монда «продуктның» яңа булуында ялгышмаска һәм борычны артыграк салып ташламаска гына иде.

Ризыкны өстәлгә кайнар килеш бирергә.

2016 ЕЛ ӘЙЛӘНӘСЕ СЕЗГӘ КҮТӘРЕНКЕ КӘЕФ ЮЛДАШ БУЛСЫН!

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич



Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **73377** – татар телендә
Индекс **73947** – рус телендә

2016 елның 6 аена татар телендәге журналга язылу бәясе – **840 сум 00 тиен**

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР:

4 Татарстан-2015. Елның 10 күренекле вакыйгасы
6 2016: Президент фаразлары
8 Югары очышлы уңайлылык
14 Ике сеңел
16 Әгерҗе. Тамырлары һәм ябалдашы
22 Тизлеккә ашкыну
26 Ислам академиясе идеологик көрәш инструменты булачак
28 Пенсия яше турында тагын бер кат
38 Өлкәннәр нәсыйхәте
42 Ходай рәхмәте белән исән калдым…
44 Тормышның кадерен белегез!

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР:

48 «Альфа» туры юлга алып чыгармы?
50 WorldSkills: һөнәрилекнең алтын стандарты
54 Кайда алар хәзер?

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР:

58 Парк һәм андагы кешеләр
60 Аксыл костюмлы ялгыз джентльмен
64 Иң зур бәхет – эшләп тапкан бәхет
70 Затлылардан затлы – каз
74 Казан тарихының караңгы урыннарындагы ак таплар
78 Мин үсеп җиткәч
80 Сез кайсы дөньяда яшисез?
84 Торналар, торналар!
86 Афиша
88 Татарстан-2016. Үзгәрешләр өчьеллыгында

WWW.PROTATARSTAN.RU

Татарстан

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА



Республика тормышы турында

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Россиянең һәм БДБ илләренең иң яхшы төбәк аэропорты **КАЙДА**

Әгерҗе фермерлары **НИГӘ** курыкмый кризистан

Югары тизлекле тимер юл магистрале безгә **НӘРСӘ** бирәчәк

Озак һәм бәхетле гомер итү өчен **НӘРСӘ** кирәк




24 июль — 9 август

Казанда Су спорт төрләре буенча үткән дөнья чемпионаты 190 илдән рекордлы санда катнашучыларны җыйды. Татарстан башкаласында дөнья чемпионатын оештыру мондый турнирларны үткәрү тарихында иң яхшысы дип танылды.

ТАТАРСТАН-2015. ЕЛНЫҢ 10 КҮРЕНЕКЛЕ ВАКЫЙГАСЫ





13 сентябрь

Татарстан Президентын сайлауларда Рөстәм Миңнеханов сайлаучыларның 94.4 процент тавышын җыйды.



9 июнь

ТРның Югары Ослан районында «акыллы шәһәр» – Иннополисны ачу тантанасы булды, ул ИТ һәм югары технологияләргә профессионалларны тарту ноктасы булачак. Күпмедер вакыттан соң, Иннополиста 155 000 кеше яшәячәк һәм эшләячәк.



10 октябрь

Казан Париж һәм Шарлеруа белән ярышта 2019 елда профессиональ осталык буенча WorldSkills Competition дөнья чемпионатын уздыру хокукын отты.

10 август

ТР Дәүләт Советы Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслады. Документ алдагы 15 елга ТР үсешенең векторын билгеләде.





3 сентябрь

«Алабуга» махсус икътисадый зонасында чит ил машиналары өчен Россиядә беренче моторлар җитештерү предприятиесе ачылды. Ford Sollers двигательләре заводының егәрлеге бер елга 105 мең (200 меңгә җиткерү мөмкинлеге белән) двигатель тәшкил итә.



4 ноябрь

Татарстан Президенты Болгар ислам академиясен ачу һәм Казан Изге Мәрьям ана соборын торгызу турындагы карарга кул куйды.



14 апрель

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә XX гасырның иң бөек биючеләреннән берсе Владимир Васильев куелышында «Dona nobis pacem (Безгә тынычлык бүләк ит)» балетының дөнья премьерасы булды.



29 март

Казан «Зениты» волейболчылары үз тарихларында өченче тапкыр Европа Чемпионнар лигасында җиңеп чыкты. Финалда казанлылар Берлинда Польшаның «Ресовия»сен отты.



10 декабрь

Беренче Россия милли музыка премиясе-2015не Казан җырчысы, Вена операсы солисткасы Аида Гарифуллина алды. «Опера музыкасын иң яхшы башкару» номинациясендә ул Анна Нетребко, Любовь Казарновская, Мария Гулегина һәм Хебла Герзмава кебек көндәшләрен узды.

2016: ПРЕЗИДЕНТ ФАРАЗЛАРЫ

2015 ел азагында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов төрле очрашу, конференция һәм киңәшмәләрдә үткән елга нәтиҗәләр ясады һәм республиканың киләчәген фаразлады. «Татарстан» Президентның 2016 елга төп планнарын һәм фаразларын туплады.

2016: ҮРГӘ МЕНӘБЕЗ!

Ничек кенә катлаулы булмасын, киләсе елга без күп нәрсә планлаштырдык. Теләсә кайсы кризистан соң күтәрелеш булырга тиеш. Без хәзер үргә менә башларга тиешбез, дигән ышаныч бар. Өметләнәчәкбез, эшләячәкбез.

2016: ЛИДЕРЛЫКНЫ САКЛЫЙБЫЗ!

Инновацион активлык, башка индикаторлар буенча рейтингларда – республика беренче өчлектә, беренче бишлектә... Мин киләчәктә дә илдәге лидерлык позицияләрен саклап калырга нигез бар, дип саныйм.

2016: БЕЗ ҺӘРКЕМ БЕЛӘН ЭШЛӘРГӘ ӘЗЕР!

Мин Татарстанга инвестицияләр кертергә ниятләгән һәркем белән дуслашырга әзер. Без хәзер гарәп дөньясында да партнерлар эзлибез, мин төрек безнесы да бездән баш тартмас, дип өметләнәм. Көньяк-Көнчыгыш Азиягә, Кытайга өметләнәбез. Безнең бурыч – халыкны эш белән тәэмин итү, икътисадны үстерү, ә болар өчен инвестицияләр кирәк.

2016: УЯУ БУЛЫРГА КИРӘК!

Республикада террорчылыкка каршы барлык кирәкле чаралар да күрелә. Барлык хезмәтләр көчәйтелгән режимда эшли. Без аңлату эше, «террорчылыкка каршы ныгыту» алып барабыз. Тынычланырга ярамый, Аллаһ сакласын өчен, үзебезгә дә сакланырга кирәк. «Мондый хәл безнең белән булмаячак», – диярга ярамый. Бик уяу булу зарур.

2016: АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ БУЕНЧА ХӘЛЛӘР ӨМЕТЛЕ

Продукция белән тәэмин итүдә Татарстанның үзендә дә, аны республикадан читтә сатуда да беренди өзеклекләр юк. Без сөт җитештерү буенча лидерлар – республика территориясендә 1 миллион 700 мең тонна сөт җитештерелә. Агросәнәгать комплексы продукциясен сатудан 219 миллиард сум керем көтелә.

2016: ИҢ МӨҺИМ БУРЫЧЛАР

Якындагы елларда безнең икътисадның үсеш ноктасы дип нефть эшкәртүне һәм нефть химиясен саныйбыз. Нефть химиясе күләме буенча икеләтә диярлек артырга тиеш.

Машина төзелешендә, кыенлыкларга карамастан, КамАЗдагы яңа модель буенча эш бара, КамАЗ пилотсыз автомобиль җитештерү белән бик җитди шөгыльләнә. Ford Sollers Алабугада двигательләр җитештерү буенча яңа заводын эшләтеп җибәрде.

Оборона-сәнәгать комплексында авиация заводы буенча планнар зур: бу безнең стратегик бомбардировщикларны ремонтлау да, ТУ-160 самолетларын җитештерү дә.

2016: ИҢ МӨҺИМ ПРОЕКТЛАР

«Алабуга» махсус икътисадый зонасы» проекты бик уңышлы гамәлгә ашырыла – инвестицияләрнең гомуми күләме 95 миллиард сумнан артты, 5 300 эш урыны булдырылды. Якын арада 6 резидентны җәлеп итү планлаштырыла, бу яңа күләм, яңа салым кертемнәре, яңа эш урыннары бирәчәк.

«Иннополис» проекты. Соңгы максат – 155 мең кешелек IT-шәһәр төзү. Әлеге мәйданчыкта 60 мең айтишник эшләргә тиеш. Резидентлар бар инде.

2016: ПРОГРАММАЛАР ДӘВАМ ИТТЕРЕЛӘ

Социаль ипотека программасы буенча 420 мең квадрат метр торак тапшырылачак. Меңнән артык күпфатирлы йортны ремонтлаячакбыз. Барлык мөһим социаль программалар дәвам ителәчәк.

Әһәмиятле казаныш – демографик вазгыять. Бу иң мөһим нәтиҗә – ышанычлылык бар, тотрыклылык бар, һәм бәбиләр туа, медицина эшли. 2016 елның көзенә Казанда перинаталь үзәк эшли башлар, дип уйлыйм.

Парк һәм скверлар программасы. Бу бер тапкырлык кына шоу түгел. Парклар кышын да, бигрәк тә җәен эшләргә тиеш. Әлеге программага без хәзер сусаклау зоналарын өстибез. Моңа миллиард сум әзерләп куйдык.

2016: ТУГАН ТЕЛГӘ ЯРДӘМ

Ә иң мөһиме – тынычлык, килешү, безнең милләтара, динара мөнәсәбәтләрнең тотрыклылыгы. Диннәренә, милләтләренә карамыйча, кешеләр тыныч эшләсен һәм яшәсен өчен, бу – мөһим критерий. Монда стратегия дә бар, без барлык бу мәсьәләләрне актив хәл итәбез.

Үз телеңне, милли үзенчәлекләреңне саклап калу җиңел түгел. Шунлыктан якшәмбе мәктәпләренә ярдәм итәргә, укытуның барлык юнәлешләрен – удмурт, мари, чуаш, мордва телләренә өйрәтүне дә кайгыртырга кирәк.

2016: РЕСПУБЛИКАНЫҢ АБРУЕН КҮТӘРӘБЕЗ

Горький музее ачыла, Толстой, Боратынский, Тукай музейларын тәртипкә китерергә кирәк. Без моның белән киләчәктә дә шөгыльләнәчәкбез, бу республиканың абруен күтәрә. Бездә шундый бөек кешеләрнең яшәве һәм эшләве – зур горурлык. Мин әле Зөя, Болгар, 300 Сабантуй кебек зур проектларга тукталмыйм... Без Россия Федерациясенең 58 субъектында Сабан туйлары үткәрәбез, бу начармыни?

2016: ИҢ МӨҺИМЕ – СӘЛАМӘТЛЕК ҺӘМ ТЫНЫЧЛЫК

Аллага шөкер, без исән-сау... Аллаһ теләсә, киләсе елда да сау-сәламәт булырбыз. Сәламәтлек булса – барысы да булыр! Без үзебез, якыннарыбыз, дусларыбыз авырмасын. 2016 елда да барысы да тыныч булсын.

Фото: www.tatarstan.ru



ЮГАРЫ
ОЧЫШЛЫ УҢАЙЛЫЛЫК



Автор:
Владимир
Матылицкий

Капкасы нинди булса, хуҗасы да шундый. Татарстан башкаласының һава капкалары – башка башкалаларны көнләштерерлек. Моны документлар да раслый: World Airport Winners версиясе буенча «Казан» Халыкара аэропорты Россия һәм БДБ илләрендәге төбәк аэропортлары арасында иң яхшысы дигән статуска һәм Skytrax рейтингында 4 йолдызга ия.



Фото: Александр Эшкинин






Ике миллион – Казанның һава аланы аша ел дәвамында шуның кадәр пассажир үтә. Аларның күпчелеге 1А терминалы аша уза. Ул дүрт телескопик трап белән җиһазландырылган һәм пассажирлар агымын торбадан су кугандай үткәреп тора. Теркәү өчен 19 өстәл каралган, алты паспорт контроле кабинасы, дүрт куркынычсызлык контроле пункты этеш-төртешләрдән һәм очыш вакытында туарга мөмкин күңелсез сюрпризлардан азат итә.



Телескопик траплар җылы яклардан кайтучыларны аеруча сөендерә – урамда зәмһәрир суык булса да, «боинг» салоныннан аэропорт бинасындагы очып килү залына шорты белән майкаларда үтеп була. Шул ук вакытта багаж төялгән арбалар пассажирларның артыннан ук тоткарлыксыз бара. Транспортер янына килеп басуга, чемоданың инде – тасмада! Әйтергә кирәк, багаж белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы эшкәртүне генә гадиләштереп калмый, югалган очракта, эзләп табуны да җиңелләштерә.



Терминал 1 Идел буе төбәгендәге төбәкара рейсларга һәм якын чит илләргә рейсларның бер өлешенә хезмәт күрсәтә. Терминаллар үзара тоташкан, һәркайсыннан туп-туры аэроэкспресслар перронына эләгергә була, шулай ук урамга чыкмыйча гына – траволатор аша. Тагын терминал 2 бар – анысы VIP-персоналар өчен. Ул сәгатенә 100 пассажирны кабул итеп үткәрә ала, һәм гадәттә анда пассажирлар сирәк була.



Пассажирга нәрсә кирәк? Транспортның аэропортка кадәр йөрүе, чиратларның булмавы, ә менә күрсәткечләрнең һәм очышлар таблосының аңлаешлы булуы. Тагын – кафе һәм рестораннар, белешмә бирүче хезмәтләр, чиста бәдрәфләр, саклау камералары… Бирedә боларның барысы да бар.



Пассажирлар өчен иң югары дәрәҗәдәге уңайлылык тудыру – «Казан» Халыкара аэропорты генераль директоры Алексей Старостинның бөтен көчен куеп эшләгән эш юнәлеше.

– Иң мөһиме – бар да технологик югарылыкта, пассажир өчен уңай булсын, – дип сөйләгән иде берничә ел элек аэропортны реконструкцияләү чорында ул. – Казанда пассажирга хезмәт күрсәтүнең уйланылган технологиясе булган заманча бина төзеләчәк.

Инде ниятләр тормышка ашты, дип белдерергә дә була.



Тимер юл һәм аэровокзал арасындагы аэроэкспресс көнгә 8 тапкыр әйләнеш ясый. Аэропорттан метроның иң якын станциясенә кадәр автобус йөри. Такси? Проблема юк! Аэропортка үз транспортында килүчеләр өчен 795 машинага исәпләнгән һәм 50 VIP-урын бар. Өстәвенә, 80 машиналык сакланмый торган урын һәм 30дан артык автобус кую урыны.



Куркынычсызлык – теләсә кайсы һава аланы өчен төп таләп. «Казан» аэропортында терминалларны 700гә якын видеокамера күзәтә, багажны дүрт дистә интроскоп «үтәли карый». Пассажирларны карау өчен дүрт сканер исәпләнгән. Аэропортта хәтта этләр белән кинологлар да эшли.



Бирергә чиратлар юк диярлек: банкоматлар, электрон терминаллар җитәрлек урнаштырылган, барларда, кафе һәм рестораннарда урыннар күп. Багаж тапшыру автоматлары, сувенир киосклары, даруханә, акча алыштыру пунктлары, туристлар өчен мәгълүмат… Хәтта гыйбадәт кылу бүлмәсе дә бар. Күрсәткечләр өч телдә язылган: рус, татар һәм инглиз телләрендә.



«Казан» аэропортында Wi-Fi бар. Россиянең теләсә кайсы почмагына һәм җирле кәрәзле номерларга бушлай шалтырату мөмкинлеге булган алты таксофон инвалид коляскасында хәрәкәт итүчеләр өчен дә уңайлы биеклеккә урнаштырылган. Бу таксофоннар начар күрүчеләр өчен Брайль әлифбасы һәм начар ишетүчеләр өчен тавыш көйләгечләр белән җиһазландырылган.



Пассажирларга утырту талоннарын чыгарып алу өчен, Reprint терминаллары куелган, алар вакытны янга калдыру мөмкинлеге бирә. Бу мөмкинлектән гадәттә web-теркәлү үтүчеләр файдалана. Терминал «ә» дигәнче сезнең гаджет экранында күренгән кодны укып, талон чыгарып бирә. Барысы да тәртиптә – хәерле юл сезгә!

PRESSA.RU



Иллюстрация: Вильям Бугро. «Приятное бремя», 1895 ел.

ИКЕ СЕҢЕЛ



Владимир Мамонтов, журналист, сәясәт белгече, «Говорит Москва» радиостанциясенең генераль директоры тормыш фәлсәфәсе турында уйлана.

Россия Фәннәр академиясенең Социология институты мәгълүматларына караганда, Россия халкының якынча 8 проценты илдәге вазгыятьне һәлакәт чигендә дип бәяли. Моңа сез ни диярсез? Н-ну... Тормыш итү чыннан да җиңеләюгә бармый кебек: санкцияләр, нефть арзаная, кар яумый, әле тегесе, әле монысы. Кайберәүләр моны аеруча авыр кабул итә. Хаклары бар...

Юк, сез аңлап җиткермәдегез. Россия Фәннәр академиясенең Социология институты мәгълүматларына караганда, Россия халкының якынча 8 проценты вазгыятьне һәрвакытта да һәлакәткә тиңли. Кар яуса да, яумаса да... Хикмәт анда түгел. Алар өчен һәлакәткә һәрвакыт урын бар.

Шаккатмалы бит. Күз алдына гына китереп карагыз: халыкның төп өлеше бөтенләй башкача уйлый. Менә карагыз: 90нчы еллардан соң 2000нчене ваклый башладык – һәм социологлар төзегән графиклардагы сызыклар өскә таба юнәлеш алды. Урамнардан күселәр юкка чыкты, кибетләрдә товарлар барлыкка килде, эшкә урнашу, хәтта берәр атналык ял алып, Прагага барып кайту да мөмкин була башлады, ә алты сутый җирдә бәрәңге урынына чыршы утыртсаң да була – берәү дә аптырамаячак. Канәгатьсезлек күрсәтүчеләрнең бер өлеше (бөтен кеше дә газ тармагында эшләми бит) акрын-акрын кими бара, тормыш билгеле бер эзгә төшә бугай, дип уйлаучылар арта. Шуннан соң, менә сиңа мә – 2008 ел, кризис. Көр күңеллеләрнең саны тагын кими. Реалистлар кырыслана, билдәге каешларын кысыбрак буа.

Ләкин боларның берсе дә һәр нәрсәдән фаҗига ясарга яратучылар категориясенә тамчы да туры килми. Авыр еллармы, кырыс еллармы – аларга барыбер. Алар дөньяга үз каланчаларыннан карый – һәм аларның дөнья картинасы үзгәрми диярлек.

Гадиләштереп тормыйбыз: араларында хезмәт хакларыннан да, перспективалардан да канәгать түгелләр шактый. Күбесе социаль үзгәрешләр, икътисадтагы күтәрелешләр һәм түбән тәгәрәүләр шәхсән аларга кагылмый торган өлкәдә эшли. Шәхси машинасы белән кешеләр ташучы пенсиядәге бер танышым әйтмешли, «сельпога хамон китергәннәре юк, китермиләр һәм китермәячәкләр».

Ләкин күпләр һәлакәт халәтендә яшәргә ияләшкән, күнеккән инде, билгеле бер мәгънәдә алар бу халәттә үзләрен уңайлы хис итә. Мәхлук, мескен кеше «мин генә берни дә үзгәртә алмыйм, миннән тормый» дип яши, ул шушы социаль рольне сайлаган һәм үзенең бәхетсезлегенең сәбәбен һәрвакыт читтән генә эзли, ә ул исә төпкә тарта, бер эләктереп алса, җибәрми. Амплуага әверелә. Моны читтән күзәтү кызык, ләкин андый кешеләр өчен куркасың: әлеге кара көйгән буш далада алар ничек яши? Энә күзе кадәр генә бәхет нуры алар өчен кайсы болыт астыннан чыгып елмаер соң? Караңгылык белән генә туену мөмкин түгел бит! Әллә мөмкинме?

Үзең алган тәэссоратлар – иң җетеләре, килешәсезме? Шулай килеп чыкты: миңа озак еллар дәвамында өлкән яшьтәге ике хатын-кызның тормышын күзәтеп барырга туры килде. Хәер, алар вакытлар үткәч өлкәнәйде, ә кайчандыр үз бәхетләрен табарга өметләнгән япь-яшь кызлар иделәр. Тормышларын кыска гына итеп сурәтләгәндә болайрак: яшьли әтисез калу, ачлык, тозлы балык белән тамак ялгап үткән ачлы-туклы студент тормышы, кеше аягы сирәк баса торган якларда эшләү, сугыш, көндәлек тормыштагы уңайсызлыклар. Алар яшәгән йортларда суыткыч та, телефон да булмады, беренче кер юу машиналары бүлмә буйлап сикереп йөри иде, ә шушы шатлыклы вакыйгага кадәр алар керне кул белән уды. Гомерләренең шактый күп өлеше Сталин чорына туры килде, аннан соң волюнтаризм, торгынлык еллары. Кара көнгә дип җыйган акчалары ике тапкыр янды. Түләнә торган пенсияләре дә мескен генә, югыйсә алар күбрәк пенсиягә лаек кешеләр иде.

Ләкин шунысы гаҗәп: алар тормышны кабул итүләре буенча бер-берсеннән бөтенләй аерылып тора иде. Берсенә бу иксез-чиксез михнәтләр сихердәй тәэсир итә. Ул каршылыкларны җиңә-җиңә алга атлау гына түгел, башкача мөмкин булуын аңламый да иде. Ә башкача ничек, тормыш бит бу! Укуында да искиткеч үҗәтлек-тырышлык белән уңышларга ирешә, яхшы урынга эшкә эләгергә тырыша, иң яхшы хезмәт хакына омтыла, иң катлаулы участокларда эшләргә алына, Сталинга атап шәм кабызмый, Хрущевтан көлә генә, Брежнев турында «әйбәт абый» дип сөйли, көнне-төнгә ялгап тир түгә, җырлый, теш арасына пычак кыстырып, лезгинка бии. Бер ул үстерде, аны һәрвакыт хөрмәт иттеләр һәм һәрвакыт көр күңел белән яшәде. Икенчесе исә йомшак кына искән җилдә дә селкенеп тора. Күп укыды ул, зәвыклы булды һәм бөтен йөрәге белән үзен кызганучан иде.

Шулай яшәде дә – әлеге дә баягы оптимист апасы (ә алар апалы-сеңелле иде) гомеренең актив чорында иңенә иңен куеп, арыш башагын тартып, ипи итеп пешереп, аңа дигән тормыш авырлыкларының бер өлешен үз җилкәсендә тартып барганга. Аның өчен җырлап барганга. Аның өчен илне тартып барганга.

Һәм тормышында тыйнак кына бәхет, тыныч кына шатлык кичергән өчен ул һәрвакыт якты чырайлы, көр күңелле апасына рәхмәтле була белде – монысына төпчек сеңелнең йөрәге һәм акылы җитәрлек иде.

Кайчак уйлап куям: әлеге сигез процент тәнкыйтьче һәм «бар да җимерелде» дип даими зарланып торучылар кавеме әйбәт кенә итеп җайлашып алган бу тормышта. Бәхеткә, 92 процент бар: аларның эшли, җырлый һәм беркайчан да зарланмый торган абый-апалары.

Югыйсә, бөтенләй харап булыр идек.



РАЙОННАР БУЙЛАП!

«Татарстан» журналы «Районнар буйлап!» дигән кыска исем астында махсус проектка старт бирә. Максатыбыз – республикадагы 43 муниципаль районның һәрберсе турында сөйләү. Андагы кызыклы кешеләргә, игелекле гамәлләр, шәп бизнес-проектлар, уникаль һәйкәлләр һәм башкаларга, ягъни еракта һәм якында урнашкан кала-салаларыбыз горурлыгы булганнарга багышланган проект бу. Әгерҗе – башкаладан иң ерак урнашкан районнарның берсе. Аңардан башлыйбыз да.

Александр Эшкинин фотолары



Автор:
Олеся Бондаревская

ӘГЕРҖЕ. ТАМЫРЛАРЫ ҺӘМ ЯБАЛДАШЫ

Әгерҗе чыннан да Казаннан шактый читтә урнашкан. Аның белән танышу кызык булыр, дип уйлыйбыз. Бирегә безне ниләр үзенә җәлеп итте соң? Гаҗәеп табигате һәм искиткеч кешеләре. Аларны бер нәрсә берләштерә: замананың һәм вазгыятьнең нинди булуына карамастан, алар әйләнә-тирә дөньяны яхшырак итәргә тырыша.

КРИЗИСМЫ? ЮК, СИЗМИМ ӘЛЕ

Сәфәребездә беренче тукталыш – Кичке Таң авылы. Безне җирле фермер Тәлгать Муллахмәтов каршылый. Моннан ел ярым элек ул иске МТС территориясендәге 5 гектар җирне сатып алган. Гаиләсе – хатыны, кызы, ике улы белән иске ангарларның берсен ремонтлаган. Быелтыр августта сарыклар алып кайтканнар. Шул рәвешле үз эшен башлап җибәргән.

– Минем сарыкчылык хуҗалыгым әлегә тирә-якта иң кечкенәсе, 250 баш кына. Терлекләрнең санын икеләтә арттырырга уйлыйм.

Кризис көчәйгән чакта эш башлау куркытмыймы икән соң?

– Кризисмы? Минем әле аны сизгәнем юк, – дип көлә фермер. – Кредитлар алмадым. Барысын да үз акчама эшлим. Җир эшкәртүгә дәүләт субсидияләре бар, әмма бик аз – 30 гектарга 6 мең сум тирәсе. Печәнне үзем үстерәм, үзем әзерлим. Күптән түгел печән әзерләү өчен пресс сатып алдым. Район администрациясе дә, поселокныкы да эшемдә булышалар.

Без фермерның киләчәктә дә кризиска бирешмичә эшләвен телибез, аның белән көрәшергә Тәлгать Муллахмәтовның вакыты юк. Тиздән сарыклары бәрәнләячәк, аларга яңа абзар төзергә кирәк.



Фермер Тәлгать Муллахмәтов иске МТС территориясендәге 5 гектар җирне сатып алган.



«Кичке Таң» тыюлыгы инспекторлары һәм аларның «Кояшкай» балалар бакчасындагы ярдәмчеләре

ИТАЛМАСНЫҢ БАШ САКЧЫСЫ

«Кичке Таң» тыюлыгы директоры Әһли Фәйзуллин безгә җирле риваятьне сөйләде. Егет белән кыз Иж елгасында су коенган. Анда бик тирән булган, бата башлаганнар. Егет суга баткан, кыз исә үсемлек сабагына ябышып ярга чыга алган. Шул вакыттан бирле әлеге үсемлек кызның исеме белән «италмас» дип атала икән.

Бу – саз чәчәге, руслар аны «купальница» дип атый. Ул Татарстанның юкка чыгып баручы төрләре китабына кертелгән. Әһли Гаскәр улы һәм инспекторлар коллективы кешеләр җирле табигатькә зыян китермәсен, дип күзәтә. Закон бозучыларга штраф салына, былтыр 220 мең сумлык штраф салынган.

– Хәзер без Татарстан территориясендәге өлеше табигать һәйкәле статусына ия булган Иж елгасының Удмуртия территориясендә дә шундый ук статус алуына ирешергә телибез. Алайса италмас чәчәген коткарып калып булмаячак, – дип аңлата Әһли Фәйзуллин.

ИҢ ЭКОЛОГИК БАЛАЛАР БАКЧАСЫ

– Урманда кош ояларын туздырырга, керпе һәм күбәләкләрне тотарга, ботакларны сындырырга, пәрәвезгә тияргә ярамый! – дип, яңгыравыклы тавышы белән сөйли инспектор-эколог костюмы кигән кыз бала.

Кичке Таң авылындагы «Кояшкай» балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрне тере табигатьне саклау кагыйдәләре белән шулай таныштыралар.

– Без Рыжованың «Табигать – безнең туган йортыбыз» программасы буенча шөгыльләнәбез. – дип сөйли балалар бакчасы мөдире Сәрия Нуриева. – Без бит «Кичке Таң» дәүләт тыюлыгы янәшәсендә яшибез. Мондый матурлыкны сакларга балачактан ук өйрәтергә кирәк, бу безнең иң зур байлыгыбыз. Экология белән мавыкмый һич мөмкин түгел – бакчабыз тыюлык инспекторлары белән бер бинада урнашкан бит!

Сүз уңаеннан, нәкъ менә биредә, Кичке Таңда, Җир хартиясе – ЮНЕСКО тарафыннан расланган халыкара кеше һәм әйләнә-тирә мохит хокукларын яклау декларациясенең Татарстанда беренче ташы урнаштырылган. Хартияне ТР Дәүләт Советы 2001 елда программа сыйфатында хуплаган булган. Таш Татарстанда Хартияне гамәлгә кертүнең нәкъ менә Әгерҗе җирендә башлануы символы булып тора.



Әһли Фәйзуллин Татарстанда Җир хартиясен гамәлгә ашыру символы янәшәсендә



МӘГЪРИФӘТЛЕ ИСЛАМ ХАКЫЙКАТЬЛӘРЕ

Иж-Бубый авылындагы мәчет. Аның125 елдан артык тарихы бар. Мәчет каршында мәдрәсә эшли, шулай ук XX гасырның танылган татар мәгърифәтчеләре Бубыйлар (Нигъмәтуллиннар) гаиләсе музее да вакытлыча бирегә урнаштырылган. Мөхлисә Бубый язмышы бигрәк тә фаҗигале булган. Иж-Бубыйда мөслимәләр өчен беренче мәдрәсәгә нигез салучы Россиядәге тәүге хатын-кыз казыя 1937 елда атып үтерелгән.

Мәгърифәтле ислам традицияләрен Иж-Бубый мәчетенең унсигезенче мулласы Котдус хәзрәт дәвам итә. Ул колхоз рәисе, Әгерҗе администрациясе башлыгы урынбасары булган, хәзер исә мәхәллә халкына рухи белем бирә.

– Христианлык, мөселманлык һәм иудаизм – төрле диннәр, еш кына аларның канунннары бер-берсенә каршы килә. Бүген кайберәүләр тәкъдим иткәнчә, аларны берләштерү, кушу мөмкин түгел. Әмма Коръәндә, без башка диннәрне хөрмәт итәргә тиеш, диелгән. Бүген җәмгыять тынычлыкка һәм татулыкка таянырга тиеш, – ди бөек мәгърифәтчеләрнең бөек мирасын саклаган бүлмә уртасында басып торучы Котдус хәзрәт.

Фото: Александр ЭШКИНИН



– Бүген җәмгыять тынычлыкка һәм татулыкка таянырга тиеш, – ди Котдус хәзрәт



Тимерьюлчылар династиясенең дәвамчысы Евгений Бареков

200 ЕЛ ЮЛДА

Әгерҗе – Горький тимер юлындагы иң зур станцияләрдән берсе. Биредә безне вокзал башлыгы Евгений Бареков каршылый.

– Мин тимерьюлчылар династиясеннән. Нигез салучысы бабам булган, хәзер аның эшен инде оныгының баласы дәвам итә, – дип сөйли Евгений Владимирович. – Ә Барековлар династиясенең гомуми стажы 200 елдан артып китә.

Вокзал башлыгының һәр эш көне төрле тәэсирләргә бай.

– Бервакыт бер яшь пар биредән башта Мәскәүгә китәргә, аннары чит илгә очарга тиеш иде. Поезд килгән, ә аларны утыртмыйлар. Билетларын чит ил паспорты белән алганнар, хәзер исә Россиянекен күрсәтәләр икән, чөнки чит ил паспортлары инде Мәскәүдә. Билгеле инде, мондый очракта проблеманы вокзал башлыгы гына хәл итә, – дип сөйли Евгений Владимирович. – Аларга башта таксида Казанга барырга, анда инде, яңа билет алып, Мәскәү поездына утырырга тәкъдим иттем. Өлгерделәр. Мондый мәсьәләләрне вокзал башлыгына көн саен хәл итәргә туры килә.

Гадәттән тыш булган очракларда ничек юлын табарга соң?

– Тимер юлга кадәр мин ОБХССта эшләдем, шунлыктан кешеләр белән аралашу тәҗрибәм шактый бай минем! – дип шаярта Евгений Владимирович.



Паровоз 1971 елда Бөек Ватан сугышында һәлак булган Әгерҗе хезмәтчәннәре хөрмәтенә куелган

РАЙОННАР БУЙЛАП / МАХСУС ПРОЕКТ



Марат Муллахмәтов һәм аның гармунчылар ансамбле Бах, Моцарт, Бетховенны яңгыратырга ниятлиләр

БАЯНДА – БАХ КӨЙЛӘРЕ

– Минем яраткан җырым – ерак шәһәргә шахтада эшләргә киткән һәм үзенең туган ягын, сөйгән кызын сагынучы егет турында, – дип сөйли Әгерҗе Мәдәният йортындагы бәйрәм ыгы-зыгысында Марат Муллахмәтов. Ул биредәге гармунчылар халык ансамбле җитәкчесе. Аның әтисе дә, кыз туганы да баянда уйный – инде бер династия диярлек. Райондагы барлык гармунчы-баянчыларны бер ансамбльгә туплау идеясе Маратта моннан ун ел элек туа. Хәзер инде алар Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә танылган – 2015 елда коллектив халык ансамбльләренең «Күп чалымлы Россия» конкурсы лауреаты булган. Һәркайсы авыл Мәдәният йорты җитәкчесе булган музыкантларның төп бурычы – баян һәм гармунны популярлаштыру.

– Безнең иң популяр композицияләребез – татар халык җырлары, без аларны үзебезгә яраклаштырдык: кайбер урыннарын бераз тизәйттек, кайбер җирләрен баеттык. Алар искиткеч заманча яңгырый. Хәзер менә Европа классикасын – Бах, Моцарт, Бетховенны өйрәнергә җыенабыз. Минем уйлавымча, бу безгә дә, тыңлаучыларга да бик кызык булачак, – дип йомгак ясый сәнгать җитәкчесе. Ә үзе баянында борынгы татар көен сыздыра...

ТАМЧЫДАН КҮЛ ҖЫЕЛА

Күрешкәндә, Саҗидә апа минем учымны үзенең җылы һәм көчле бармаклары белән кыса. Әгерҗедә яшәүче бу әбигә күптән түгел 90 яшь тулган. Тыл хезмәтчәне, профессиональ тегүче, биш бала анасы, 11 онык һәм 7 оныкчыгының әбисе. Саҗидә апа бүген дә эштән туктамый: мәчетләр төзелешенә акча җыя. Ун еллык хәйрия эшчәнлеге дәверендә ул өч меңнән артык кешедән 400 мең сум акча җыйган. Бу акча Әгерҗедәге мәчет һәм мәдрәсәне төзеп бетерергә ярдәм иткән, Красный Бор авылында төзелешне башларга мөмкинлек биргән.

Үзенә сәдака биргән кешеләрнең исемнәрен әби тәфсилләп дәфтәргә язып бара, хәзер инде сигез дәфтәре тулган.

– Әни базарга бара һәм шунда дәфтәре белән утыра, хәер биргәннәрне шундук теркәп куя. Ул – бик тәкъва кеше. Мөгаен, шуңа да зур куәткә ия-дер. Әгерҗе халкында шундый сүз дә йөри – әнигә акча биргән кешеләрнең һәркайсына савап була икән, – дип сөйли Саҗидә апаның кызы Лилия.

Саубуллашканда, Саҗидә апа баскыч төбеннән безгә кул болгап калды.

– Ирләрегез белән озак һәм бәхетле яшәгез! – дип тели ул безгә татарчалатып. Һәм безнең, чыннан да шулай булыр, дип ышанасы килә.



Биш бала анасы, 11 онык һәм 7 оныкчык әбисе Саҗидә апа кызы Лилия белән

ТИЗЛЕККӘ АШКЫНУ



Автор:
Айдар Сәгъдиев

Уртача татарстанлы, әгәр бик тели икән, өч сәгать эчендә Казаннан Сарманга барып җитә ала. Яисә Чебоксарга. Бу – бүгенге көндә. Ә инде бер биш елдан соң ул шушы вакыт эчендә Россия башкаласының үзәгенә кадәр барып җитә алачак.

КАЗАН – ТҮБӘН НОВГОРОД
1 сәг. 30 мин.
~~9 сәг. 10 мин.~~

КАЗАН – МӘСКӘҮ
3 сәг. 30 мин.
~~14 сәг. 7 мин.~~

Беренче мәртәбә илебездә югары тизлекле магистральләр турында узган гасырның 70нче елларында сөйли башлыйлар, хәтта Мәскәү – Ленинград һәм Мәскәү – Симферополь маршрутлары буенча проект алды эшләре эшләнгән була. Россия әлеге темага кире әйләнеп кайтсын өчен, өч дистә ел һәм читтән инвестицияле ярдәм таләп итеlә – бу инде үзе бөтенләй башка илгә әверелгән һәм күршесендә тагын да күбрәк үзгәреш кичергән Кытай булган хәлдә.

Беренче карашка, Татарстанга бик уңай туры килгән кебек: нәкъ менә Көнбатыш Кытай Европа юл өстендә урнашкан. Әмма эш, әлбәттә, уңай туры килү белән күршедә Кытай булуда гына да түгел. Ә шунда ки: булачак магистральнең тарту көче зонасында ил халкының 20 проценты яши һәм аның өчен ул файдасы төрле яктан «килеп чыга торган» зур интеграль проект. Ләкин бу хакта соңрак.

Мәскәү белән Казан арасында көненә **30** рейс

«Мәскәү – Казан» югары тизлекле тимер юл магистрале нигездә инде киләсе елда әзер булырга тиеш.

770 км
«Мәскәү – Казан» ЮТМ трассасының озынлыгы



ВАГОН ТУРЫНДА БӘХӘСЛӘР – ИҢ СОҢГЫ ЭШ

Исегезгә төшерик, «Мәскәү–Казан–Екатеринбург» ЮТМ проекты Свердловск өлкәсе һәм Татарстан хөкүмәтләре кабинетларында 2009 елда туган иде. Иң беренче чиратта ул чит илләрдә булган тизлекле тимер юл инфраструктурасын үстерү тәҗрибәсенә нигезләнә. Соңгысы бигрәк тә тәэсирләндергеч. Әйтик, Париж, Брюссель һәм Лондонны бәйли торган ЮТМ киселешенә туры килгән депрессив саналган француз шәһәре Лилль дистә ел эчендә илнең халык саны буенча икенче агломерациясенә һәм иң эре постиндустриаль үзәгенә әверелде. Кытайда Пекин–Тяньцзинь линиясе ачылып, бер ел гына узганнан соң да, әлеге шәһәрләр арасындагы икътисадый бәйләнеш күләме 25%ка үсә. «РТЮ» ААҖнең беренче вице-президенты, «Тизлекле магистральләр» компаниясе гендиректоры Александр Мишарин сүзләренә караганда, Япониядә тизлекле һәм югары тизлекле линияләр эшчәнлегеннән кергән еллык тулаем керем 60 миллиард евроны тәшкил итә. Нәкъ менә шуңа күрә дә югары тизлекле трассалар хәзер бөтен дөнья буйлап проектлана һәм төзелә – Бөекбританиядә, АКШ, Бразилия, Мексика, Төркия, Мароккода...

«Казан–Мәскәү» ЮТМ төзелеше якынча 1,069 триллион сумга төшәчәк, дип бәяләнә. РТЮның төп инвесторлары дәүләт белән бергә концессионерлар булачак, аерым алганда, China Investment Corporation компаниясе, ул, беренче сөйләшүләр буенча, проектка 300 миллиардка якын акча салырга тиеш. 2015 елның маенда Россия һәм Кытай башлыклары, ЮТМ Кытай технологияләре буенча һәм аларның җиһазларын кулланып, әмма Россия компанияләре катнашында төзеләчәк, дип килештеләр.

– Аңлашыла ки, Кытай өчен дә бу альтруистик проект түгел. Ул үз бурычларын хәл итә, – дип шәрехли Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Вадим Хоменко. – Һәрвакыттагыча, кытайлар алга таба үзләре таяна алырлык объект төзиләр – әйтик, үз товарларын сату яисә үз сәнәгатьләрен чимал белән тәэмин итә алу максатында. Өстәвенә, алар инвестицияләр кертүне бик акыллы хәл итәләр. Әгәр бу заем акчалары икән – димәк, бик түбән проценттан. Ләкин – һәрвакыт билгеле бер шартларда.

2015 елның июнендә «РТЮ» ААҖнең әле ул чактагы президенты Владимир Якунин, ЮТМ проектлау (шул вакытта башланган) ике елны алачак, ә төзелеш эшләре – тагын биш елны, дип белдергән иде. Узган елның сентябрендә үзенең бер әңгәмәсендә Россия Президенты Владимир Путин ЮТМ инде 2020 елга эшли башларга тиеш, дигән төгәллек кертте.

ТАТАРСТАНГА БАРАСЫҢМЫ –



«ТАТАРСТАННЫ» УКЫ!

КРИЗИСКА КАРШЫ ПРОЕКТ

Мәскәүдән Казанга бүген өч мең сумга самолетның эконом-классында очарга мөмкин. Поездда купега билет якынча шул ук бәягә төшә. Табигый ки, ЮТМ, базарда көндәшлеккә ия булсын өчен, тизлек кенә түгел, түли алырлык бәя дә тәкъдим итәргә тиеш.

Мәскәү Инфраструктура икътисады үзәге исәпләүләренә караганда, юл инде эшли башлавының икенче елында ук 10,5 миллион пассажирны (шуларның 2,7 миллионы Мәскәүдән Казанга киләчәк) күчереп йөртәчәк, пассажир ташуның гомуми күләмендә ЮТМнең өлеше 49%ны тәшкил итәчәк. Әлеге шактый саллы күрсәткечкә төрле категориядәге пассажирлар өчен билет бәяләренең дә төрле булуы хисабына ирешеләчәк, дип уйланыла. Югары сегментны эшлекле кешеләр биләячәк – алар иң уңайлы сәгатьләргә ия булачак. Калган вакыт «шәхси йөрүләр» категориясенә калдырылачак. Мондый очракта билетларның өчтән бере Мәскәүдән Казанга кадәр 3200 сум булачак, икенче өчтән бер өлеше – 4800 сум, калганнары – түбән сегмент (2400), югары (6400) һәм люкс (10000).

Мондый бәяләр режимы гади тимер юллар буенча пассажирлар ташуны үзеннән-үзе «гамәлдән чыгарачак». ЮТМ бер уңайдан Мәскәү юнәлешендәге авиарейсларның да юкка чыгуына китермәсме? «Алай булмаячак, – дип раслый ТР Транспорт министрлыгының иҗтимагый советы рәисе Павел Чернов. – Халыкның керемнәре арту һәрвакыт авиаташулар санының артуына китерә. Бер яктан караганда, бу бүген иң зур тизлеккә ия транспорт. Икенчедән, аэропортларда утырту вакытын киметү юнәлешенә караган барлык мөмкинлекләр әлегә кулланылып бетелмәгән».

Социологик сораштырулар шуны күрсәтә: ЮТМ проектында катнашучы төбәкләрдәге халыкның өчтән береннән күбрәге, югары тизлекле магистраль кулланышка тапшырылганнан соң, бер шәһәрдә эшләп, икенчесендә яшәргә каршы түгел. Төбәкләр башкалалары арасындагы юл өчен түгелгән вакыт уртача алганда бер сәгатькә кадәр кыскарырга тиеш, ә Түбән Новгородтан Казанга кадәр вакыт– игътибар – бүгенге тугыз сәгать ярым урынына сәгать ярымны тәшкил итәчәк.

Татарстан өчен бу, мөгаен, күрше төбәкләрдән (Чебоксардан Казанга кадәр 34 минутта барып җитеп булачак) эшче көчләр агымы артуын аңлатачак, алай гына да түгел, магистральнең көнчыгышка таба озынайтылуына бәйле рәвештә, республика эчендәге халыкның хезмәт мобильлеге шактый югары күтәреләчәк. Бу очракта булачак магистральгә предприятиеләренең ТТПндагы өлеше өчтән бергә якынлашкан Кама сәнәгать кластеры кушылачак. Кластер, исегезгә төшерик, якындагы дистә елга Татарстан икътисадының төп үсеш ноктасы итеп билгеләнгән. Ә Яр Чаллыны ЮТМ моношәһәр булуын кәгазьдә генә калдырачак. Болар барысы да эшсез халыкның санын киметүгә китерәчәк, ә ЮТМгә якын төбәкләрдә хезмәт хакы дәрәҗәсе, ТР Транспорт министрлыгы бәяләренә караганда, 30–50%ка үсәчәк.

Ләкин агломерацион эффект – ЮТМ ачуның бары тик турыдан-туры булмаган нәтиҗәсе генә. Югары тизлекле магистраль – чимал булмаган тармакларның һәм инновацион технологияләрнең үсешенә этәргеч тә, автоюлларны, шул исәптән күпне күргән М7 трассасын бушату да әле. РФАнең Халык хуҗалыгын фаразлау институты шуны санап чыгарган: магистральне төзү 1,2 триллион сумлык (2013 елгы бәяләрдә) продукция җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен мультипликатив эффект бирәчәк һәм хезмәт базарында 370 мең яңа эш урыны (Татарстанда – 8 мең) өстәячәк, бу әле магистральне төзүдә һәм эксплуатацияләүдә мәшгуль халыкны исәпкә алмаганда. Ягъни бүгенге икътисадый вазгыятьтә ЮТМ кебек зур төзелеш акрынаю ягына юнәлгән икътисадка уңай этәргеч бирә алачак. Бу чыннан да кризиска каршы проект.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР
БУ МӨҺИМ

Проектны Татарстанда гамәлгә ашыруның мультипликатив эффекты 301,5 млрд сумны тәшкил итәргә тиеш.

ПОЕЗД ӘЛЕГӘ КИТМӘГӘН

Магистраль Казанга нинди маршрут буенча килеп җитәчәк? Әлеге сорауга җавапны, ихтимал, инде мартта ук алып булырдыр, ул вакытта ЮТМны урнаштыру территорияләрен планлаштыру буенча документларны раслау күздә тотыла. Аккош күле районындагы урман массивын һәм торак җирләрне юк итүне күздә тоткан вариантларның нинди резонанс уятканын күпләр хәтерлидер. Күрәсең, әлеге тәҗрибәне истә тотып, Александр Мишарин проектантлар каршында «шәһәрләрнең инде формалашкан инфраструктураларын үзгәртүне һәм юкка чыгаруны минимумга китерү» бурычын куя.

Трассаны эшләүчеләр Казан участогының берничә вариантын тәкъдим итә – берсе Биектаудагы вокзал белән, икенчесе – Казаннан көньяктарак урнашкан станция белән (бу очракта Идел аша күпер төзергә кирәк булачак). Бүген исә, безнең мәгълүматларга караганда, җитди рәвештә түбәндәге вариант карала: торак зоналарның кагылгысызлыгын, магистральне турыдан-туры шәһәргә кертүне (Төньяк вокзалы районында) күздә тотканы гамәлдә булган тимер юл өстеннән 13 километрлы эстакада салу хисабына хәл ителә.

– Ләкин монда да барысы да җиңел генә түгел, – дип аңлата КДАТУ доценты Ринат Гобәев. – Тәүлек саен ЮТМ буйлап, 13 пассажир поездыннан тыш, аңлавымча, һәрберсе, ким дигәндә, 3600 тонна булган контейнерлар алып баручы 11 йөк составы үтәр, дип көтелә. Шундый тизлекләрдә эстакадага нинди динамик йөкләнеш туры килүен күз алдына китерәсезме?! Әйе, Казанга составлар киметелгән тизлектә керәчәк, ләкин, шуңа да карамастан, әлеге вариантның куркынычсызлыгына карата минем үземдә сораулар кала бирә.

Һәм куркынычсызлыкка карата гына түгел. Эстакаданың биеклеге 15 метрдан да ким булмаска тиеш, дип уйлый Ринат Гарифуллович, киңлеге, ким дигәндә, 25–30 метрлар тирәсе. Бу ныклы фундаментлар, таянычлар һәм ригельләрсез эшләп булмаячак дигәнне аңлата. Гамәлдәге юллар буйлап төзелеш техникасы узмаячак, димәк, барыбер урман кисәргә кирәк булачак. Моннан тыш, эстакаданы төзү аркасында тимер юлның шактый интенсив пассажир һәм йөк ташу участогын туктатып торырга туры киләчәк. Һәм, ахыр чиктә, бу җир өстендә магистральне төзү белән чагыштырганда шактый кыйммәткә төшә.

Эксперт ЮТМне Казанга кертмичә, кырыйдан, «Биектау» варианты буенча, ләкин көньяктарак, М7 юлына параллель рәвештә төзергә тәкъдим итә. Һәм шәһәрдән төньяккарак 8–10 километрда, чиста кырда, вокзал, депо һәм логистика контейнер үзәге (эстакада вариантында да аларны төзергә туры килә – тик шәһәр читендә, торак төзелешенә кагылып һәм коммуникацияләрне чыгарып) салуны да. ЮТМ пассажирларын «Төньяк вокзал» метро станциясенә кадәр китерүне төрле юллар аша башкарып була – гадәти автоюллар яисә H-Banh технологиясе буенча җир өсте транспорт системасы (соңгысы үз вакытында аэропортка илтүче аэроэкспресс линиясенә альтернатива буларак тәкъдим ителгән иде) ярдәмендә.

– Владимирга һәм Чебоксарга ЮТМ керми. Һәм, сүз уңаеннан, анда перспективада шәһәрне магистраль ягына үстерү күздә тотыла, – дип фикер йөртә Гобәев. – Түбән Новгородта магистраль аэропортка бәйләнә. Ә бездә ни өчендер турыдан-туры шәһәргә кертергә телиләр. Әйе, Казан кырыена килеп җитеп, поездда чыгып, шунда ук метрога утыру бик уңайлы. Ләкин моның өчен 13 километрлы эстакада төзү кирәкме?.. Соңга калганчы, эксперт җәмәгатьчелеге иң кулай вариантны сайларга тиеш.

Шул ук вакытта, Siemens немец концерны ЮТМдә «Сапсанның» тизлеген сәгатенә 400 км га кадәр арттырырга сәләтле яңартылган версиясен куллануны тәкъдим итә. Ә РТЮ поездның беренче тышкы һәм эчке эскизларын тәкъдир итте, аларны эшләү белән Россиянең «Синара» машина төзелеше компаниясе һәм China CNR Corporation Кытай компаниясе шөгыльләнә. Проект буенча, һәр поезд 743 пассажирны сыйдырырга сәләтле 12 вагоннан торачак. Урыннарның шактый зур өлеше – 380 – иң арзан, туристик класска карый.



ИСЛАМ АКАДЕМИЯСЕ ИДЕОЛОГИК КӨРӘШ ИНСТРУМЕНТЫ БУЛАРАК

Камил хәзрәт Сәмигуллинны Болгар ислам академиясе идеясенең авторы дип атау мөмкин түгел – беренче тапкыр ул хакта моннан ике дистә ел элек ишетелгәнгә күрә булса да, ул чакта Татарстан мөфтие әле бала гына булган. Әмма Татарстан мөселманнары лидеры бу фикерне актуальләштерде һәм бер уңайдан, рәсми телгә күчергәндә, аны тормышка ашыру өчен җаваплылыкны алды.



Автор:
Айдар Сәгъдиев

Узган ел, ниһаять, бу проектка старт бирелде һәм шундый планка куелды: яңа вуз (чынлыкта – магистратура) дөньяви дәрәҗәдәге фәнни-белем бирү үзәгенә әвереләчәк. Эш гигантлыкка омтылуда түгел, ә бәлки аннан кечерәкне оештыруның мәгънәсе булмауда; чөнки кечерәге дин галимнәре булырга теләгән Россия мөселманнарының аңы, ә ахыр чиктә – бөтен өммәтнең аңы өчен барган идеологик көрәштә оттыруга дучар булачак. Төрледән-төрле, аерым алганда, мәгълүмати фронтлардан алынган белешмәләргә караганда, мондый сценарийны уздырмау Россиядә көннән-көн актуальрәк була бара.

Ягъни Болгар ислам академиясе – моны беркем дә яшереп тормый – барыннан да элек идеологик көрәш инструменты буларак карала. Мондый күзлектән караганда, Татарстанның яшь мөфтие һәрьяклап туры килергә тиеш.

ЧӘЙ ЯНЫНДА АҢНАР ӨЧЕН КӨРӘШ

Шунысын да искә төшереп үтик: Татарстан Диния нәзарәтенең 28 яшьлек җитәкчесе бу вазыйфага шактый катлаулы вакытта килде. Ул чакта, 2013 елның апрель аенда, элгәреге мөфти Илдус Фәйзовка һөҗүм оештырылуыннан һәм аның урынбасары Вәлиулла Якупов үтерелүеннән соң, берничә генә ай үткән иде. Мондый очракта яшь рухи лидер үзен ничек тотарга тиеш? «Үч алырга» һәм басым ясарга керешсәң (вакыйгалар мантыйгы Фәйзовны нәкъ шуңа этәрә иде) – «убырлыларга ау оештыру»да гаепләячәкләр, экстремизмга каршы тиешенчә кырыслык күрсәтмәсәң – экстремистлар Татарстанны үзләре өчен йомшак һәм татлы тәгам дип кабул итәчәк.

Әмма яңа мөфти шунда ук берничә төгәл адым ясады һәм бөтен кеше аңларлык сигналлар җибәрде. Иң элек ул үзеннән алдагы мөфтидән һәм башка дин әһелләреннән хәерфатиха алды, моның белән ул сүзнең варислыкны өзү турында бармаганын һәм мондый кырда идеологик чайкалышларның булмаска тиешлеген күрсәтте. Икенче яктан, ул төзәлү юлына басарга теләмәгән радикаллар белән диалогның мөмкин түгеллеген, ә башкалар белән аның мөмкин генә түгел, һичшиксез кирәк булуын белдерде. «Татарлар – шундый халык, без һәрбер мәсьәләне диярлек чәй янында хәл итә алабыз, – диде ул чакта Камил хәзрәт. – Без мөселманнарны берләштерергә тиеш, тик кемдер куйган шартларда түгел, ә бәлки хәнәфи мәзһәбе (исламдагы дүрт хокукый мәктәпнең берсе, татарлар өчен ул традицион санала – ред.), татар дин гыйлеме мирасы кысаларында».

Сүз уңаеннан, хәнәфи мәзһәбе шактый консерватив, берсүзсез аңа буйсыну бервакыт мөфтине ретроградлыкта гаепләүгә барып җитә язды. Ул чакта Камил хәзрәт мәзһәбкә нигез салган Әбү Хәнифәнең шахмат уенын «мәкърүһ» (гөнаһка якын гамәл) дип санавы турындагы җөмләсен искә алган иде. Әбү Хәнифә, эшкә яисә социаль проблемаларны хәл итүгә зыян китереп, уен белән мавыгучыларны гаепләгән, – дип аңлаткан ул чакта мөфти. – Ә бу «кейс»ның үзен безнең көннәрдә галимнәр тикшерергә тиеш (шулай да мөфти үзе шахмат уйнамый).

Моннан тыш, мөфти үзенең хезмәтен «гуманлаштырырга» тырышты. Әйтик, бу күрмәүчеләр өчен «Ярдәм» мәчете һәм укытутернәкләндерү үзәге ачу кебек проектларда чагыла һәм, әлбәттә, исламның уңай имиджын булдырырга ярдәм итә. Аның социаль челтәрдәге шәхси битен дә вакыйгалар турындагы хисап дип кенә кабул итеп булмый. Соңгы биш «пост»ны алып карыйк: «Якын Көнчыгыштагы ялган ислам дәүләтенең иблис характеры» турында халыкка биш минутлык видеомөрәҗәгать; Апас районы имамнары һәм дин тотучылары алдында укылган вәгазьдән берничә фоторәсем: Камил Сәмигуллинның күптән түгел басылып чыккан «Каберләрне зиярәт кылу. Шәригать кушканнар һәм әдәп кагыйдәләре» китабын шәрехләү; Мәскәүдәге «динара футбол матчы»ннан фоторепортаж»; Зәй районында татар галиме һәм мәгърифәтчесе Таҗетдин Ялчыгол каберен зиярәт кылудан фотосурәт. Анда хәзрәтнең арткы пыяласына Коръән аяте язылган беренче машинасының (Дэу Нексия) фотосы да куелган, ә аять мондый: «Аллаһы Тәгалә әйтә: «Миңа гына гыйбадәт кылыгыз һәм ата-анагызга итагать итегез».

БЕЗ АКАДЕМИЯЛӘР БЕТЕРМӘДЕК. ӘЛЕГӘ

Узган ел Татарстан мөфтие идеологик кырда актив рәвештә уңай чагылырга тырышты. Гыйнвар аенда ул француз сатирик журналында пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (с.г.в.) ясалган карикатураларга каршы чынлыкта программ (һәм шактый кискен) белдерү белән чыкты. Ул аларны бөтен кешелеккә һәм беренче чиратта исламга китереп сугу дип атады, «дөньяның кайбер төбәкләрендә» гамәлдә булган ике төрле стандартлардан ваз кичәргә чакырды: «афроамериканны мыскыллау – бу расизм, яһүдне мыскыллау – антисемитлык, ә кайберәүләр, 1,7 миллиард мөселманны мыскыллап, моны «сүз иреге» дип саный». Узган елның сентябрь аенда ТР Диния нәзарәте башлыгы үзенең инстаграмында тагын бер «карикатура»ны – суга баткан Сүрия малае сурәтен шәрехли: «Ни намус, ни кызгану, ни җаннары юк».

Ә күптән түгел «Интерфакс»ка Согуд дин эшлеклеләре төркеменең Россиягә җиһад игълан итүләре уңаеннан «Интерфакс»ка биргән комментариенда ул: «Эчке вазгыятьне тирән белгән күренекле дин галимнәре генә мондый рәвештәге диндар нәтиҗәләр ясый ала», – диде. Хәзер мөфти алдында беренче итеп академия оештыру мәсьәләсе куела икән, аның турыдан-туры бурычы – «эчке вазгыятьне аңлаучы» дин галимнәре әзерләү.

Шунысын да искә төшерик: борынгы Болгар шәһәрендә академия ачу идеясен беренче булып РФ мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин узган гасырның 90нчы елларында, Россиягә чит илләрдәге мөселман вузларын тәмамлаучылар кайта башлагач тәкъдим иткән иде. Бу мәсьәлә шул вакыттан бирле өлгереп килә. 1998 елда Казанда бакалавриат дәрәҗәсендә белем бирүче Россия ислам институты ачылды, әмма, аны тәмамлап, магистр дәрәҗәсен алырга теләүчеләр барыбер чит илләргә җибәрелде – илдә алар өчен көндәшлеккә сәләтле белем бирү мохите юк иде.

Узган елның 4 ноябрендә Татарстан Президенты Болгар ислам академиясе ачу турындагы указга кул куйды. Бу елның беренче яртысында бинага нигез салынырга тиеш. Академия базасында шулай ук Россиянең мөселман галимнәре союзы (монысы мөфтинең шәхси инициативасы), фән-мәгариф үзәге, ислам китапханәсе, экспертлар советы, татар дин гыйлеме мирасын өйрәнү үзәге, динара диалог үзәге һәм башка структураларның эшләве дә күздә тотыла. Хәзер иң мөһим бурыч – белем бирүне һәм башка процессларны дөрес итеп төзү һәм эчтәлек белән тулыландырудан тора.



Фото: domrt.ru

Сыйфатлы дин белеме бирү – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең өстенлекле юнәлеше

2 ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга «Татарстан»нан 2 төп сорау:

– Сезнеңчә, Болгар ислам академиясе мөселман дөньясында абруйлы уку йортына әверелсен өчен, күпме вакыт кирәк булачак?

– Халыкара абруйны бер ай яисә ел дәвамында яулап алу мөмкин түгел, моңа биш, ун ел кирәк булырга мөмкин, тик бу безнең үзмаксат түгел. Иң мөһиме – РФнең әйдәп баручы дини оешмаларын кадрлар белән тәэмин итәчәк көчле Россия дини белем мәктәбен булдыру. Болгар ислам академиясендә эшләү өчен, без дөньяның иң эре һәм абруйлы дин белгечләрен җәлеп итәчәкбез, ә укыту программалары дөньяның иң яхшы уку йортларындагы заманча мөселман мәгарифе стандартларына туры китереләчәк. Болгар ислам академиясе XXI гасырда кешелекнең заманча проблемаларына һәм каршылыкларына дини күзлектән җавап бирә алачак «белем йорты»на әверелергә тиеш.

– Болгарда ислам академиясен ачу планы турындагы хәбәрне гомумән Россия өммәте («гади» инанучылар да, мөселманнарның диния нәзарәтләре җитәкчеләре дә) ничек кабул итте?

– Әлбәттә, илһамланып, шул уңайдан Россиядәге тулаем мөселман өммәте белән дә. Сыйфатлы дин белеме бирү – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең өстенлекле юнәлеше. Бөтен үзәкләшкән мөселман дини оешмаларына квалификацияле кадрлар кирәк. Россиядә соңгы 20 елда 7000нән артык мәчет ачылган. Кызганычка, белгечләр җитешмәгәнлектән, еш кына имамхатыйп вазыйфасын дини дә, дөньяви да белеме булмаган кешеләр башкара, һәм бу традицион булмаган исламның таралуына китерә. Россиянең бөтен мәдрәсәләрендә укыту ысулларын стандартлаштыру һәм бердәйләштерү, һәм шулай ук Болгар ислам академиясен ачу мөселман мохитендә экстремизм һәм дини түзеп тора алмаучылык мәсьәләләрен сизелерлек дәрәҗәдә хәл итәргә тиеш.

ПЕНСИЯ ЯШЕ ТУРЫНДА ТАГЫН БЕР КАТ

Пенсиягә чыгу яшен арттыру турында халык арасында барган дәвамлы, катлаулы фикер алышуларның нәтиҗәсе (аның даими геройлары һәм дәлилләре күптән барлыкка килде инде) Президентның: әлегә арттырмыйбыз, әмма истә тотабыз, киләчәктә күз күрер, дигән йомгагына кайтып калды.



Автор:
Рөстәм Шакиров


Россиядә ир-атларның якынча өчтән бере 60ка да җитми. Ә хатын-кызларның һәр унынчысы 55 яшькә кадәр яши алмый. Әгәр мәсьәләгә циникларчарак карасак, «яшәп җиткерә алмаучылар» никадәр күбрәк булса, РФ Пенсия фонды өчен шулкадәр әйбәтрәк. Табигый ки, россиялеләрнең гомер озынлыгы тагын да кимрәк булуын беркем теләмәячәк, әмма мәсьәләгә икенче яктан якын килергә була: пенсиягә 5 ел соңрак чыгу аңа дәгъва кылучыларны 1,5 мәртәбә киметәчәк. Бүгенге көндә РПФндагы дефицитны (2016 елда 1,6 трлн сум тәшкил итәчәк) бюджеттан ябарга мәҗбүр булган дәүләт өчен, турысын әйткәндә, кызыктыргыч план.

Мәсьәләнең катлаулылыгы кайбер шартлар белән каршылыкка керүдән гыйбарәт: РФ Конституциясенең Россия дәүләтенең социальлеген гарантияләүче 7нче маддәсе кебек ачыктан-ачык күренеп торучылары белән генә дә түгел. Әйтик, пенсиягә чаклы яшәп җиткерү ихтималлыгы нибары 50 процент кына, ә лаеклы ялга чыккач, 5 кенә ел булса да яшәп калу мөмкинлеге тагын да азрак икәнлеген эчтән генә аңлаган иратларның саны күбәергә мөмкин, ә алар инде эш бирүченең югары, әмма соры хезмәт хакы түләүгә күчү турындагы тәкъдименә бигүк каршы килмәсләр дә. Җитмәсә, әлеге уңайдан алар моңарчы да артык зур ризасызлык күрсәтмәде. Ә бу инде янәдән РПФ акча җыеп бетерми һәм йомык әйләнә буйлап хәрәкәтләнә, дигән сүз.

ӘГӘР БЕРНИ БУЛЫШМАСА, НИҺАЯТЬ, ИНСТРУКЦИЯНЕ УКЫГЫЗ ИНДЕ

Россия Хөкүмәтенең «либераль» блогы хезмәт яшен озынайтуның бүгеннән үк кирәк икәнлегенә халыкны ышандырырга тырыша. Болай дип әйтү өчен, чыннан да объектив сәбәпләр бар: пенсиягә чыгу яшенең Европа илләренеке белән чагыштырганда баштан ук түбән булуы, россиялеләрнең гомер озынлыгы (2018 елга чаклы 74 яшьтән ким булмас) һәм пенсионерлар саны арта баруы (1991елдан башлап, алар өчтән бергә күбәйгән, бер үк вакытта халык саны 5 млн га азайган), шулай ук РПФна акча күчерү күләме кимүе.

«Әйе» дип әйттерерлек башка дәлилләр дә бар, алары көйләүләргә бәйле. «Пенсия реформасы лабораториясе» проекты җитәкчесе, Европа Пенсия фонды директорлар советы рәисе Евгений Якушев: «Индексацияләү һәм пенсияләр түләү дәүләтнең бурычы икәнлеген аңларга кирәк. Пенсиягә чыгу яшен озынайтмасак, салымнарны арттырырга туры киләчәк, – ди. – Ә бу исә хезмәт хакы түләү фондына тәэсир итәчәк, эш хакы күләме кимергә мөмкин». Ягъни әгәр гражданнар лаеклы ялга элеккечә үзләре теләгән (күпләр өчен) 55-60 яшьтә чыгарга ниятләсә, шуңа чаклы азрак хезмәт хакына яшәячәк. Яисә «аннан соң»гы чорны – азрак пенсия белән. РФ икътисадый үсеш министры Алексей Улюкаев өчен, теоретик яктан караганда, монысы да килеп туган хәлдән чыгу юлы. Ул узган елның декабрендә: вакыйгалар нәкъ менә шулай үсеш алыр, дип куркытты. Пенсиягә



«Индексацияләү һәм пенсияләр түләү дәүләтнең бурычы икәнлеген аңларга кирәк. Пенсиягә чыгу яшен озынайтмасак, салымнарны арттырырга туры киләчәк. Ә бу исә хезмәт хакы түләү фондына тәэсир итәчәк, эш хакы күләме кимеячәк»

Фото: fotolia.com



Иллюстрация: Леонид Баранов. «Деревенские великаны»

Пенсиягә чыгу яшен күтәрү процессын пенсияләр күләмен (хәзер объектив рәвештә югары булмаган) арттыруга бәйләсәк, җәмәгатьчелек аны уңай кабул итәчәк.

чыгу яшен арттыруның иң яхшы карар булачагына ишарәләп, министр: «Әмма минемчә, бу альтернатива – социаль, сәяси, икътисадый мәгънәдә отышсыз гамәл», – дип искәртте.

Шулай да, «арттыручылар» совет собесы казанышының берсенә һөҗүм итү нинди дә булса бонуслар рәвешендә компенсацияләнергә тиеш, дип саный. Якушев: ПЧЯА процессын пенсияләр күләмен (хәзер объектив рәвештә югары булмаган) арттыруга бәйләсәк, җәмәгатьчелек аны уңай кабул итәчәк, дип фаразлый. Бу өлешчә алганда хәтта «үзеннән-үзе шулай килеп чыга». «Әйтик, кеше пенсиягә 60та түгел, 62дә чыга. Эш бирүче әлеге ике ел дәвамында пенсия кертемнәре түләп бара, ул кеше лаеклы ялга чыккан вакытта, 60 яшьтә пенсиягә киткәнгә караганда, аңа күбрәк «тама».

«Х» яшенә җитеп килүчеләрне эш белән тәэмин итү программасын эшләү тагын бер компенсация механизмы була алыр иде, дип саный 49 яшьлек Мөршидә. «Хәзер эш югалту бик җиңел. Яңасын да тиз табарга була, ләкин сиңа 25 яшьләр тирәсе булса гына, – ди ул. – Иремә 54 кенә тулса да, вакансия булса да, ничә яшьтә икәнлеген белүгә, аны беркая да эшкә алмыйлар. Гомумән алганда, йә хезмәт хакыңны кимрәк аласың, йә бөтенләй эш таба алмыйсың».

ПЕНСИЯБЕЗ ТӨЗЕРГӘ ДӘ, ЯШӘРГӘ ДӘ БУЛЫША

Пенсиягә чыгу яшен күтәрүгә каршылар, әлеге һәркемне борчыган өлкәдә бернәрсәне дә үзгәртмәс өчен, дәүләт әле бөтен мөмкинлекләреннән файдаланмады, дигән фикердә нык тора. «Әлеге дә баягы Европа белән чагыштыруда күпмедер хәйлә бар, кешеләр бу мәкерне сизә, – дип саный блогер Иван Чернов. – Әйтик, керемгә салымның прогрессив шкаласын гамәлгә кертергә була. Европаның алдынгы илләрендә пенсиягә бик соң чыгалар, әмма аларда физик затларга салым күпкә гаделрәк салына. Безнең очракта, әгәр монда тәртип урнаштырсак, ягъни байларның салымнан качуын туктатсак, бу үз нәтиҗәсен бирер иде».

Социология фәннәре докторы, КФУ профессоры Андрей Ершов, Россиянең иң яңа тарихында моның өчен күпкә кулайрак хәлләр булганын күздә тотып: бүгенге көндә пенсиягә чыгу яшен күтәрү өчен, 90нчы еллар азагындагы кебек җитди нигез юк, дип саный. Ул чакта болай да хәлсезләндерелгән икътисад тәмам таркалган, эшсезлек нык арткан, илнең еллык бюджеты 20 млрд доллар тәшкил иткән иде. Ершов, 1999 елның мартында РФ Хөкүмәте аппаратының Социаль үсеш департаменты җитәкчесе, танылган икътисадчы Евгений Гонтмахерның үзенә, дефолт кичергән Көньяк Америка илләре кебек үк, Россия дә пенсия белән тәэмин ителешне туктату ихтималлыгы алдында тора, дип әйтүен искә төшерә. «Илдә мондый вазгыять тагын бер-ике ел дәвам итсә, шулай булачак та, дип фаразлаган иде ул чакта, – дип сөйли Ершов. – Пенсия түләү бөтенләйгә юкка чыккан булыр иде, дип уйламыйм, әлбәттә. Әмма гражданнарның кайбер категорияләренә чыннан да бик авырга туры килер иде. Болай да бик аз күләмле пенсияләрне арттыру турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде».

– Башкарма хакимият әледән-әле, икътисадыбыз тотрыклы, кризис белән санкцияләргә бирешми, дип тынычландырып тора, – ди Ершов. – Шулай булгач, бөтен халыкка кагылганны нигә кинәт үзгәртергә? Икенче чиккә китү дә күзәтелә: икътисадый үсеш булмавын, бюджет тишек-тошыкларын сылтау итү. Бусы гомумән иң җиңел юл. Бары тик салымнар җыюны, хезмәт җитештерүчәнлеген, югары технологияле экспорт күләмен һ.б. арттыру өстендә эшләргә кирәк. Финанс өлкәсен, аеруча шәхси компанияләр тарафыннан кире кайтмаслык итеп чит илләргә чыгарылучы акчаларга бәйлесен, тәртипкә салу зарур. Илдә акча бар, аннан дөрес файдаланырга гына кирәк.

Билгеле булганча, ПЧЯАны әлегә ил, төбәк, муниципаль дәрәҗәләрдәге түрәләрдә сынап карыйлар. Владимир Путин үзенең былтыр декабрьдә булып узган «зур» матбугат конференциясендә, әлеге гамәлнең фискаль нәтиҗәсе аз дип, турыдан-туры әйтте. Шулай булгач, бу яңалыкны гамәлгә кертүне «озаграк эшләргә мораль яктан әзер булучылар»дан (РФ Премьер-министры Д.Медведев сүзләре) башлауның мәгънәсе калганнарга: дәүләт хезмәткәрләре эшләвен дәвам итә бит әле, зарар юк, керешеп киттеләр, дип әйтүдән гыйбарәт.

Без Ершовтан, бу хәл дәүләт һәм муниципаль хезмәттәге кадрлар вазгыятенә тәэсир итәчәкме, дип сорадык. ТР Президенты каршындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә академиясен озак вакыт җитәкләгән, шуның өстенә күптән түгел үзе дә дәүләт хезмәткәре буларак пенсиягә чыккан Андрей Николаевич фаразлавынча, барыбер сизелерлек зур нәтиҗә булмаячак.

– Пенсиягә чыгарга аз вакыт калган хезмәткәрләр беркадәр аптырашта, билгеле, – ди эксперт. – Күпләр дәүләт хезмәтендә нәкъ менә лаеклы пенсиягә өметләнеп эшләде бит. Ә хәзер алар уйга калырга мөмкин. Үзегез уйлап карагыз. Әйтик, элеккеге табибә, 51 яшьлек ханым. 40 яшендә сәламәтлек саклау министрлыгына яки шул юнәлештәге шәһәр идарәсенә эшкә килгән. Анда баш белгеч яки бүлек мөдире урынбасары булып эшләгән, лаеклы ялга чыкканчы, биредә хезмәт итәргә тиешле вакыты унбер ел булуы аны канәгатьләндергән. Әмма хәзер дәүләт хезмәткәре пенсиясен алу өчен, аңа 4 түгел, ә 14 ел эшләргә туры килмәгәе (РФ Дәүләт Думасында төрле вариантлар, шул исәптән шактый ук «йомшак»лары – пенсиягә чыгу вакытын әкренләп, бер елга арттыра бару карала). Ул баш табиб яки аның урынбасары булып эшләргә китеп барырга мөмкин, әлбәттә. Өстәвенә, анда һөнәри яктан канәгатьләнү алу мөмкинлеге зуррак, хезмәт хакы җәһәтеннән дә оттырмавы ихтимал.

СӘЛАМӘТ КЕШЕ ҺӘМ ТӘМӘКЕЧЕ ПЕНСИЯСЕ

Либераль икътисадчыларның еш кына тормыш чынбарлыгын очраклы хәлгә санавын искәртеп, икътисадчы Илсур Гатауллин ПЧЯА мәсьәләсен кәгазьгә түгел, ә соры хезмәт базарындагы вазгыятькә чумып анализларга чакыра.

– Аңлыйсызмы, бүгенге көндә пенсиягә чыгу яшен йөзгә кадәр күтәрсәң дә, мәгънә булмаячак, – ди ул. – Пенсия мәсьәләсендә бары тик кемнең салым түләве, кайсының түләмәве, һәр икесенең нинди проблемалары барлыгы турында утырып уйларга, аларны ничек хәл итеп булуын ачыкларга кирәк. Ә аннан соң ТКХ, төзелеш, дәүләт сатып алулары өлкәләренең һәркайсы өчен аерым, эшли торган чаралар булдырырга. Әйтик, хәзер ТКХ өлкәсендә күп субподрядчылар хезмәткәрләренә «кара» эш хакы түли. Мин барлык идарәче компанияләргә субподряд килешүләрен махсуслашкан мәйданчыкларда (субподрядчылар рәсми теркәлгән урында) һәм бары тик кулында ачылган эш урыннары булган компанияләр белән генә төзергә тәкъдим итәр идем. Һәм компания кайсы күбрәк НДФЛ һәм пенсия кертемнәре тәкъдим итә, ИК белән шунысы килешү төзи. Бүгенге көндә әлеге 538 мең кеше үз пенсиясенә үзе эшләп таба. Исегезгә төшерик, узган елның маенда РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов эшсез дип саналган хезмәт яшендәге татарстанлыларның 538 мең кеше булуын әйтте (23 процент чамасы). Араларында хуҗабикәләр бар, әлбәттә, әмма күпчелеге – соры керем алучылар. Еллык статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, 2014 елда ТРнда шундый 350 мең кеше (2010 елда йөз меңгә күбрәк) булган. Күбесенең кече бизнес предприятиесендә эшләве аңлашыла. Болары да булачак пенсионерлар, әмма алардан бюджетка һәм РПФна бер тиен дә керми. Гатауллинның бәяләвенчә, Татарстанның шуңа бәйле еллык югалтуларының 16–17 млрд сумы – НДФЛ, 40 млрд чамасы – социминиятнең пенсия өлеше.

Җаваплы затлар аларны легальләштерергә кирәклеген аңлый, аеруча хәзер – кулланылмаган теләсә кайсы мөмкинлекне җентекләп күздән кичерергә туры килгәндә. Нигездә бүгенге көндә ул хезмәт килешүе булмаган хезмәткәрләрне ачыклау аша, шул исәптән, халыктан, контрольлек, хокук саклау органнарыннан, профсоюзлардан, төрле базаларны анализлаудан кергән мәгълүмат буенча башкарыла. Хезмәт килешүе төзүдән качкан юридик затка салынучы штрафның иң зур күләме элек 50 мең сум булса, 2015 елдан башлап 200 меңгә җитте.

Әмма проблема шунда: кагыйдә буларак, кризиста күләгәдәге сектор үсә. «Нихәл итәсең, икътисадның дәүләт тарафыннан кырыс көйләнүле, планлаштырулы мобилизация вариантын кулланырга туры киләчәк, – ди Гатауллин. – Сүз дә юк, кырыс модель, «базарның күзгә күренми торган кулы» белән бернинди уртаклыгы юк. Әгәр барысын да үзгәрешсез калдырсак, 2016 елда бездә 538 мең түгел, ә 700 хезмәт иясе соры зонада калачак».

Һәм монысы, экспертлар бу система эшчәнлеген гамәлгә ашыруны иминиятләштерү принцибына әйләнеп кайтып, ягъни үз-үзеңне тәэмин итү юлы белән башкарырга өндәгән мәлдә. «Хәзер пенсия системасы иминият кималендә түгел; Россиядә пенсиянең яртысы федераль бюджеттан, калганы иминият кертемнәреннән түләнә, – ди Якушев. – Еш кына халыкның бу катламы бер тиен дә иминият кертеме түләми, әмма бер үк вакытта киләчәктә дәүләттән пенсия алырга өметләнә. Болай эшләүчеләр пенсияләренең минималь яшәү дәрәҗәсе чаклы гына булачагын аңларга тиеш».

Белгечләр бәяләвенчә, икътисадый яктан актив халкы 70 млн булган РФндә мондый кешеләр саны 20 млннан артык.

Бу мәкаләне әзерләгәндә шундый кызыклы фактка тап булдык: пенсиягә чыккач, үз тормышын төрләндерергә җыенучылар арасында ир-атлар бөтенләй диярлек юк икән. Активлары эшләвен дәвам итә, ә калганнары, ягъни актив булмаганнары, пенсиясенә сөенеп утыра.

Еш кына халыкның бу катламы бер тиен дә иминият кертеме түләми, әмма бер үк вакытта киләчәктә дәүләттән пенсия алырга өметләнә.



Иллюстрация: Юрий Клапоух. «Серьёзные намерения»

PRESSA.RU

һәр шимбә
20.30



ТНВ
ТАТАРСТАН

бәйге
КАРАОКЕ
battle





12+

Реклама

РОМАН ЕГОРОВ, «РОМИНО» ҺӘМ «СКАВОЛИНИ» САЛОННАРЫ ХУҖАСЫ:

– Безнең тормышта гаилә традицияләре, мәдәният, якыннарыңның яратуы кебек үзгәрмәс кыйммәтләр бар. Бик күп гаиләләрдә, минемчә, күңелгә якын, буыннан-буынга күчеп килгән бизәнү әйберләре, савыт-саба, йорт җиһазлары сакланадыр. Ата-бабалар истәлеге, нәселебезне бәйләүче бер җеп булып тора. Әгәр инде мондый әйберләр сакланмаган икән, хатирәләребез яши – бәйрәм көннәрендә әнинең сервантган бизәкле савыт-сабаны яисә балаларга кагылырга рөхсәт ителмәгән таш сыннарны чыгарып куюы турында.



Безнең бүгенге бер көнлек әйберләр гасырында да гаилә традицияләрен булдырырга мөмкин. Монда, әйтик, коллекцион фарфор ярдәмгә килә ала – күпьеллык тарихка ия кечкенә гаилә фабрикаларында кулдан ясалган искиткеч нәфис фарфор предметлар алар. Берьюлы зур сервиз сатып алырга димәгән – ниндидер уңай белән яисә кадерле кунакларны сыйлаганда кулланырлык берничә пар чынаяк алырга да була бит.

Шәхсән үзем Италиянең культ бренды Villari коллекцион фарфорын тәкъдим итәр идем. Villariның тарихы Сильвия һәм Чезаре Виллариларның мәхәббәт тарихыннан башлана. Алар икесе дә фарфор җитештерү фабрикасында эшләгән һәм 1965 елда өйләнешкәннәр. 1967 елда аларның фарфорга мәхәббәте һәм эшмәкәрлек рухы Соланья шәһәрендә (Венециядән 70 чакрымда) үз фабрикаларын ачарга мөмкинлек биргән.

Коллекцион фарфор җитештерүнең уникаль технологиясе – бу Villari гаиләсенең кыйммәтле мирасы. Ә безнең бу затлы әйберләргә ия булу һәм аларны, истәлек өчен, балаларыбызга һәм оныкларыбызга тапшыру мөмкинлегебез бар.

Реклама



РОМИНО
ИНТЕРЬЕРЫ ИТАЛИИ

«Ромино» һәм Skavolini Италия
җиһазлары, кухнялары һәм
интерьерлары салоннары
Казан шәһәре, Чистай урамы, 61-б,
тел: +7 (843) 203 93 07

Skavolini Италия җиһазлары кухнялары
һәм интерьерлары салоны
Симферополь шәһәре,
Киров проспекты, 7-а.
тел: +7 (3652) 60 08 79

salon@romino.ru
www.romino.ru

«КВАРТ» ЯҢА ОРБИТАГА ЧЫГА



Декабрьдә «КВАРТ» АҖ ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында яңа резиналарны кушу линиясен эшләтеп җибәрде, ә ул исә предприятиенең җитештерү куәтен арттырып, елына 6 мең тоннага кадәр резина эшләнмә җитештерү мөмкинлеген тудырды. Бу – заводны тулысынча яңадан техник җиһазлауның беренче адымы гына әле.

1942 елда нигез салынган, бүгенге көндә акционерлык җәмгыяте булган «КВАРТ» – резина-техник эшләнмәләре җитештерүче иң эре предприятиеләрнең берсе. Ул 7 меңнән артык төрдәге эшләнмәләр җитештерә, шулар арасында нефть, автомобиль сәнәгате һәм төзелеш җиңсәләре, автомобиль пыялалары һәм метрополитен тоннельләре тыгызлагычлары, герметиклар, техник пластиналар, термоэластопластлар, шулай ук РФ Оборона министрлыгы заказы буенча җитештерелүче махсус эшләнмәләр. Бораулау скважиналары җиңсәләре – заводның аерым бер горурлыгы, чөнки аны Россиядә һәм БДБ илләрендә бары тик «КВАРТ» АҖ генә эшләп чыгара.

Әмма яңа икътисадый чынбарлык продукция сыйфатына аерым бер таләпләр куя. Ә резина эшләнмәләрнең сыйфаты – барыннан да бигрәк ярымфабрикатлар – резина катнашмалары сыйфатына бәйле. 2014 елда предприятие алдында тулысынча яңарту-үзгәртеп кору зарурияте килеп басты. Икътисадый вазгыятьнең катлаулы булуына карамастан, «КВАРТ» АҖ резина кушуның яңа җитештерү линиясен урнаштыруга 500 миллион сум тотарга булды. Моңдый модернизация юлын үткән коллегалары тәҗрибәсен өйрәнеп, тәэминатчыларны җентекләп эзләделәр. Нәтиҗәдә, «Мицубиси» корпорациясенә керүче «Кобэлко» япон компаниясеннән һәм «Солмек», «Колмек», «Продикон» итальян компанияләреннән иң заманча резина кушу җиһазлары сайлап алынды.

Рөстәм Миңнеханов яңа линиянең ачылышына ТР Премьер-министры урынбасары вазыйфаларын башкаручы – ТР сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримов, ТР икътисад министры Артём Здунов, ТР Президенты ярдәмчесе Ринат Сабировтан торган вәкиллекле делегация озатуында килде. Җитештерү мәйданнары буенча экскурсияне «КВАРТ» АҖнең генераль директоры Рафаэль Галимов үткәрде.

Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты:

– «КВАРТ»ның эшләп чыгару күләменең үсүен, керемнәренең артуын, предприятиенең Россия базарында төп урыннарны биләвен телисе килә. Ә моның өчен җитештерү куәтен яңартуны дәвам итәргә кирәк.

Резина кушу цехында кунакларга җитештерү егәрен елына 6 мең тоннага арттыру мөмкинлеге тудыручы яңа җиһазларны аерым бер горурлык белән күрсәттеләр. Югары тизлекле резина кушу җайланмасы кушылмаларны автомат рәвештә биреп тору системасы, резиналарны стрейнирлаштыру һәм суыту линияләре белән тәэмин ителгән. Резина җитештерү җиһазларының су белән тәэмин итүнең ябык системасына тоташтырылган булуы аларның суыну нәтиҗәлелеген арттыра һәм кулланылган суларны агызып чыгару күләмен киметә.

ТР Президенты «КВАРТ» Акционерлык җәмгыяте һәрвакытта зур хезмәт сорый торган катлаулы җитештерү белән дан тотуын билгеләп үтте. «КВАРТ»ны яңартуны дәвам итәргә ниятләгәннәр инде. Модернизацияләүнең икенче-өченче этаплары якындагы ике елда башкарылачак. Завод резина кушу линияләрен тулысынча техник җиһазландырып бетерергә һәм, 2018 елдан башлап, елына 20 мең тонна резина катнашма эшләп чыгару куәтенә ирешергә ниятли.

«КВАРТ» АҖнең уңыш нигезләре аның 70 еллык хезмәт юлына, эшче һәм белгечләренең югары һөнәрилегенә, башкарган эшләренә мөнәсәбәтенә бәйле. Бу хакта предприятиенең генераль директоры Рафаэль Галимовтан да дөрес һәм төгәлрәк әйтеп булмыйдыр: «Завод – өебез, коллективы – гаиләбез ул. Һәм без аны яхшырак, уңайлырак, ышанычлырак итәргә омтылабыз».

«КВАРТ» АҖнең төп заказчылары: КамАЗ, НефАЗ, «Соллерс-УАЗ», АвтоВАЗ, ГАЗ, «Татнефть», «Сургутнефтегаз» ААҖ, Казан вертолёт заводы, РТЮ һ.б.

Реклама

СЫЙФАТКА – БЕРЕНЧЕ УРЫН!

2015 елның 18 декабрендә ТР Министрлар Кабинетында сыйфат өчен ТР Хөкүмәте премияләренә 11нче республика конкурсы лауреатлары һәм дипломантларын котлау тантанасы булып узды. Җиңүчеләргә бүләкләрне ТР Премьер-министры Илдар Халиков тапшырды.













– Узган вакыт арасында конкурс предприятие һәм оешмаларның үз эшчәнлекләрен бәяләүдәге нәтиҗәле механизмын булдырып кына калмады, ә бәлки ышанычлы партнерлар һәм сыйфатлы товарлар җитештерүче һәм хезмәт күрсәтүчеләрне эзләүдә базар гидына да әверелде, – дип билгеләп үтте Татарстан Премьер-министры.

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы башлыгы Альберт Кәримов 2015 елда конкурска 61 оешмадан гаризалар керүе турында сөйләде. Аеруча инициативалылар арасында – Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск предприятиеләре. Конкурста машина төзү, нефть химиясе, сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр, төзелеш һәм мәгариф тармаклары вәкилләре актив катнашты.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен тапшыру советы конкурсның 7 лауреатын һәм 13 дипломантын билгеләде.

Алар 2015 елның сыйфат өчен Татарстан Хөкүмәте премияләре лауреатлары булды:

- «Органик синтез» Гавами акционерлык җәмгыяте,
- «КамАЗ» ГАҖнең Тимерчелек заводы,
- «ТАНЕКО» АҖ,
- «ТаграС – РемСервис» ҖЧҖ,
- «Бәкер» шифаханәсе Профсоюзларның дәвалау-профилактика учреждениесе,
- «Система-Сервис» идарәче компаниясе» ҖЧҖ,
- «МХ 1» ҖЧҖ.

Конкурс дипломантлары арасында:

- «Татнефть» ГАҖнең В.Д.Шашин исемендәге Бөгелмә механика заводы,
- «Татнефтепром» ААҖ,
- «Ваш консультант» ҖЧҖ
- «Лениногорск нефть техникумы» Дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе,
- «Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы» Дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (Түбән Кама).

















«БӘКЕРГӘ» БАРЫР ВАКЫТ!

2015 елның декабрь аенда ел әйләнәсе Татарстанда гына түгел, Россиядә дә популяр булган шифаханә чираттагы бүләгенә – ТР Хөкүмәтенең сыйфат билгесе премиясенә лаек булды. «Бәкер»нең баш табибы Марат Ибраһимов безгә шифаханәгә бирелгән бу югары бүләкнең чыгарма түгел, ә бәлки кагыйдә булуы турында сөйләде.



– Марат Фаязович, шушы көннәрдә «Бәкер» чираттагы бүләген яулап алды. Ул шифаханәдәге сервис һәм дәвалауның югары дәрәҗәсе турында гына түгел, аның популярлыгы турында да сөйли. Мондый уңышка ничек ирешә алдыгыз?

– Беренчедән, искиткеч дәвалау базасы, урнашуның уңайлы шартлары, хезмәт күрсәтүнең сыйфатын даими рәвештә яхшырту шифаханәгә илдәге иң яхшылар абруен тәэмин итте. Икенчедән, үзегез күргәнчә, без медицина тармагының яңа мөмкинлекләрен һәм технологияләрен үзләштерү буенча туктаусыз комплекслы эш алып барабыз, даими рәвештә базарны өйрәнәбез, тагын да хәрәкәтчәнрәк һәм көндәшлеккә сәләтлерәк булырга омтылабыз. Шул ук вакытта үзебезнең күпьеллык тәҗрибәбездән иң яхшыларын саклап калырга тырышабыз. Эшчәнлегебезне оештыру һәм планлаштыруга аерым игътибар бирелә. Без инде күп еллар шушы юл белән барабыз һәм, мөгаен, уңышыбызның стратегиясе дә шулдыр. Димәк, сыйфат өчен бирелгән премия бөтен коллективның тырыш, максатчан һәм озак вакытлы хезмәтенең нәтиҗәсе булды.

– Ә кунакларыгыз кемнәр?

– Ел саен без 15 меңнән артык кешене кабул итәбез. Бу сан елдан-ел үсә бара: россиялеләр өстенлекне сәламәтлек, яшьлек, матурлыкка бирә башладылар. Безгә Татарстаннан гына түгел, Самара, Чиләбе, Оренбург өлкәләреннән дә, Пермь крае, Башкортостаннан, Ханты-Манси автономияле округыннан, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсеннән дә киләләр. Үзләренең югары технологияле шифаханәләре һәм табигать гүзәллекләре булуга да карамастан, безгә чит илләрдән килүчеләр дә күп – Казахстаннан, Кытайдан, Төркиядән, Австралия һәм Азәрбайҗаннан.

– Кешеләрнең иң күп килгән чагы кайсы айларга туры килә?

– «Бәкер» өчен «сезонара» төшенчәсе юк дияргә була, шифаханә ел әйләнәсе тулып тора. Таулар, урманнар һәм күпсанлы инешләр белән әйләндереп алынганга күрә, бу җирлектә сизелеп торган дәва үзлекләренә ия булган үзенчәлекле климат формалашкан. Шуңа күрә дә шифаханә – рәхәтләнеп ял итү һәм гарантияле сәламәтләнү мөмкинлеге бирүче урын, һәм анда ел әйләнәсе килергә мөмкин.

– Ә «Бәкер»гә болай гына, алдан урын алып куймыйча, килергә мөмкинме?

– Беләсезме, безгә путевкаларны алдан ук, 1,5–2 ай кала сатып алалар, шуңа күрә номерга бронь алу хәерлерәк. Шулай эшләсәгез, «Бәкер»дә менә дигән дәвалау программасы гына түгел, башка хезмәтләрнең дә тулы комплексын алуга ныклы ышанычыгыз булачак – санаторий территориясендә тау чаңгысы комплексы, боз шугалагы, бильярд залы һәм кафе-барлар эшли. Экзотик хайваннар тотылган үз мини-зоопаркыбыз да бар.

Реклама

– Гадәттә, курортның сыйфатлы сервисы һәм киң дәвалау мөмкинлекләре аның югары бәясенә тәңгәл килә. «Бәкер»дә бәяләр диапазоны ничегәк тора?

– Без киң аудиторияне күздә тотабыз, бәяләре 5 мең сумнан башланган «люкс» номерларында vip-урнаштыруны да, туклану һәм дәвалану түләгенә 2800 сумнан башлап бәяләнүче стандарт номерлар да тәкъдим итә алабыз. Сүз уңаеннан, 2015 елның башыннан без «Карлыгач» дигән яңа йокы корпусы ачтык. Ул тулысынча дөнья стандартларына туры килә һәм иң таләпчән кунакларның да ихтыяҗларына җавап бирә ала. Шунысын да әйтим, нинди генә программаны сайласа да, безнең клиентыбыз иң югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү белән тәэмин ителәчәк.

– Сез «Бәкер»нең климат һәм инфраструктур өстенлекләре турында күп сөйләдегез. Шифаханәнең дәвалау программалары нигезендә нәрсә ята соң?

– Беренчедән, бу – Бәкер җиренең табигый үзенчәлекләре: сапропель ләмнәре һәм «Мацеста», «Нафтуся» кебек минераль сулар. Икенчедән, монысы да табигый байлыклар кебек үк мөһим фактор – безнең үз эшләнмәләребез, шулар нигезендә без төрле процедураларның тулы бер җыелмасын берләштерәбез.

– Шифаханә нинди авыруларны дәвалауда махсуслаша?

– Бу тире авырулары, таяну-хәрәкәт, аш кайнату һәм нерв системалары авырулары, ир-ат һәм хатын-кызларның баласызлыгы. Бу авыруларны дәвалау өчен без сәламәтләндерүнең традицион һәм сыналган ысулларын – минераль сулар һәм ләм ванналарын, озон һәм лазер терапиясен, бальнеодәва, арома- һәм гирудотерапияне, дәва өчен йөзү һәм башка шундый чараларны кулланабыз. Сүз уңаеннан, безнең «Бакировская» минераль суыбыз 2015 елда «Россиянең иң яхшы 100 товары» исәбенә керде.

– Ә табигый релаксация сөючеләргә «Бәкер» ниләр тәкъдим итә?

– Спа-ял сөючеләргә, мәсәлән, кедр мичкәсе, кедр «пента-саунасы» һәм фитобар ошаячак.

Югары класслы массаж сеанслары алырга теләүчеләр исә бу процедураның акупунктура һәм банкалысыннан башлап, япон Шиацуына һәм аппаратлысына кадәр булган киң линейкасы тәкъдим ителә. Асылда, «Бәкер» – чып-чын сәламәтлек хәзинәсе, анда медицина тернәкләндерүе казанышлары да, заманча ял ысуллары да, хезмәт күрсәтүнең югары сыйфаты һәм бай дәвалау базасы да тупланган.

– Дәвалау программасындагы берәр яңалык турында сөйләп үтсәгезче.

– Инде әйтеп узганымча, хезмәт күрсәтүнең исемлеген киңәйткәндә, без килүчеләрнең ихтыяҗларына юнәлеш тотабыз. 2015 елда без программаларыбызга үзен уңай яктан күрсәткән карбокситерапия юнәлешен – тәнне яшәртү һәм дәвалауның тире астына углекислый газ инъекцияләрен кертүгә нигезләнгән методикасын керттек.

– Күрүемчә, сез ирешкәннәрегездә тукталмыйча, динамик үсеш кичерәсез.

– Без кырыс көндәшлек мохитендә эшлибез. Базарда хезмәт күрсәтүнең сыйфат дәрәҗәсе дә, ял итүчеләрнең ихтыяҗлары да үсә. Төбәктә генә түгел, федераль дәрәҗәдә үз тармагыбызның иң яхшы вәкиле статусын саклау өчен, безгә туктаусыз алга барырга кирәк. Зур алгарышка, аеруча инфраструктура планында, без соңгы ике елда ирештек.

– Сыйфат өчен бирелгән премиягә кире кайтканда: шифаханә өчен бу чираттагы бүләк кенәме яисә ул зуррак мәгънәгә ияме?

– Һичшиксез, конкурс лауреаты исеме – безнең өчен Татарстан Хөкүмәте ягыннан югары бәяләнү генә түгел, ә бәлки шифаханәнең Россиядәге шиксез абруен раслаучы танылган брендка туры килүе дә. Без үз эшебезне киләчәктә дә камилләштерүне күздә тотабыз. Алдагы баскыч Сыйфат менеджменты системасына кертелү һәм сертификацияләнү булачак.

– Ял итү өчен чит илнеме, әллә үз илебезнеме, әйтик, «Бәкер»неме, сайлау алдында һаман да икеләнеп торган кешеләргә нәрсә әйтер идегез?

– Медиклар раславынча, үзең яшәгән киңлекләрдә ял итү күпкә файдалырак. Күпләрне куркытучы «санкцияләр» сүзе үз илебездәге шифаханә-курорт системасының киләчәктәге үсешенә мөмкинлек бирә. Үз республикабыз чикләреннән чыкмыйча сыйфатлы ял итү мөмкинлеге булганда, нигә чит илләргә омтылырга ди? Һәм безнең шифаханә – моңа иң яхшы мисал. Шулай булгач, «Бәкер»гә барыр вакыт җитте!

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЧОРДАШЛАРЫ

Быел без 95 яшьлек журналыбыз яшьтәшләре, басмабыз белән бергә республика үсешенә зур өлеш керткән, илебез күргән барлык авырлыкларны да үз җилкәсендә күтәргән өлкән яшьтәге кешеләребез турында язарга уйладык.

ӨЛКӘННӘР НӘСЫЙХӘТЕ

50 ел колхоз рәисе булып эшләгән Бөек Ватан сугышы ветераны, берничә ай элек 90 яшен тутырган ил агае Фәйзи Галиев Әтнә районының Түбән Шашы авылында улы Тәлгать, килене Суфия тәрбиясендә бик бәхетле картлык кичерә.



Автор:
Лилия Нурмөхәммәтова

ДИННЕ ДӘ БЕЛДЕМ, КӨННЕ ДӘ

– Минем кебек бер колхозны 49 ел да 7 ай җитәкләгән кеше юк, – ди Фәйзи Әхмәт улы. – 7 классны тәмамлаганнан соң бик тә белем аласым килгән иде, 75 сум акча түләргә кушкач, укый алмадым. Колхозга кайтып идарәдә эшли башладым. Шул вакытта әтием: «Улым, әллә кемнәр булырсың әле, мин сиңа ышанам», – диде. Ул бик белемле кеше иде. Әтнә районында русча белүче берданбер кеше булган. Латин, гарәп, кириллица белән хатасыз язды. Коръәнне дә укыды, үзе коммунист. Тик гомере генә озын булмады. 42 яшендә үлеп китте. Үлгәндә янчыгында 13 сум акчасы бар иде, шуны миңа биреп, ике энеңне ташлама, хәерче итмә, диде. Аның әманәтен үтәп яшәдем. Әнием дә дини иде. Ул 91 яшендә үлде. Менә мин дә әни яшенә җиттем. 17 яшемдә сугышка киткән идем, исән кайттым. Җилкәмдә әле дә ядрә кыйпылчыгы саклана.

1942 елда офицерлар хәзерләү курсына укырга дип җибәрелгән Фәйзине ашыгыч рәвештә сугышка алалар. Үлгән кешеләр өемен беренче тапкыр Ржев шәһәрендә күрә ул. Менә шуннан соң егет башыннан ниләр генә узмый. Күпме дустын югалта. Җан дусты булган күрше авыл егете дә яу кырында кала. Белгәнен укып, өстенә балчык каплап китәргә дә мөмкинлек булмый. «Эчке әгъзаларына кадәр күренеп тора иде, канга баткан гәүдәсе әле дә күз алдымда», – дип искә ала ул бүген.

Фәйзи ага сугыштан исән-имин кайтуын могҗизага тиңли. «Авылыбызда Гайшәбану исемле бик белемле абыстай бар иде. Улыңның хатларын җыеп барсаң, исән-имин кайтачак, дигәч, әнием аның сүзләрен тыңлаган. Ул хатлар бүгенгә кадәр саклана. Өлкәннәр киңәшен тотып яшәдем мин. Колхоз рәисе булып эшли башлагач, уракка чыгарга җыенабыз. Әни бераз сабыр итәргә кушты. Җомгадан соң Гайшәбану белән дога укып башлап куярбыз, җомгадан соң башланган эш хәерле була, диде. Үзем коммунист кеше, обком, райком члены булсам да, гомерем буе бу киңәшне тоттым, җомгадан соң эш башлап куя торган булдым», – ди ил агае.

ХАЛЫК ӨЧЕН ЭШЛӘДЕК

Яраланып кайткан Фәйзи 1944 елның 21 июнендә колхоз рәисе була. Сугыш бара, илнең авыр вакытлары. «Башыңны ник элмәккә тыктың, әнә, 80–90 кеше ачлыктан шешенеп ята, алар өчен син җаваплы бит», – дип елап каршы ала әнисе улын.

– Ире сугышта үлеп калган Әминә апа хәтеремә бигрәк тә кереп калды. Аларга керсәм, өч баласы да сәкедә ята. Әминә апа муеныма сарылып, үкси-үкси елый, ачлыктан саклап калуымны үтенә. Шул мизгелдә кызы үлде, – дип авыр сулап куйды Фәйзи ага.

Менә шул елларда авылдашларын бәхетле итү өчен барысын да эшләргә дип, үзенә ант бирә. Сүзендә тора Фәйзи. Аның колхозы республикада беренчеләрдән булып халыкка акча түли башлый. «Искра» хуҗалыгы СССР күләмендә зур дәрәҗәләргә ирешеп, шактый саллы бүләкләргә ирешә. Колхоз рәисенә тиешле премия акчаларын да Фәйзи ага үзенә алмый, колхоз счетына салып, һәр колхозчыга тигез итеп бүлдерә. «Үз кесәңә генә тутырсаң, халык яратмый башлый. Күрә бит ул... Шуңа күрә мин бер колхоз белән 50 ел идарә итә алдым», – ди Фәйзи абый, нәтиҗә ясап.

– Колхоз рәисе үзен түгел, колхозчыларын яратырга тиеш, – дип сүзен дәвам итте аксакал. – Шуннан соң гына сине яратучы, хөрмәт итүчеләр барлыкка килә. Элек таякка эшләү иде. Хезмәт көне сутыйдан чыгып язылды. Икмәк буларак борчагын да, арышын да, солысын да, бодаен да бирергә тырыштык. Колхоз помидор, кыяр, алма үстерә башлагач, аннан да өлеш чыгардык. Стаканлап бал өләшкән вакытлар да булды. Эшләү дәверемдә 7 авылның берсе дә юкка чыкмады, эшчеләр, йортлар саны кимемәде.

ХАЛКЫМ АЛДЫНДА ДӘРӘҖӘМ ЗУР

Шул кадәр эшләп, колхозны күтәреп, нигә герой булмадыгыз, дигән сорауны еш бирәләр аңа. Геройлыкка документлары киткән булган. 5 еллык күрсәткечләр буенча 18 сыер тулмаган, Мәскәүдән өстәмә документлар сораганнар. Алар сораган белешмәне илтмәгәннәр. «Бездән шактый ким күрсәткечләр белән эшләгән колхоз рәисләре дә герой булды. Аның каравы, авыл халкы мине геройга тиңли, дәүләт бүләкләрем болай да күп», – ди ветеран.

Әйтүләренчә, Фәйзи ага һәркем белән тигез аралашкан. Югары дәрәҗәдәге җитәкчеләр белән дә, авыл халкы белән дә гади итеп сөйләшә

Фотолар: Илдар Мөхәммәтҗанов



Ветеран бүген гаиләсенең җылысын тоеп яши

Төп йортны алып бару урман кисү белән бер.

идем, дип искә ала ул. «Үзеңне әллә кемгә куеп яшәп булмый ул. Гомерем буе үз фикерем булды. Һәркем алдында сүземне әйтә алдым», – ди ул.

Эшләү дәверендә республика җитәкчеләре Фикърәт Табиев, Гомәр Усманов, Минтимер Шәймиев белән дә уртак тел тапкан, җитәкчелек тә аңа хөрмәт белән караган. Эштән китәргә ниятләгәч, Гомәр Усманов аны үз янына чакырып, калуын үтенгән. Казаннан фатир бирергә вәгъдә иткән. Шуннан соң тагын 8 ел колхоз белән идарә итә ул. Тәкъдим ителгән фатирыннан баш тарта. Хатыны Бибисара белән киңәшләшәләр дә, авылдан беркая да китмәскә карар кылалар. Әйтергә кирәк, колхоз рәисе булып эшләгән бик күпләр, вазыйфадан киткәч, авыл кешесенең кырын карашын күтәрә алмый читкә чыгып китәргә мәҗбүр. Бары халыкны җәберләмәгәннәр генә авылда яшәп кала. Фәйзи абый шундый сирәк рәисләрнең берсе.

– Якын-тирәдә газ булмаганда, безнең авыл газ якты, – ди шушы җирлектә яшәүче Раилә Сабирова. – Авыл халкы өчен яшәде, диләр аның турында. Эшчеләр арасында кыңгыр эшләр булса да, зурга җибәрмәгән, үзе хәл иткән, беркемне дә фаш итмәгән. Кешене зар елатмады, рәхәттә яшәтте, дип искә алалар аны.

ҮЗГӘРЕРГӘ ИДЕ

Заманында авылны яшьнәтеп яшәткән Фәйзи абый бүгенге тормыш турында борчыла. Ул җитәкчелек иткән чорда өйләнүдән алып йорт төзүгә кадәр колхоз ярдәм иткән, халыкка кызыксындыру чаралары шактый булган. Хәзер эшчеләргә бөтенләй икенче караш, кешедән экономия ясап, тормышны алып бару дөрес гамәл түгел, дигән фикердә ул.

– Җөмләдә ия белән хәбәр булган кебек, тормышның да үз иясе белән хәбәре булырга тиеш. Хәзер хәбәр белән дөнья тулган, иясе генә юк. Олигархлар барлыкка килде. Кайберәүләр, эш урыныннан файдаланып, үзләренең хуҗалыкларын булдырды. Андыйлар дәүләт акчасын читкә түгел, үз оешмасына җибәрә инде. Бүгенге система шундый. Аның белән көрәшеп караган булалар, нәтиҗәсе генә күренми.

НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫМ

Фәйзи ага дөньяның үзгәрүенә борчылса да, авылда нигезләрнең бетмәвенә, аларны яшьләр дәвам итүенә куанып яши. Балалары белән төп йортта яшәүче өлкәннәр шактый булуына сөенә.

– Мин бик бәхетле карт, үз нигеземдә картлыгымны үткәрәм. Бабаларымның бабалары торган нигез бу, – ди ул. – Өч балабыз буй җиткәч, аларны җыйдым да әйттем: «Әниегез белән икәү генә калдык. Кайсыгыз безнең белән яшәргә тели, нигезне кем дәвам итә, дидем. Олы малай: «Әти, татар халкында элек-электән килгән гадәт бар, төпчек малай калырга тиеш», – диде. Тәлгать риза булды. Бүген нигезебезне улым Тәлгать белән киленем Суфия дәвам итә. Миңа 90 яшь инде, төрле вакытым була, киленем бик яхшы, кадер-хөрмәттә тәрбияли. Янымда үскән өч кызым – оныкларым да минем горурлык. Алар мәктәптән алтын медаль белән киттеләр. Авылда татар телендә белем алган кызларым югары уку йортларын кызыл дипломга тәмамладылар. Төпчеге дә югары уку йортында яхшы укый. Безгә кемнәр генә килми, туганнар да, дуслар да. Бөтен өй тула. Онықчыклар белән 25ләп кеше җыелабыз. Көн саен диярлек өебездән кеше өзелми. Киленнең йөзенә канәгатьсезлек чыкканы юк. Өстәлен тутырып һәркемне каршы ала. Бу яшькә җиткәнмен икән, барлык балаларымның да өлеше зур. Борчу китермәүләре белән алар миңа дәрт биреп тора. Мин беркайчан да алар артыннан йөрмәдем, юнәлеш кенә бирдем. Берсе дә йөземә кызыллык китермәде.

Җөмләдә ия белән хәбәр булган кебек, тормышның да үз иясе белән хәбәре булырга тиеш.





Киленен аерым мактавы юкка түгел аның. Моннан 33 ел элек бу нигезгә Суфия апа килен булып төшкәндә Фәйзи аганың әнисе дә исән була. Ике кайнаналы (Әтнә ягында кайнана белән кайнатаны әтеки белән әнеки диләр) йортка төшүдән курыкмый ул. Олылар сүзеннән чыкмыйча, аларны хөрмәт итеп яши. Ике кайнанасын да карап соңгы юлга озата.

– Бу авылга юллама белән килгән идем, бирелә яшәп калдым – ди Суфия апа. – Төп йортка килен булып килергә ризалык биргәнсең икән, иң беренче чиратта әтеки белән әнекине карарга, тәрбияләргә кирәк. Ир белән балалар икенче чиратта кала. Шуңа риза буласың икән, тора аласың. Без гомер буе бер-беребезгә ярдәмләшеп, аңлашып яшәдек.

– Суфияның да әтисе колхоз рәисе иде, әнисе дә төп йорт килене булды. Өлкәннәрне хөрмәт итүне аңа яшьтән сеңдереп үстергәннәр, – ди Фәйзи ага. – Килен оныкларны да шулай тәрбияли. Дәү әниләре үлгәннән соң, оныкларымның дога укуын ишеткәч, күзләрем яшьләнде. Суфияның тәрбиясе бит бу. Бүген күпләрнең төп йортта хезмәт итәселәре килми. Андыйларга мин үз киленемне үрнәк итеп күрсәтер идем.

НИГЕЗ КЕМ КУЛЫНДА?


Төп йортны алып бару урман кисү белән бер, ди Фәйзи абый. Нигез гөрләп барсын өчен, ирнең дә, хатынның да бер булып, өлкәннәрнең берләшеп яшәве кирәк. «Җан җылысын саклый торган хатын бер генә була ул. Бөтен нәрсәне хатынга гына йөкләү дөрес түгел. Балаңны кара, елатма, диюче ирләр бар. Бу сүзне бер тапкыр минем дә әйткәнем булды. Ул бала минеке генә түгел, дип, хатыным елап җибәрде. Менә шул вакытта ирнең хатын-кызга хөрмәте булганда гына тормыш матур буласына төшендем. Мондый сүзләрне әйтмәскә тырыштым. Хатыным белән бер-беребезне аңлап, 60 ел яшәдек. Ир-егетләр хатыннарын, өлкәннәр килгән киленнәрен, киленнәр өлкәннәрне хөрмәтләп яшәргә тиеш», – дигән киңәшен бирде ул.

ОЗАК ЯШӘҮ СЕРЕ

Фәйзи ага белән без рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык. Хәтере шулкадәр шәп. Бу хәлне ул көн саен иртән бер йомырка ашау нәтиҗәсе, ди. Йомырканың сарысы аң дәрәҗәсен арттыру сәләтенә ия икән.

– Мин гомер буе имән кебек нык булдым дип әйтә алмыйм, авырмый тормадым, авырдым, тик үземне саклап яшәдем, – ди аксакал. – Кибетнекенә караганда табигый ризыкларга өстенлек бирдем. Авылда яшәп сөт сатып алучыларга аптырыйм, кибетнекеннән ниндидер тәм килгән кебек миңа. Сыерын да, тавыгын да асрыйбыз. Көн саен каймак ашыйм. Колхоз рәисе булсам да, нинди генә мәҗлесләрдә утырырга туры килсә дә, гомер буе аракы эчмәдем, колбаса ашамадым, тәмәке тартмадым. Эшләгәндә дә, хәзер дә җәяү йөрим. Хәрәкәттә бәрәкәт, ди безнең халык.

«Җомгадан соң башланган эш хәерле була», – дип әйтә иде әнием.



PRESSA.RU

ХОДАЙ РӘХМӘТЕ БЕЛӘН ИСӘН КАЛДЫМ...

Мөслим районының Әмәкәй авылында туып-үскән китапханәче кыз 20 яшендә фронтка китә. Һәм, утлы елларны кичеп, Берлинга, Рейхстагка кадәр барып җитә. Сержант Гази Заһитовның Рейхстаг түбәсенә кызыл әләм урнаштырганын үз күзләре белән күрә. «II дәрәҗә Ватан сугышы ордены», «Сугыштагы батырлыклары өчен» медале, «Санитар хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе иясе Мөшәрәфә Шәйхуллина турында бара сүз.

Автор:
Лилия Шәймиева,
Мөслим районының **«Авыл утлары»** газетасыннан **«Татарстан»** журналы өчен махсус

Медальләрен җыерчыклы бармаклары белән назлагандай сыйпаштыргалап ала Мөшәрәфә әби. Сугыш беткәч, кабат туган авылы Әмәкәйгә әйләнеп кайта ул. Гомере буе колхозда эшли, тормыш иптәше Габдулла абзый белән бергә балалар үстерә. Хәзер аңа 96 яшь.

МЫЛТЫК ТОТЫП САКТА ТОРДЫК...

«Сугышка алгач, иң беренче эш итеп чәчләремне кырдылар, ярты җаным чыкты шул вакытта...» – дип башлый ул истәлекләрен. Беренче сугыш кырын Тула өлкәсендә күрә санитар кыз. «Тимер юллар, вагоннар тәгәрәп ята. Аяусыз сугыш үткән җирләр иде ул. Урман эчендә, агачлар арасында яралылар ауный. Фронтта безгә 42 нче размерлы итек, винтовка, противогаз, казан, кашык, шинель бирделәр. 61 нче дивизиягә санитар итеп куйдылар, яралыларны ташыдым. Мине утыртып йөртәсе шофер белән таныштырдылар. Олы яшьтәге абзый иде инде ул. Шуның белән сугышның башыннан азагына кадәр хезмәт иттек. Иң кызганычы, сугыш беткәч үлде шул, җаныкаем... Без йөри торган машина яралыларны ташу өчен яраклаштырылган: ике рәт сәкеле. Солдатларның кайберләрен яткырып, утыра алырдайларын утыртып, сөяп куя идек. Алты кыз алмашлап мылтык тотып сакта да тордык. Аяк тавышы ишетелсә, өч тапкыр кисәтү ясарга, килүче туктамаса, атарга дигән фәрман бар иде. Бервакыт, бомба төшеп, дүрт кызыбыз үлде».

КУРКУДАН НИНДИ МӘГЪНӘ?!

– Шартлаулар вакытында үләрмен дип курыкмый идегезме? – дип сорыйбыз Мөшәрәфә әбидән.

– Мин ул чакта бик үткен, чая идем, – ди әбиебез. – Бернәрсәдән курыкмадым. Хәер, куркудан нинди мәгънә, барыбер беркая кача алмыйсың, кайсы якка карама – тоташ сугыш, миналар шартлый, ядрәләр оча. Вакыты шундый иде шул...

АЛЛАҺ ИСЕМЕН ТЕЛДӘН ТӨШЕРМИ...

Динне тыйган дәвердә яшәсәләр дә, Аллаһ исемен телдән төшерми Мөшәрәфә әби. Бу вакыйганы менә ничек искә ала ул...

Бер көнне санитар машинасы минага эләгә. Машина чәчрәп күккә оча, ә кызны ком-туфрак астыннан көч-хәл белән казып чыгаралар. Шофер белән санитаркадан кала машинада булган бөтен кеше үлеп бетә. Контузия алып, ике айлап госпитальдә дәваланганнан соң, аны кабат үзе хезмәт иткән частька җибәрәләр. «Ходай рәхмәте белән генә исән калдым» дип саный Мөшәрәфә әби.

СӨЙГӘН ЯРЫМ БАШКА ФРОНТТА ИДЕ...

Батыр йөрәкле санитар кызның тормыш иптәше дә сугышта катнашкан, аның белән сугыш кырында очрашу минутларының хатирәсен күңелендә якты ядкарь итеп саклый ветеран: «Сөйгән ярым Габдулла Шәйхуллин белән төрле фронтларда хезмәт иттек. Шулай булса да, гел хәбәрләшеп тордык. Бервакыт аның яраланганы турында ишеткәч, госпитальгә хәлен белергә килдем. Габдулла абыегыз командир, ә дәрәҗәсе – лейтенант иде», – дип горурланып сөйли ул.

Сугыш чорында әсир калу куркынычы да уратып узмаган Мөшәрәфә әбине. Дошман камалышында калгач, шофер белән җиде-сигез көн сазлыкта ятканнар. Ашаганнары – агач кайрысы белән агач төбендәге ак кортлар була. Шушы сазлыкта санитар кызның бөтен документлары җебеп бетә, бил сөяге яралана. Тик, документлары булмагач, «сугышта яраланган» дигән исем бирмиләр аңа. Бөек Ватан сугышы ветеранының медальләре бик күп, ләкин иң кадерлесе – «Санитар хезмәте отличнигы» күкрәк билгесе. «Миңа аны намуслы хезмәтем өчен бөтен рота алдында бирделәр», – дип искә ала ул.

КЕШЕЛӘРЧӘМЕ БУ?!

Мөшәрәфә Шәйхуллина Украина фронтындагы сугыш михнәтләрен кичкән кеше. Украинадагы хәзерге хәлләрне искә алгач, бик борчыла ул:

– Шулай ярыймы инде, йә?! Кешеләрчәме бу?! Нигә тагын сугыш ачарга Украинада?! Аны бит инде сугыш елларында фашистлар җир белән тигезләде – яндырып, туздырып чыкты. Күпме авыл харап булды, күпме халыкны, бала-чаганы лагерьларга илтеп тыктылар! Без бу җирне ул чакта барыбыз бергә коткардык – украиннар, руслар, татарлар. Каһәр суккыры фашистларны Рейхстагның үзенә кадәр куа бардык! Ә хәзер барысы да янә кабатлана. Ярамый бит болай!

КИРӘКМИ БЕЗГӘ СУГЫШ!

Батыр йөрәкле ветеран бүгенге көндә улы Ирек белән килене Роза тәрбиясендә бәхетле картлык кичерә. Балалары һәм оныклары белән чиксез горурлана.

– Барыгызга да минеке кебек бәхетле тормыш телим, – ди ул. – Һәм сезгә беркайчан да сугышны күрергә насыйп булмасын.

PRESSA.RU

ТОРМЫШНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

«Керегез, балалар, мин хәзер,керемне генә уып бетерим инде», – дип каршылады безне Миңнегайшә әби, күбекле кулларын сөлгесенә сөртә-сөртә.



Миңнегайшә әби оныгы Рөстәм белән

Материал **«Заветы победителей»** китабына нигезләнеп эшләнде

– Синең белән сөйләшергә хәбәрчеләр килгән, Казаннан, – дип, әбекәйне безнең белән таныштыра Лаеш районының Кече Елга авылы фельдшеры Суфия Ибәтуллина. – Яшь чакларың, сугыш еллары турында сораштырмакчы булалар. Ә син, йә, ник тик кенә телевизор карап утырмыйсың инде, кер уарга булган, күр әле!

– Балалар эштә чакта нәрсә белән булса да юанырга кирәк ич инде, Суфия кызым, – дип елмая Миңнегайшә әби. – Эш белән дә юанмасаң, көнне ничек уздырырга кирәк... Ә сез узыгыз, әйдә, ник бусагада торасыз?!

Аның күзләреннән күзне алып булмый – әйтерсең, игелек, мәрхәмәт бөркелә алардан. Йөзе нурлы бу әбекәйнең битендәге һәр җыерчыкны балкытып елмаюын күргәч, тормышта гел балда, майда гына йөзеп яшәгән икән, дип алданырга мөмкинсең...

ШАТЛАНЫП ТУЯ АЛМЫЙ...

Вәлиуллиннар йортына барлык туган-тумача җыелырга ярата икән. Өстәл артында чәйләп, гәпләшеп утыралар. Миңнегайшә әби үзе мондый җыеннарны аеруча яратам, аларга шатланып туя алмыйм, ди. Өй тулы бала-чага җыела ич, күңелледер... Хәзер, инде алар үсеп кеше булгач, оныклар килгәч, билгеле, күңелле. Ә теге чакта, 40 яше әле тулып кына узганда, биш улы һәм кайнанасы белән тол булып утырып калганда, күңелле булмагандыр бер дә.

«ӘЗЕР БУЛЫРГА КИРӘК!»

Бөек Ватан сугышы башланганда, Миңнегайшәгә 17 яшь була. Фронт сызыгының ил эченә никадәр тирән үтеп керәчәген ул чакта берәү дә белми, яшь кызны, яшьтәшләре белән бергә, Апас районының Дәвеш авылына окоп казырга җибәрәләр. Дәвешнең туган якны өйрәнү музее экспонатлары арасында кызыклы бер документ саклана – казылган окопларны тапшыру буенча акт, ул 1942 ел белән тамгаланган. 1941 елның октябреннән алып 1942 елның февраленә кадәр Апас районында кул белән 300 километрдан артык окоп казылган, документка ышансак. Немец армиясе үтеп кергәндә, әзер булырга кирәк, дип тырышкан халык. Казу эшләрендә миллионнан артык кешенең катнашуы билгеле.

«МИХНӘТЕ БАРЫБЫЗГА ДА ҖИТТЕ...»

– Без ул чакта бер кешеләрнең өендә яшәдек, – дип искә ала Гайшә әби. – Гаиләләре ишле иде, өстәвенә без дә – сигез кыз бала һәм дүрт ир кеше. Ашарга җитми, салкыннар үзәккә үтә, кием-салым юк. Бозланып каткан бәрәңгене җыеп алабыз да, кайнаган су агызып, эретеп, ашыйбыз. Бөтен булган ризык шул. Ә эш авыр – көннәр буе казыйсың да казыйсың. Ничек чыдаганбыз, белмим?! Дүрт ай узгач, безне, Аллага шөкер, кайтарып җибәрделәр. Хәер, өйдә дә хәлләр әллә ни яхшы түгел, тик шулай да туган нигездә җиңелрәк. Миннән сугыш турында сорыйлар... Нәрсә әйтим инде: барыбызга да җитте михнәте – ирләргә дә, хатын-кызларга да, балаларга да, карт-корыга да. Әмма без барыбер җиңеп чыктык, чөнки безнең максатыбыз бер иде.

ЭШЛӘГӘНГӘ – ЭШ ЯЗГАН

Сугыш тәмамлангач, Миңнегайшә Сибгатулловна яшь фронтовик Кәримулла Вәлиуллинга кияүгә чыга. Кәримулла фронттан кулы һәм үпкәсе җәрәхәтләнеп кайткан була. Бу җәрәхәтләр еллар узгач үзен сиздерә дә. Шулай итеп Миңнегайшә таяныр ир җилкәсеннән мәхрүм була. Бөек Ватан сугышы солдатының тол хатыны дигән исем белән генә гаиләне туйдырып та, күтәреп тә булмый бит. Кайнанасын да карарга кирәк... Шулай итеп Миңнегайшәгә көне-төне колхоз эшен җигелеп тартырга туры килә. Нишлисең, эшләгәнгә эш язган, диләр бит.

«ҺӘР КӨННЕҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!»

– Аллага шөкер, сынатмадым, барысына да көчем җитте, – дип сөенә Гайшә әби. – Кайнанам да безнең белән 99 яшенә кадәр яшәде. Хәзер менә үзем дә биш бөртек хатын-кызга – кайнана. Дөрес, бер улыбыз – Камил – инде 12 ел арабызда түгел, әмма гаиләсенең бездән өзелгәне юк. Үзем улым Миңнехан һәм киленем Назирә белән кадер-хөрмәттә яшим, шөкер. Балаларым кешелекле булып үсте, оныклар да әйбәт. Ә тормышта күргәннәрне искә төшергәндә, болай уйлыйм мин: Аллаһы Тәгалә миңа ул сынауларны әзерләп куйган, биргән икән, димәк, шулай кирәк булган, димәк, минем аларны ерып чыгарыма ышанган. Шуларны күргәнгә, тормышның кадерен беләмдер дә, бәлки. Гаиләмдәгеләрне дә һәр көннең кадерен белеп яшәргә өндәп торам. Сез дә шулай яшәгез, балалар!

2016 елга язылу кампаниясе дәвам итә!

WWW.PROTATARSTAN.RU
Татарстан
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә

Шәхси затлар өчен:
Индекс **73377** – татар телендә: алты айга язылу бәясе **840 сум 00 тиен**
Индекс **73947** – рус телендә: алты айга язылу бәясе **900 сум 00 тиен**

Ф.СП-1

Почта России
АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал 73377 (индекс издания)
Татарстан
(наименование издания)
количество комплектов:
на 2016 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда (почтовый индекс) (адрес)
Кому (фамилия, имя, отчество)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА
ПВ место литер
на ~~газету~~ журнал 73377 (индекс издания)
Татарстан
(наименование издания)
Стоимость: подписки 840 руб. 00 коп.; переадресовки ____руб.____коп.
количество комплектов:
на 2016 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда (почтовый индекс) (адрес)
Кому (фамилия, имя, отчество)

Шулай ук электрон почта аша да язылырга мөмкин:
dolgovadv@tatmedia.com
Дистрибуция бүлеге хезмәткәрләре, шалтыратып, кызыксындырган сорауларыгызга җавап бирерләр.

Яки түбәндәге телефон буенча тарату бүлеге җитәкчесе Дарья Долговага үзегез шалтырата аласыз: **тел. +7 (987) 294-54-11**

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Казан WorldSkills халыкара чемпионатына **НИЧЕК** әзерләнә

Беренче «Мисс Татарстан» хәзер **КАЙДА**



Фото: hakandeliduman.wordpress.com

«АЛЬФА» ТУРЫ ЮЛГА АЛЫП ЧЫГАРМЫ?



Юрий Алаев, КФУ иҗтимагый мәгълүмат үзәге җитәкчесе, киләчәк буыннардан нәрсә көтеп булуы турында уйлана.

Киләчәк турында хыялланганда, без аның тулысы белән шушы киләчәкне булдыручы актив буынның гадәтләре, күнекмәләре, холкы һәм акылы белән билгеләнүе турында еш уйланабызмы соң? Әйдәгез, аларга игътибар беләнрәк карыйк әле, бәлки, безне нәрсә көткәне ачыкланыр.

90нчы еллар башында Америка социологлары Уильям Штраус белән Нейл Хоув фәнни әйләнешкә латин әлифбасының X, Y, Z хәрефләре белән билгеләнгән буыннар градациясен керткән иде, аңа кадәргеләрен «бэби-бумер» дип атап. Узган гасырның 80–90нчы елларында станок, кульман һәм идарә итү пультлары артына 1963–1983 елларда туган X буыны (Штраус – Хоув градациясе буенча) басты, алар эзлекле рәвештә бэби-бумерлар (1943–1963 елгылар) буынын алыштырып килде, һәм бу ике буын катламы үзләренең кыйммәтләр ориентиры белән шактый аерыла иде: өлкән буынга шәхес буларак үсеш, коллективлык, нәтиҗәгә күмәкләшеп, команда белән бергә ирешү сыйфатлары хас булса, «икс»лар ялгызаклар, аларны шәхси уңыш күбрәк кызыксындыра. Ләкин максатка тырыш хезмәт аша ирешү өстенлек итә, һәм бу бик мөһим.

Социологлар шуны ачыклаган: «игрек»лар (1983–2003 елгылар) еш кына юлларын түбәннән башлап, хезмәт баскычлары буйлап югарыга күтәрелгәнне еллар буе көтәргә әзер түгел, аларга барысы да «бүген һәм шушында» кирәк. Шул ук вакытта психологик җирлек тә радикаль рәвештә үзгәргән – яңа буынга күз алдына да китерә алмастай мәгълүмат агымы ишелеп төште, ә тышкы һөнәри мохит бик тотрыксызга әйләнде (әлеге дә баягы технологик үзгәрешләр һәм капиталның глобаль хәрәкәте аркасында). Икенче төрле әйткәндә, «игрек»лар, яңа күнекмәләр үзләштермичә, бер хезмәт урынында еллар буе тыныч кына утырып торырга исәп тота алмыйлар һәм, телиләрметеләмиләрме, совет чорында үтә тәнкыйтьләнгән «летуннарга» әйләнергә, ягъни бер эш урыныннан икенчесенә күчеп йөрергә мәҗбүр булалар.

Шул ук вакытта «игрек»лар моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәдә техник грамотага ия һәм (бигрәк тә бэби-бумерларның пенсиягә һәм бакыйлыкка күчүен дә исәпкә алганда) заманча компанияләр хуҗаларының өмете һәм таянычы булып торалар. Шуңа өстәп – сәяси сыйныф җитәкчелегенең дә, ләкин бу бөтен илләрдә дә алай түгел, әйтик, Россиядә башкача.

Монда кечкенә генә йомгак ясап, бер-ике өстәмә кертергә кирәктер. Аерым бер илләрнең X – Y буыннары икенче илләрдәге яшьтәшләреннән, тарихи һәм мәдәни традицияләре, дәүләт төзелеше һәм үсеше үзенчәлекләре аркасында, шактый аерыла. Шул ук вакытта ул аермаларның арасы кечерәя бара, һәм якынча йомгак ясасак, шуны әйтергә кирәк: глобаль җәмгыять глобаль бурычларны хәл итәргә әзер түгел, ул күбрәк «үзендәге әйберләрне» җитештерүгә һәм үрчетүгә, кулланучылык хакына куллануга юнәлгән, өстәвенә, ул кулланучылык кешенең яки социумның асыл ихтыяҗларына бөтенләй дә җавап бирми, ә ясалма рәвештә стимуллаштырудан килеп чыга.

Бу исә интеллектуаль, мәдәни һәм физик деградациягә китерә – күңелсез хәл, ә планетаның матди ресурсларының чиксез булмавын, ә «алтын миллиард»ның теге ягындагы ач халыкның саны әлеге миллиардтан артып китүен уйлаганда – фаҗигагә тиң. Тарихи масштабта караганда, перспективаларны фаразлау кыен түгел.

Хикмәт әле шунда да: тикшеренүчеләр раславынча, «икс»лардан (һәм өлешчә «игрек»лардан) туган балаларда үзләре өчен генә яшәү һәм аларга турыдан-туры кагылмый торган мәсьәләләргә битарафлык тагын да көчлерәк чагылыш таба. 1991 елдан соң туган әлеге балаларны Zлар, диләр. Төп сыйфатлары: инфантильлек, ихтыяҗларын канәгатьләндерергә кирәк булса да, хәрәкәт итүгә сәләтсезлек. «Зет»лар тере аралашуга мохтаҗ түгел, аның караvы интернеты булган җайланмаларга бәйлелекләре бик көчле. Эзләүче системаларда «зет»ларга кагылышлы иң популяр сорауларның «алар белән ничек эшләргә», «ничек эшләргә мәҗбүр итәргә» кебегрәк булуы шуңа да гаҗәп түгел.

...Дөньяның шушы рәвешле корылышында мине бер нәрсә тынычландыра: **Z** – латин әлифбасындагы соңгы хәреф. 2010 елдан соң туганнарга «альфа» буыны дигән атама бирделәр инде. Бәлки, аларга барысын да яңадан башларга туры килер?

PRESSA.RU



Фото: worldskils.ru, worldskilskazan2019.org

WORLDSKILLS: ҺӨНӘРИЛЕКНЕҢ АЛТЫН СТАНДАРТЫ

Халыкара WorldSkills Competition 2019 чемпионатының Казанда үткәрелү хәбәрен дә үз вакытында лаеклы рәвештә Универсиаданы кабул иткәндәй зур энтузиазм белән кабул иттеләр. Һәм эш Татарстан башкаласының Париж һәм Шарлеруа кебек җитди көндәшләрдән яхшырак әзерлекле булып чыгуында гына түгел. Хәтта ки эшче һөнәрләр чемпионаты – үткәрелүе Казанга ышандырып тапшырылган дөнья дәрәҗәсендәге чираттагы ярышлар гына да түгел. Барысы да күпкә җитдирәк.



Автор:
Василина Олейник

1947 елда эшче кадрларга аеруча зур кытлык күзәтелгән Испаниядә һөнәри-техник әзерлеккә багышланган беренче милли конкурс үткәрелә. Ул эшче белгечлекләрнең абруен күтәрергә һәм һөнәри белем бирүнең нәтиҗәле системасын төзүгә этәргеч бирергә тиеш була. Соңрак әлеге башлангычны башка илләр дә күтәреп ала.

Россия – WorldSkills International системасына соңлап кушылучыларның берсе. 2012 елда гына әлеге хәрәкәткә кушылып киткән Россиягә бүген башкаларны куып тоту өчен шактый зур адымнар ясарга туры килә. Хәер, адымнарыбыз ныклы күренә.

ГӨБӘДИЯ – ХАЛЫКАРА СТАНДАРТЛАР БУЕНЧА

Көз ахыры – имтиханнар чоры түгел. Ләкин Казандагы Халыкара хезмәт күрсәтү көллиятендә киеренкелек сессия вакытындагыдай. Биредә, WorldSkillsның «өйдәге» этабында, иң яхшы студентлар киләсе баскыч – урта махсус һөнәри уку йортлары арасында уздырыла торган челтәр этабына узу өчен көрәшә.

Цехларда эш гөрли. «Пешекче эше» белгечлеге студентлары гөбәдия әзерләү белән мәшгуль: камыр басалар, эчлеген ясыйлар. Мондагы атмосфера нәрсәсе беләндер шеф Гордон Рәмзинең соңгы вакытта популярлашып киткән кулинар шоуын хәтерләтә: барысы да тиз һәм җитди эш итә. Ризык милли, тик аны пешерү WorldSkills стандартлары буенча башкарылырга тиеш. Ә алар, экспертлар әйтүенчә, шактый күп. Һәм нәкъ менә әлеге стандартлар беренче чиратта һөнәри осталык буенча үткәрелә торган традицион конкурсларны яңалары – WorldSkills International кысаларында үткәрелә торганнарыннан аерып тора да инде.

– WSI – мәйданда бара торган һәм анда булган һәр нәрсәгә карата аерым таләпләр ул, – дип сөйли көллият директоры Фәридә Ковалёва. – Гадәттә һөнәри осталык конкурсларында нәтиҗә һәм эш урыны бәяләнә. Ә биредә кирпеч артыннан кирпеч салгандай бәя барлыкка китерүче төгәл күрсәткечләр кулланыла. Мәсәлән, катнашучының мәйданда ни рәвешле оптималь хәрәкәт итүе, ингредиентларны өстәлдә ничек тезүе һәм алып куюы бәяләнә, эргономикага карыйлар. Шулай ук кирәк-яракларның бәрәкәтле кулланылышы да исәпкә алына: һәркемнең үз кәрзине бар, ярыш ахырында арбитрлар әзерләү вакытында никадәр нәрсәнең ташлануын карыйлар. Бәя объектив һәм субъектив критерийлар буенча балларны кушуның катлаулы схемасы ярдәмендә барлыкка килә. Һәм барлык стандартлар да шактый кырыс. WorldSkills этапларында яңа инвентарь һәм җиһазларны кулланган өчен дә баллар күтәрелә. Димәк, без аларны әзерлек этабында ук үзләштерергә тиешбез. Әлбәттә, нигездә, катнашучының үз компетенциясендәге стандартларны никадәр яхшы белүе бәяләнә.

Эшче профессияләрнең абруен күтәрүдән тыш, белем бирү процессына халыкара стандартларны кертү – WorldSkills проектының төп максатларының берсе. Бүген бездәге белем бирүнең дәүләт стан-



Гөбәдия – милли ризык, тик аны пешерү WorldSkills стандартлары буенча башкарылырга тиеш.

дартлары шулай ук, һичшиксез, файдалы, чөнки төбәкләр буенча белгечләр әзерләүнең аерым бер дәрәҗәсен билгелиләр. Ләкин төп проблема – сыгылмалылыкның булмавында. Алар, бер яктан, белгечләр әзерләүне бердәйләштерәләр, ә икенче яктан, җәмгыять ихтыяҗларына яраклашуны кыенлаштыралар. WSI исә «компетенция» төшенчәсен куллана. Бу нигез булырга тиешле белемнәр, белгечтән һичшиксез таләп ителгән һөнәри күнекмәләр, тагын өстәп – модульләр, ягъни белгеч хәл итә алырга тиешле бурычлар. Һәм, әлбәттә, югарыда аталган таләпләр алгарыш җилләренә ярашлы рәвештә формалаштырыла.

– Белем һәм күнекмәләр даими яңарып тора, ниндидер яңа компонентлар өстәлә, яңа технологияләр туа, аларны студентлар белән бергә үзләштерергә туры килә, – дип сөйли WorldSkills турында кондитерлык эше буенча баш эксперт Юлия Павлова. – Быел милли чемпионатта безнең алты модуль катнашачак, былтыр өч кенә иде. Бу – конфетларның өч төрле сортын, карамельдән зур композиция (программада бу юк, безгә аны өстәмә үзләштерергә туры килә) әзерләү. Плюс ике торт, 50гә 50 зур шоколад композиция, өч исемдәге пирожный, марципаннан эшләнмә һәм тәлинкәдә десерт. Һәм бу бер чемпионат биреме. Әгәр оештыручыларның 30 процент биремне кисәтмичә генә алыштырырга һәм тагын «кара ящик» кертергә хокуклары барлыгын исәпкә алсак, исеме аталмаган һәм мәҗбүри рәвештә кулланырга тиешле ингредиентны кертү конкурсантлар өчен ничек авырга туры килүен аңларга була. Бу, әлбәттә, катнашучыларның үсешенә зур этәргеч бирә.

Мондый якын килү пешекче һәм кулинарларны гына үстерми. Шундый ук кырыс һәм көтелмәгән нәрсәләргә бай программа слесарьне дә, токарьне дә, ташчыны да, флористны да, автомеханикны да, зәркәнчене дә күтәргә мөмкин. Ягъни WorldSkillsta тәкъдим ителгән компетенцияләр ярышы белемле генә түгел, универсаль белгечне әзерләргә юнәлдерелгән.

КАЙ ЯКТАН ТОТЫНЫРГА?

Әгәр бүген WSI компетенцияләренең махсуслаштырылган үзәкләре төзелә торган урта махсус белем бирү йортлары каршында хәрәкәткә, ким дигәндә, урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларының яртысын тарту бурычы торганын исәпкә алсак, ахыр нәтиҗәдә Татарстан икътисады әзерлекләре халыкара дәрәҗәдәге кадрлар алырга тиеш. Ә WorldSkills ярышларында катнашучы компетенцияләр (димәк, профессияләр) алты юнәлештәге 45кә якын төрдә, алар арасында төзелешкә, коммуникациягә, мәгълүматка, җитештерү һәм инженерлык технологияләренә, иҗатка һәм дизайнерлыкка, хезмәт күрсәтү һәм гражданлык транспортын тәэмин итүгә караганнары бар. Белгечләр бәяләмәләре буенча, якындагы ике елда йөз меңгә якын профессионал (аларның 35 проценты – эшче һөнәрләр) таләп ителгән республика өчен бу шактый яхшы перспектива.

Әмма WSI процессына кушылып китү һөнәри белем бирү системасын гына үзгәртеп калмый. Ул инде хәзер үк уку йортларының үзләрен дә үзгәртә.

– Республикада WSI шартларына туры килә торган махсуслаштырылган компетенция үзәкләрен (МКҮ) ачарга кирәк, алар җиһазларны тупларга, экспертларны әзерләргә тиеш, – дип сөйли WSRның ТРндагы Республика компетенцияләр үзәге җитәкчесе Анфиса Җәләлиева. – Бүген урта махсус белем бирү учреждениеләре нигезендә 31 МКҮ ачылды. 2013 ел ахырында Татарстан Мәскәү өлкәсе белән бергә әзерлекнең нәтиҗәлелеге һәм темплары буенча лидерлар арасында, шуңа күрә республика милли чемпионатны үткәрү хокукын ала да. Әзерлекнең ресурс үзәкләре дә барлыкка килде. Бүген алар җиде, ә 2020 елда егерме булачак. Эш бирүчеләр белән уртак төзелгән һөнәри оешмалар тигез шартларда тәэмин ителә.

Яңа ачылган ресурс үзәкләрендә профессиональ әзерлекнең «озын һәм кыска» программаларын, квалификацияләрне сертификацияләүне гамәлгә ашыру планлаштырыла. Алдынгы методикалар, технологияләр һәм ресурслар эшләнәчәк һәм сыналачак.

Әле совет чорыннан ук килгән гадәт буенча һөнәри белем бирү йортлары, нигездә, производстводан чыгарылган җиһазлар хисабына тәэмин ителә. Табигый ки, бу очракта нинди дә булса яңалыкны үзләштерү мөмкинлеге калмый. Студентлар иске техниканы өйрәнәләр, ә аннан соң эш бирүчегә барып, бөтен көчләрен яңасын үзләштерүгә түгәләр.

– Бу яктан Россиягә алга тартылырга туры килә, – ди Фәридә Ковалева. – Беренче тапкыр WorldSkills ярышларында катнашу өчен, Германиягә чыккач, андагы заманча җиһазларны күреп, җыелма командабызның аптырашта калганын яхшы хәтерлим әле мин. Катнашучылар беренче мәртәбә күргән җиһазларга кай яктан тотынасын да белми иделәр. Ә хәзер укуны тәмамлаучыларның предприятиеләргә заманча техниканы белеп килү мөмкинлеге бар, һәм хәтта ки производствога әлеге җиһазны кертә дә алачаклар.

> «Беренче тапкыр WorldSkills ярышларында катнашу өчен, Германиягә чыккач, андагы заманча җиһазларны күреп, җыелма командабызның аптыраштa калганын яхшы хәтерлим әле мин».

Татарстан башкаласында май аенда үткән Милли чемпионаттан соң, партнер фирмалар тарафыннан бушлай бирелгән җиһазны республика Мәгариф министрлыгы һөнәри белем бирү оешмаларына тапшырды. Алардан хәзер яңа кадрлар файдана ала.

ОСТАЛЫК СЫЙФАТЫ БУЛАРАК «ЛЕГО» ҖЫЮ

Казан педагогия көллиятенең ресурс үзәге замана педагогикасы таләп иткән соңгы сүз буенча җиһазландырылган. Релакс-бүлмә, күпләгән матур уенчыклар, конструктор тутырылган зур әрҗәләр, балалар өчен «акыллы» өстәлләр, видеопроекторлар. Ул өстәмә үсеш үзәге буларак эшли: биредә түгәрәкләр алып барыла, теләге булганнар белән логопед шөгыльләнә. Биредә шулай ук көллияттә укучылар да практика үтә.

WSда катнашучы студенткалар «Лего» конструкторыннан балалар тарафыннан җыелган роботларны күрсәтәләр. Аны җыйганда баланың вак моторикасы гына түгел, әйләнә-тирә мохиттә ориентлаша алу күнекмәләре дә үсә, дип аңлаталар. Лего-роботны җыя алу һәм аның белән эшли белү – мәктәпкәчә белем бирү педагогына карата куелган заманча таләпләр икән. Конкурсның әлеге модуле инде практикага кертелгән. Ә илебезнең белем бирү стандартларында, әлбәттә, әлегә бу юк.

– Үзәгебездә без Россиядә һәм чит илләрдә булган барлык ресурсларны тупладык, аларны мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләү өчен кулланырга мөмкин. Бу экологик яктан чиста, СанПин тарафыннан хупланган, барлык стандартларга туры килә торган әсбаплар, җиһазлар, уенчыклар, – дип сөйли Анфиса Җәләлова. – Җиһазлар барлыгын күрдек, тик методик тәэмин ителеш, тәрбиячеләргә тәрбия процессын дөрес оештырырга ярдәм итә торган әсбаплар юк. Без боларның барысын да WS конкурсантлары өчен әзерлибез. Ел саен берничә яңа модуль алабыз. Кайсы компетенцияләрнең нигез булачагын билгеләдек. Бу, мәсәлән, коммуникатив юнәлеш: ата-аналар белән эш, әкиятләр уку, аларны сәхнәләштерү, соңрак – рәсем ясау. Тәрбияче баланың вак моторикасын формалаштыра, ул кәгазьне ничек куярга, пумаланы тотарга һәм башкаларны белергә тиеш.

Фото: worldskils.ru, worldskilskazan2019.org

> Урта һөнәр бирү урта йортлары каршында WorldSkills хәрәкәтенә, ким дигәндә, урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларының яртысын тарту бурычы тора.

Болар «автомат» рәвештә башкарылырга тиеш.

Сз уңаеннан, «Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячесе» компетенциясен, «Файдалы казылмаларны нәтиҗәле табу һәм эшкәртү» кебек үк, конкурс белгечлекләре исемлегенә кертергә нәкъ менә Казан тәкъдим итте. Эш шунда ки, милли чемпионатны оештыручыларның яңа белгечлекләр кертергә хокукы бар. Башта презентация тәртибендә, ә соңрак – төп, шулай ук конкурс программасына кертелгән белгечлек буларак. Татарстан тарафыннан тәкъдим ителгән компетенция хәтта халыкара ярышларда да төп белгечлеккә әверелергә мөмкин. Аларның иң якындагысы 2017 елда Абу-Дабида уздырылачак.

Бүгенге көннәрдә көллияттә, республиканың башка һөнәри урта белем бирү йортларында кебек үк, милли беренчелеккә әзерлек эшләре бара.

– Конкурс йә эшчәнлек процессына, йә нәтиҗәгә бәя бирә, – дип сөйли «Мәктәпкәчә белем бирү педагогы» компетенциясе буенча эксперт Наталья Орлова. – Мәсәлән, конкурсантларга балалар өчен гимнастика, процессуаль дәресләр үткәрү тәкъдим ителергә мөмкин. Һәм менә шул чакта яшь үзенчәлекләренә, программа буенча нормативларга туры килү бик мөһим. Без процесста методикага туры килүне эзлибез. Ә нәтиҗәләрне без сәнгати эшчәнлектә – декортив-гамәли иҗатта бәялибез. Катнашучыларның, мәсәлән, гжельне, хохлома, городецк яки жостов язуларын башкару технологияләрен белүләренә бәя куябыз. Шулай итеп башкарды яисә башкармады принцибы буенча бәя куюның 15кә якын күрсәткече җыела. Шуңа күрә бәяләр һәрвакыт объектив.

WorldSkills та конкурсант педагогларның балалар белән эшләмәячәге кызыклы. Ярдәмгә балалар буларак катнашучы волонтёрлар киләчәк. Алар кайчак артыгын уйнап җибәрәләр дип сөйлиләр, шуңа күрә WorldSkillsta катнашучыларга жюри игътибары өчен генә көрәшергә туры килмәячәк.

БЕЛЕМЛЕ БУЛУ – АБУ-ДАБИГА БИЛЕТ

Республика өчен профессиональ осталык буенча халыкара конкурска әзерлек барышында туган сораулар арасында экспертларның җитеп бетмәве әлегә хәл ителмәгән. Бу катнашучыларны конкурска әзерли һәм аларның эшләренә бәя бирә алырлык зур тәҗрибәгә ия укытучыларга кытлык күзәтелә, дигән сүз. Россия күләмендә лицензиягә ия экспертлар әле бар, ә менә халыкара дәрәҗәдә танылганы бары тик берәү генә – «Флористика» компетенциясе буенча.

Ә башка яклардан карганда, Татарстан бүген үк Россия төбәкләре арасында – WorldSkills хәрәкәте буенча лидер. Казанда узган елның май аенда үткәрелгән милли этап моның шулай икәнен раслады.

ТР җыелма командасы медальләр саны буенча гомуми зачетта беренче урынны алды. Ә Финляндиядә уздырылган эшче профессияләр чемпионатында Чаллы егете Антон Лоскутов «Санлы-программалы идарә ителешле станокларда токарь эшләре» компетенциясендә беренче урынны яулады.

Әмма, кабатлап әйтәм, иң мөһиме – җиңүләр түгел. Казанда 2019 елда үткәрелергә тиешле халыкара ярышлар чараны уздыру өчен кирәкле инфраструктураны калдыру белән бергә, һөнәри белем бирү системасын реформалауга көчле этәргеч бирәчәк, дөресрәге, инде бирәләр. Бу исә үз чиратында белем бирү дәрәҗәсен сыйфат ягыннан үзгәртүгә китерәчәк.

Лего-роботны җыя алу һәм аның белән эшли белү – мәктәпкәчә белем бирү педагогына карата куелган заманча таләпләр икән.





кайда АЛАР ХӘЗЕР?

Кешеләр, хәтеребезгә күренекле, атаклы, легендар шәхесләр һәм йолдызлар булып кереп калып, тарихыбызны язалар. Гомер бик тиз уза, буыннар алмашы да шундый ук тизлек белән бара. Кайчак кичәге кумирларыбызның кайдалыгын белү өчен, хәтер төпкелләребезне актарып, хәтта ки «Татарстан» журналы хәбәрчеләренең эзләнү сәләтләренә дә таянырга туры килә.



Автор:
Татьяна Лескова

Ната Смирнова фотолары, Ирина Шәрипова һәм «MTmodels» агентлыгы архивыннан алынган фотолар

ГҮЗӘЛЛЕК АЛИҺӘЛӘРЕ

26 гыйнварда «Пирамида» мәдәният-күңел ачу үзәгендә XVIII «Мисс Татарстан» гүзәллек конкурсының финалы була. Титул өчен 30 кыз көрәшә, интрига соңгы мизгелгә кадәр саклана. Аларның тормышы шуннан соң ничек үзгәрәчәген исә әле бөтенләй фаразлап та булмый. Кайберәүләре өчен бу гомерләренең иң истә калырлык вакыйгасы, икенчеләренә исә зур мода дөньясына тәүге адым булачак. Сүзебезне дәлилләү өчен, кайчандыр «Мисс Татарстан» таҗын кию бәхетенә ирешкәннәрнең язмышларына тукталыйк.



ИҢ БЕРЕНЧЕ МИСС

Бәйге тарихында беренче җиңүче кыз – Чаллыдан **Ләйлә Кәшипова**. Конкурстан соң аңа Мәскәү агентлыгында эш тәкъдим итәләр, әмма ул баш тарта һәм туган шәһәренә кайта. Гүзәллек бәйгеләрендә катнашуын дәвам итә. Бер елдан соң Ләйлә «Мисс Россия-1999» конкурсы финалчылары унлыгына керә. Анда «Татарстан-1998 беренче вице-мисс» титулына ия Анна Круглова «Мисс Россия-1999» таҗын яулый. Аннары Ләйлә «Хрустальная корона России-2000» конкурсында «Мисс Очарование» титулына ия була. Мәктәпне тәмамлагач, кыз Чаллы сәнгать училищесында укый һәм рәссам-дизайнер дипломы ала. Башта интерьер дизайнеры булып эшли, аннары киемнәр тегүгә күчә, үзенең биш коллекциясен булдыра. Буш вакытында картиналар ясый. 4 ел буе «Fam-TV» телепрограммасын алып бара. Хәзер Ләйлә ире һәм балалары белән Түбән Камада яши.



ИҢ КҮП ТИТУЛЛАРГА ИЯ МИСС

Түбән Камадан **Татьяна Павлова** «Мисс Татарстан» таҗын 2000 елда кия. Аннары тагын берничә бәйгедә уңышлы катнаша. Казандагы җиңүеннән соң бер ел үткәч, гүзәл кыз Туниста «Жемчужина России-2001» титулын яулый, аннары «Вице-мисс Россия-2001» була. Шул ук елда, россиялеләрдән беренче буларак, Япониядә «Мисс Интернешнл-2001» титулына ия була. Киләсе елда Япониядә кабат «Вице-мисс Интернешнл-2002» булып танылa. Дөнья подиумнарында балкыр өчен бар мөмкинлекләре булса да, кыз башка юлны сайлый. Татьяна КФУның икътисад факультетын тәмамлый һәм Казан банкларының берсендә эшли. Улы бар.



ИҢ ЯШЬ МИСС

Казан гүзәле **Карина Исмәгыйлева** 17 яшендә җиңү яулый. «Мисс Татарстан-2009» титулын ул КДУның икътисад факультетында беренче курста укыганда ала. Шул ук елны «Мисс Россия-2009» конкурсында беренче 15 гүзәл арасына керә. Шуннан соң бераз вакыт Милан һәм Парижның модель агентлыкларында эшли, әмма җитди контрактлар төзи алмый. Ә менә Татарстанда Карина «Лица Универсиады» конкурсында җиңгән 6 кыз арасына керә, аның фотолары белән билбордлар Бөтендөнья студент уеннары вакытында шәһәребезне бизи. Югары уку йортында укуын дәвам итеп, Карина волонтерлар хәрәкәтендә катнаша. Сербиядәге җәйге Универсиадада һәм Сингапурдагы яшьләр арасындагы беренче Олимпия уеннарында Татарстанны презентацияләүдә катнаша.

ТАТАРСТАНДА УҢЫШКА ИРЕШТЕҢ –



«ТАТАРСТАННЫ» УКЫ!

2010



Ирина Шәрипова: «Барлык хыялларым да тормышка ашты»

ИҢ ЗУР УҢЫШЛАРГА ИЯ МИСС

«Мисс Татарстан-2010» тарихы замана Золушкасы турында әкияткә охшаган: аны кастингтагы тамашачылар арасында очраклы гына күреп алалар һәм конкурска чакыралар, ә ул анда җиңә һәм тиз арада дөнья подиумнарын яулый. Боларның кайсы дөрес, кайсы ялган соң? Бу турыда без Нью-Йорктан кайтышлый Казанда тукталган **Ирина Шәрипованың** үзеннән сораштык.

– Синең тормышыңда «Мисс Татарстан» конкурсы нинди роль уйнады?

– Җиңгәндә, миңа 17 яшь кенә иде, һәм мин нәрсә булуын аңлап та җиткермәдем, ахры. Әмма минем тормышым шундук үзгәрде. «Мисс Татарстан» булгач, мин «Мисс Россия» бәйгесендә катнашу хокукын алдым. Төрле шәһәрләрдән җыелган 50дән артык кыз отельдә яшәдек, безнең үзебезнең сакчыларыбыз да бар иде – алар рөхсәтеннән башка бер адым да атлый алмыйсың, менә шундый «алтын читлек». Аннары мин Кытайга, дөнья гүзәлләре конкурсына бардым һәм икенче урын алдым...

– Аннары Көнбатышка киттеңме?

– «Мисс Россия» конкурсында ук мине танылган модельләр агентлыгы скауты табып, чит илдә эшләргә тәкъдим иткән иде. Мин моңа бер елдан соң гына тәвәккәлләдем: Франциягә киттем, контракт төзедем. Парижда, аннары Миланда, Лондонда эшләдем. 2013 елда АКШка күчендем. Анда исә хыяллар чыннан да тормышка аша. 23 яшемә, әле КХТИ студенты чагымда ук, фатирлык акча эшләдем.



– Фэшн-индустриядә озакка калырга җыенасыңмы?

– Дизайнер буласым килә. Әмма моның өчен кимендә махсус белем алырга кирәк. Ә мода күрсәтүләр һәм фотосессияләр графигы даими түгел, шунлыктан ниндидер җитди нәрсә белән шөгыльләнү мөмкинлеге әлегә юк. Мин «Woman Management» – дөньядагы иң зур модель агентлыкларыннан берсенең вәкиле. Нью-Йоркта, Парижда, Миланда эшлим. Һәм башка агентлыкта – Лондонда.

– Нинди шоуларда катнашасың?

– Мода атналарында. Башта Нью-Йоркта, аннары Лондонда, Миланда һәм Парижда. Моннан тыш, Оскар де ля Рента, Ральф Лорен, Марк Джейкобс, Шанель, ә 2014 елдан Виктория Сикретс шоуларында катнашам. Тагын бер хыялым тормышка ашты – мин мода дөньясындагы иң кәттә шоу подиумында йөрдем.

– Модель тормышы турында балачак күзаллауларың чынбарлыкка туры киләме?

– Чынбарлык төзәтмәләр кертте. Модель эше – күңелле шоу һәм мәңгелек бәйрәм генә түгел икән ул. Бу бик авыр хезмәт тә. Иртән сәгать 8–9га эшкә киләсең, сиңа 100 тапкыр киенеп-чишенергә һәм фотога төшәргә кирәк – фабрикадагы конвейер төсле. Төн уртасында арып-талып кына кайтып егыласың.

– Шулай да, хыялың тормышка аштымы соң?

– Әйе, теләгәннәремә ирештем. Үземне модель бизнесында сынап карадым. Дольче һәм Габбана компаниясе рекламасында төштем – билбордлар, фотоларым бөтен дөньяга таралды. Танылган косметика компаниясе рекламасында төштем... Үзем хыялланганнарның барысына да ирештем диярлек. Тагын бер-икесе генә калды.

– Әлеге исемлеккә гаилә керәме?

– Хәзер түгел, 1–2 елдан. 30 яшь тулганчы кияүгә чыксам һәм ике бала тапсам, бик яхшы булыр иде. Әмма бу эштә алдан планлаштырып кына булмый шул.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Салих Сәйдәшев иҗаты **НИГӘ** мәңгелек һәм кабатланмас

Ринат Таҗетдинов **НИГӘ** сәясәтче булырга теләми

Казан **НИНДИ** серләрен һаман да саклый

Әтнәдә хәбәрчеләребезне **НӘРСӘ** белән сыйлаганнар

Астролог фаразынча, 2016 ел Татарстанга **НИЛӘР** вәгъдә итә

PRESSA.RU



Фото: www.park.tatar



ПАРК
ҺӘМ АНДАГЫ КЕШЕЛӘР

ТР Президенты ярдәмчесе Наталия Фишман иҗтимагый пространстволарның һәм активистларның бер-берсен формалаштыруы турында сөйли.

Кайвакыт шулай Тинчурин паркында очраган әбинең сиңа рәхмәт укуын ишетәсең дә кешеләрнең барысын да күрүен һәм дөрес бәяләвен аңлыйсың. Безнең Татарстанда социаль челтәрләрдәге шәрехләүләргә күз салсак, шундук бер нәрсәгә игътибар итәсең: аудитория әлеге киңлекне тәнкыйтьләү өчен уңайлы урын итеп кабул итә, ә уңай үзгәрешләрне (әгәр ул бәйрәмнәргә һәм башка шундый эмоциональ контентка карамый икән) бик еш кына искә дә алмый.

Мәскәүдә хәлләр башкачарак. Анда мәнфәгатьләре, социаль кыйммәтләр турындагы күзаллаулары, белем дәрәҗәсе бер чамадагы кешеләрдән торган критик масса аудитория булып формалашкан, адресат тәгаен билгеле. Әлеге аудиториянең бер-берсе белән аралашуы мәҗбүри түгел, әмма аларны бер үк медиа берләштерә, алар бер үк кыйммәтләргә табыналар. Мәскәүдә парклар реформасы башлангач, кешеләр әлеге пространствоның үзләре өчен булуын аңладылар һәм, килеп, бөтен кешеләр өчен бер булган үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен булдырдылар.

Казанда исә вазгыять башкачарак – без әле үз аудиториябезнең кем булуын, аның нәрсә теләвен һәм аның белән ничек дөрес аралашырга кирәклеген һәрвакытта да аңлап җиткермибез. Әмма ничек тә уртак тел табарга тырышабыз, һәм, минемчә, бергәләшеп шактый уңышка да ирештек: быел без коммуникация, кире элемтә, шәһәрлеләр белән аралашу ягыннан сизелерлек алга киттек. Һәм бу соңгы нәтиҗәгә тәэсир итә, алга таба да итәчәк – яшәүчеләр тарафыннан расланмаган очракларда без проектларны җиренә җиткереп эшләп бетерү өчен кире борабыз.

Мин каршылыкларның конструктив хәл ителүе яклы. Мәсәлән, архитектор Максим Смирнов Казан паркларына урнаштырыла торган балалар мәйданчыкларының сыйфатыннан канәгать түгел иде. Без Максимны әлеге мәйданчыкларны җитештерә торган предприятиегә алып бардык. Аңа җитештерүне күрсәттеләр, тегe яки бу чишелешнең ни өчен кулланылуын аңлаттылар. Һәм ул үз дәгъваларының урынсыз булуын таныды. Минем өчен Максим кебек кешеләр бик мөһим, чөнки алар мохитне үзгәртергә, ягъни үз фикерен якларга да, шул ук вакытта үз ялгышларын танырга да әзер.

Халык белән күп очрашулар үткәрдек, шактый кызыклы һәм файдалы нәрсәләр белдек. Тамара исемле хатын бигрәк тә хәтеремдә калды, ул миңа хайваннарның Тинчурин паркына җирләнүенең сәбәпләрен аңлатты һәм әлеге каберлеккә тимәскә кирәклекне дәлилләде. Очрашуларның берсендә халык артлы эскәмияләр куймауны сорады, чөнки анда хулиганнар менеп утыра икән. Без өстенә менеп утырып булмый торган биек артлы эскәмияләр ясаттык. Ягъни бөтен кешене канәгатьләндерә торган чишелешне һәрвакыт табып була, бераз тырышырга гына кирәк.

Тик шулай да безгә тәнкыйть ява гына. Бу – нормаль күренеш, бу да кире элемтә барлыгын күрсәтә. Миңа Рөстәм Нургали улының моңа булган мөнәсәбәте ошый. Минем эшчәнлегемнең җитәкчесе буларак, ул «Парклар һәм скверлар» командасының халык белән аралашу форматын хуплый. Ул безнең адреска килеп ирешкән негативка да конструктив карый, моны киләчәктә эшләү өчен файдалы мәгълүмат, тыныч эшләргә мөмкинлек тудыручы мөһим фактор буларак бәяли, кайчак чиновниклар игътибарны җәлеп итә торган ачык тәнкыйтьтән куркалар бит.

Әмма кешеләр үзләре дә аңларга тиеш – әйләнә-тирә мохитне аларга беркем дә төзеп бирмәячәк. Территорияне төзекләндереп була, әмма аның киләчәктәге халәте шундагы кешеләрнең активлыгына бәйле булачак. Әгәр алар нинди дә булса акция, бәйрәм, спорт чарасы үткәрергә тели икән, үзләренә башлап йөрергә кирәк. Без гамәлгә кертү механизмнары белән булышырга әзербез. Минемчә, тормышка ашырылган инициативалар туплана барган саен, халык моны күрер, үз көченә ышаныр, һәм актив кешеләр саны да артыр әле.

Бу җәһәттән Татарстан районнары алып барган эшчәнлек сөендерә. Анда үзеңне территория белән тәңгәлләштерү дәрәҗәсе башкарак. Зур шәһәрләрдә үзеңне каланың хуҗасы итеп тою шактый кыен, ә менә кечкенә торак пунктларда бу яктан җиңелрәк. Бервакыт Түбән Камадагы «Тукай» паркына сугылдык – үз вакытында без анда бик күп эш эшләгән идек, һәм мин аны бик яратам. Октябрь башында, эш көнендә, иртәнге сәгать тугызда паркта шактый күп халык йөрүен күреп куаныштык.

Проектларыбызда интерактив формат кулланырга тырышабыз, анда һәркем инициатива күрсәтә һәм үзенең ял итү территориясенең нинди булачагына йогынты ясый ала, шул рәвешле бер идея икенчесен тудыра. Минем уйлавымча, дөрес үсеш алган очракта, бу процесс шәһәрләр һәм аларда яшәүче халык арасындагы мөнәсәбәтләрнең яхшы якка үзгәрүенә китерәчәк.



АКСЫЛ КОСТЮМЛЫ ЯЛГЫЗ ДЖЕНТЛЬМЕН



Автор: Ольга Туманская

«Ул Горький урамындагы театр янында йөрергә ярата. Менә дигән урын – ыгы-зыгы юк, һәрчак тыныч. Өе дә янәшәдә, ишегалдында гына, аерым йорт түгел-түгелен, шулай да ярап тора. Ягымлы, җылы кеше икәнлеге абайланса да, өйдә утыруны үз итә торганнардан түгеллеге шунда ук күзгә ташлана. Уйчан карашы каядыр төбәлгән, әйтерсең, нидер ишетелә аңа. Шул моңнан сихерләнеп басып тора да – капка төбендә, театр янында, йорт почмагында…»

«УЛ БИТ БЕЗНЕҢ СӘЙДӘШ!»

1954 елның июнь иртәсе. Казан бәйрәм каршыларга әзерләнә – Сабан туен. Горький исемендәге паркта зур концерт узарга тиеш. Оркестр белән Салих Сәйдәшев дирижёрлык итәчәк. Бу көннәрдә аңа кунакка Яр Чаллыдан килене Вера белән олы улы Альфред килеп төштеләр.

– Салих Җамалетдинович миннән костюмын хәстәрләп куюымны үтенде. Аксыл төстәге киндердән тегелгән костюм – җәйләрен ул гел шуны кия иде, – дип искә ала Вера Петровна. – Камал театры янында, Горький урамында (хәзер монда Тинчурин театры урнашкан) яши иде ул. Паркка – кул сузымы гына ара. Әмма безгә анда барып җитәр өчен өч сәгать вакыт кирәк булды…

Сәйдәшне адым саен туктаталар – һәркемнең аның кулын кысасы, кочасы килә. Ул берәүне дә игътибарсыз калдырмый – хәл-әхвәл белешә, елмая, сөйләшә.

– Ничек һәр узган-барганга сабыры һәм илтифаты җитә икән, дип уйлап куйдым ул чакта. Карыйм: мин тырыша-тырыша хәстәрләгән костюм әкренләп йомарлана һәм керләнә бара…

Парк янына җиткәндә, Сәйдәшевне бер төркем эшчеләр уратып ала. Өсләрендәге кием майга батып беткән, сменадан кайтышлары. Алар да композиторны кочакларга керешә. Шулчак Вераның түземе төкәнә: «Саграк булыгыз, зинһар, костюмын пычратмагыз!» Тегеләр исә бертавыштан җавап кайтара: «Ул бит безнең Сәйдәш!»

Халкының чиксез мәхәббәтен Сәйдәш үзе сиздеме икән соң? Әлбәттә. «Капкадан чыгуыма, минем өчен кырык җирдә кырык самавыр кайнап утыра», – дип шаяртырга яраткан ул. Әмма «йолдыз чире» белән чирләмәгән. Халыкта үзенә карата булган тугры, какшамас хисне зур рәхмәт хисләре белән кабул иткән, гомеренең соңгы көннәренәчә җылытып килгән Сәйдәшне бу мәхәббәт. Иң авыр чакларында – хезмәттәшләре йөз чөергәндә, дуслары ташлап киткәндә, эшләргә мөмкинлек бирмәгәндә…



ТУКАЙНЫҢ СОҢГЫ ҖЫРЫ

Бәләкәй пианист «Әллүки»не уйный – Тукай өчен. Махсус. Шагыйрь үзе уйчан гына янәшәсендә утыра – сәләтле Салихның уйнавын тыңларга дип килгән ул. Кинәт Тукай, музыкага кушылып, әкрен генә көйли башлый. Музыка белән шагыйрь тавышы бербөтенгә әверелә. Тукайның тавышы көчәя төшә. Ул җырлый, ә тирә-юньдәгеләр сулыш алырга да кыймыйча тыңлый. Әмма бу алдан юрап куелмаган мизгел шулай ук кинәт кенә өзелә дә – шагыйрьнең тамагыннан кан китә. Баксаң, бу аның соңгы җыры булган икән…

Иҗат әһелләре Әхмәровлар йортыннан беркайчан да өзелми. Салих Сәйдәшев шул йортта үсә. Әтисе Җамалетдин улы туар алдыннан гына дөнья куя. Гаиләсен, ягъни хатыны Мәҗүпҗамал, улы Салих белән олы кызы Әминәне кайгыртуны ул үзенең приказчигы Насретдин Хәмитовка йөкли. Бу миһербанлы кешедә Салих 11 ел яши, ә апасы Әминә нәшир Шиһаб Әхмәровка кияүгә чыккач, әнисе белән Әхмәров йортына күченәләр.



Салих Сәйдәшев Насретдин Хәмитов гаиләсе белән. Әлеге гаиләдә ул 11 яшькә кадәр тәрбияләнә. 1910 ел.

Нәкъ менә нечкә тоемлы, укымышлы Шиһаб Әхмәров кечкенә Салихта музыкага сәләт барлыгын сизеп ала. Ул аны үстерер өчен күп көч куя – рояль ала һәм ул чактагы танылган пианист, «Тукай маршы»ның авторы Заһидулла Яруллинны Салихны укытыр өчен өйгә чакыра. Инде 13 яшендә Салих беренче татар труппасы «Сәйяр» оркестры белән чыгыш ясый. Нәкъ менә шул чыгыштан аның театр белән туганлыгы башлана да.

> Бик тыныч, үзен һәрчак кулда тотучан Сәйдәш хатыны үлгән көнне рояль капкачына капланып елый. Бик тиздән дөнья аның яңа әсәрен – «Сакай маршы»н ишетә.

КАГЫЛЫП ҮТКӘН БӘХЕТ

Валя Мухина исемле сөйкемле, зыялы кыз Шиһап Әхмәровның сеңлесе Зәйнәпнең якын дусты була. Медицина факультетында бергә укыйлар алар. Валя музыканы ярата һәм тоя гына түгел, ә үзе дә бик әйбәт уйный. Яшь Салихның аны ошатуы бер дә гаҗәп түгел. Музыка аларны берләштерә, күңелләренең бер дулкында булуын тоя яшьләр. Милләтләренең төрле булуы да борчымый Салих белән Валяны, әмма Әхмәровларның дини тәрбия алып үскән әбекәйләре яшьләрнең бергә булуын хупламый. Көннәрдән бер көнне гашыйклар, берәүгә дә хәбәр итмичә, юкка чыгалар. Кире кайтып төшкәндә, алар инде язылышкан булалар. Салих белән Валяга ачуланырга да мөмкин булмый – аларның бәхете ташып тора. Эчкерсез, мөлаем Валя тиз арада бу зур һәм тату гаиләнең аерылгысыз өлешенә әверелә.

Сәйдәш бәхетенең чиге булмас кебек тоела, әмма язмыш үз төзәтмәләрен кертә. Сәйдәшкә беренче улларын – Альфредны бүләк итә дә, сабые туып берничә көн узгач, Валентина каны агуланудан үлеп китә. Бик тыныч, үзен һәрчак кулда тотучан Сәйдәш хатыны үлгән көнне рояль капкачына капланып елый. Бик тиздән дөнья аның яңа әсәрен – «Сакай маршы»н ишетә. Сәйдәш аны дусты – артист Нури Сакаевны озаткан вакытта кәгазь кисәген тезләренә куеп яза. Бу маршның аһәңнәрендә Сәйдәш йөрәгенә җыелган бар газап, бар моң чагылыш тапкан гүя.

Валентина белән узган еллар, мөгаен, аның тормышындагы иң бәхетле еллар булгандыр. Икенче һәм өченче хатыннары турында истәлекләр әллә ни күп сакланмаган. Әмирхан Еники болай язып калдырган:

«Без якыннан 1945 елда, мин сугыштан кайткач таныштык. Ул чагында Сәйдәш Асия белән яши иде. Аның хакында әллә ни әйтә алмыйм. Без Салих белән пианинода уйнап утыргалыйбыз, ә Асия безнең якка чыкмый иде… Сафияне дә белә идем мин. Бик чибәр, сөйкемле, әмма артык җилбәзәк иде…»




ПИОНЕР СӘЙДӘШЕВ

«Әти бик иртә тора. Менә ул тәрәзә янына килә. Агач ботагына кунган кошларны дикъкать белән күзәтә, ә үзе ишетелер-ишетелмәс кенә көй көйли», – дип искә ала Сәйдәшнең кече улы Нәүфәл. Яраткан авылы Кызыл Байракта сәгатьләр буе Идел ярында кармак салып утыра торган була Сәйдәш. «Балык тотканда әти һәрчак тын гына нидер көйли иде. Мин аңа әйтәм: «Тавышланма, балыкны өркетәсең». Ә ул: «Балык музыканы ярата ул, сихерләнеп, безгә таба килсен өчен махсус көйлим», – дия иде.

Сәйдәш үзе «колагымда гел музыка яңгырап тора», дия торган булган. Күбрәк илһамга көйләнеп язган, илһамы килгәндә, башка бер эшкә дә бүленмичә, тиз һәм онытылып иҗат иткән.

1922 елда күрсәтмә чыгышлар өчен, татар дәүләт драма театры оештырырга кирәк, дигән карар кабул ителә. Бу миссияне режиссёр Кәрим Тинчуринга йөклиләр. Музыкаль эшчәнлекне оештыруны, җитәкләүне Тинчурин, үз чиратында, яшь композитор – Салих Сәйдәшевка йөкли. Хәбибулла Ибраһимовның «Башмагым» комедиясенә музыка язарга тиеш була Сәйдәш. Премьера вакытында дирижёр пультына яшь композитор үзе баса.


Салих Сәйдәшев һәм Кәрим Тинчурин.

Аннан Сәйдәш «Сүнгән йолдызлар»га бик шәп увертюра иҗат итә. «Галиябану», «Ил», «Зәңгәр шәл», «Наёмщик» спектакльләренә музыка яза. Әмма коллегалары аерым бер игътибар белән искә алган эше «Кандыр буе» музыкаль пьесасы була.

Пьесаның авторы – Кәрим Тинчурин үзе, спектакльне әзерләү вакыты бик аз, ә эшнең иге-чиге юк – егерме җыр һәм аерым балет! Тинчурин – ашыктыра, Сәйдәш – борчыла, дулкынлана. Нәтиҗәдә композитор бу тау кадәр эшне егерме көндә каһарманнарча башкарып чыга.

Ул татар профессиональ музыка сәнгатенең чишмә башында торган зат. Аның пионеры. Сәйдәшнең музыкаль драмаларында бик күп формалар бербөтенгә әверелә. Шул исәптән балет музыкасы да. Танылган балетмейстер Гай Таһиров әйтүенчә, милли хореографик сәнгатьнең шулкадәр уңышлы үсеп китүе, Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты кебек җитлеккән, камил әсәрнең дөньяга тууы, һичшиксез, Сәйдәш иҗаты куйган югары бурычлар белән тыгыз бәйләнгән. Сәйдәшнең хореографик һәм балет номерлары булмаса, беренче милли балетның андый кыска вакыт эчендә барлыкка килүе мөмкин эш булмас иде.

Олпат шәхес булуына карамастан, Сәйдәш бик тыйнак һәм иҗат мәсьәләсендә һәр яңалыкка ачык кеше була. Аңардагы тагын бер гаҗәеп сыйфат – ул тәнкыйтьне кабул итә белгән. Теге яки бу әсәрнең музыкаль бизәлешен эшләгәндә, һәрчак автор белән киңәшләшкән. Өзеген уйнап күрсәтә торган булган, авторның фикерен белешкән. Соңыннан тагын үзенә чакырып алып, уйнап күрсәткән: «Карале, мин менә бу урында, синең киңәшеңне истә тотып, болайрак үзгәрттем».

ИТСЕЗ АШ ҺӘМ КИРЕБЕТКӘН ИШӘК

Кәрим Тинчурин Сәйдәшне бик ярата. Шулкадәр ярата ки, берсендә аңа хәтта… роль тәкъдим итә! Актёр һәм режиссёр Хәким Сәлимҗанов бу кызык очракны менә ничек искә ала.

«Җилкәнсезләр» спектаклендә Казан сәүдәгәрен уйнарга туры килде. 1927 елгы җәйге гастрольләрдә Сәйдәш, грим салып, сакал-мыеклар ябыштырып, үз ролен уйный. Әмма актёрлык һөнәре барып чыкмый Сәйдәшнең. Сәхнәдә ул еш кына текстны бутый, башка сүзләр кыстырып җибәрә. Шулай Мисбах хаҗи тузына башлый торган хәйрия җыены күренешендә Салих кинәт кәмит тавыш белән: «Әй, китсәнә, ахмак хаҗи, чебеннәргә азык булсаң ие!» – ди. Сәхнәдәге артистлар да, пәрдә артында торганнары да, тыела алмыйча, көлә башлыйлар, ә Батырҗан ролен уйнаган Кәрим Тинчурин үзе, түзмичә, көлә-көлә өстәл астына кереп китә».

Сәйдәшне яхшы белүчеләр һәрчак аның юморын искә алалар – йомшак, әдәпле була ул юмор. Композитор шулай ук бик күп кәмит тарихлар һәм анекдотлар остасы да була. Сәйдәш дусларының күңелен күтәрергә ярата, кайвакыт үзе дә һәртөрле мәзәк вакыйгаларның каһарманына әверелә. Мәсәлән, СССР буенча беренче гастрольләре вакытында ТДАТ Донбасска килеп төшә. Кечкенә посёлокларда эшләүче күпчелек эшчеләр – эштә, театрның монда аз гына акча эшләү мөмкинлеге дә юк, димәк. Вокзал янындагы ресторанда нәрсәгә акчалары җиту-җитмәвен ачыклаганнан соң, артистлар беренче блюдоны гына алырга булалар. Аш китерүләре була, болар шунда ук исәп-хисап ясауларын да үтенәләр. Сәйдәш, кесәләрен актарып, бер уч вак акча чыгара да: «Җитмәс, ахрысы», – дип, авыр сулап куя. «Кайгырмагыз», – ди официант. Аштан ит кисәген ала да, аны алып киткәндә, өстәп куя: «Тынычлап ашагыз, менә хәзер тәртип!» – ди.

Ә хәзер Сәйдәшне ишәккә атланган рәвештә күз алдына китереп карыйк. Киребеткән хайван зур күлдәвек уртасында кымшанмыйча басып тора, өстендәге җайдакның әйдәкләвен бар дип тә белми. Төшә дә алмый җайдагыбыз – аягындагы ак киндер ботинкаларын жәлли. Боларның тирәсенә ачык авызлар җыела. Казахстандагы гастрольләр вакытында була бу хәл. Шәһәрне карап йөргән чакта директор Зәйни Солтанов Сәйдәшкә кызык өчен генә ишәккә атланып йөрергә тәкъдим иткән була. Ахыр чиктә, ишәкнең үзен дә, композиторның ботинкаларын да ишәк хуҗасына коткарырга туры килә.

«Бу тормышны сөючән матур күңелле кеше өстәвенә бик җор күңелле мәзәкче дә иде. Салихны якыннан белә торган кешеләрнең берәрсе булса да аның төшенке күңел йә караңгы чырай белән йөргәнен хәтерлиме икән? 1954 елның азагында, гомеренең соңгы көннәрендә дә, авыру Сәйдәш ята торган палатага Әхмәт Фәйзи белән икебез килеп кергәч, ул безне елмаеп һәм шаяртып каршылады», – дип яза драматург Габдрахман Минский.

Әмма «җор, мәзәкчән кеше» трибунага чыгуга, шунда ук бу сәләтен югалта торган була. 1929 елда Кызыл Армиянең 11 еллыгына багышланган тантаналы кичәдә Салих Сәйдәшев үзенең атаклы Маршын татар полкына тәкъдим итә. Моңа җавап итеп, композиторга тулы мундир һәм мактаулы кызылармияче исеме бирәләр. «Шулчакта Сәйдәш ике җөмлә кысып чыгара алды: «Менә яздым… Сезнең өчен…» Һәм, эшенең нәтиҗәсен күрсәтергә теләпме, оркестрга ымлады. Аннан: «Рәхмәт сезгә», – дип өстәде. Калганын аның гүзәл музыкасы әйтеп бетерде», – дип искә төшерә Гай Таһиров.

ӨЙДӘ АЯК ОЧЛАРЫНА ГЫНА БАСЫП ЙӨРИ ИДЕ…

«Шлем» спектакленең премьерасы. Сәхнәдә – кызылармиячеләр, залда да – алар. Финал! Сәйдәш маршы – диварлар тетрәп тора. Тамашачы гөрләтеп кул чаба. Марш тагын бер кат яңгырый. Хисләнүнең соң чигенә җитеп, тамашачы кызылармиячеләр сәхнәгә – актёр-кызылармиячеләрне кочакларга ташланалар. Бу тамашаны пьесаның авторы Габдрахман Минский күзәтеп тора. «Менә режиссёрны сәхнәгә йолкып чыгаралар». «Сәйдәш! Сәйдәш!» – дип шаулый халык. Аптырабрак калган, әмма гадилеген җуймаган Салих тыйнак кына, хәтта үзен гаепле хис иткәндәй, сәхнәгә чыга. Зал гөрли. «Әй, туган, күр әле, бу Сәйдәш дигәннәре нәкъ безнең шикелле икән бит! Ә каян алып яза икән ул бу әсәрләрне?!» – дигән репликалар яңгырый солдатлар арасында.

20 нче еллардан башлап, Сәйдәш музыкасы бөтен җирдә яңгырап тора. Ә ул, үзенең чиксез популярлыгына һәм халык мәхәббәтенә карамастан, әдәплелек һәм кеше язмышына карата сизгерлек кебек сыйфатларын саклап кала ала. Шулай бер чак Сәйдәш күршесе Хәким Сәлимҗановның яшәү шартлары бик кыен булуын белеп ала – ике бүлмәдә ун кеше яшиләр тегеләр. Композитор шунда ук актёрның туганнарына үз фатирына күчәргә тәкъдим итә. Шулай итеп, булачак сынчы Рада Нигъмәтуллина, әнисе һәм туганы белән, Сәйдәш йортына эләгә. Аларны иң гаҗәпләндергәне – Сәйдәшнең йорт шартларындагы гадилеге. Композиторның бердәнбер костюмы була, ул аны гел киеп йөри. Ап-ак күлмәге һәрчак чип-чиста итеп юылган, тип-тигез итеп үтүкләнгән булыр. Кышларын Сәйдәш каракүл якалы пәлтә һәм башлык кия – бөтен байлыгы шул. Фатиры да нәкъ гардеробы кебек үк – гади һәм тыйнак.

Театр мохитендә аның турында сүзләр йөри, гайбәтләр ишетелеп тора. Сәйдәш исә: «Эт өрә, кәрван йөри», – дип кенә җавап кайтара торган була. Үзе исә беркайчан да пәрдә арты бәхәсләренә, әңгәмәләренә катнашмый.

«Ул бик нәзакәтле, сак кеше иде, хәер, моны безнең хакта да әйтергә була. Без – ярар, аңлашыла инде, кеше йортында торабыз бит, хәлебез шундый. Әмма ул бит – фатир хуҗасы, бар халыкка исеме билгеле танылган композитор, ә үзе өйдә аяк очларына гына басып йөри!» – дип искә ала соңыннан Рада Нигъмәтуллина. Кечкенә Раданың хәтеренә бигрәк тә Сәйдәшнең моңсу чаклары, сәгатьләр буе үзенә бикләнеп уйланып утырулары сеңеп калган. Өйдән чыгуга шат күңелле, аралашучан, җор теллегә әверелә торган Сәйдәш, фатирына кайткач, бөтенләй башка халәткә керә торган була…

«ЭТ ӨРӘ, КӘРВАН ЙӨРИ…»

1938 ел Сәйдәш өчен аеруча авыр ел була. Кадерле дусты һәм аркадашы Кәрим Тинчуринны югалта ул, аның артыннан ук Фәтхи Бурнашны. Аларның пьесаларына иҗат иткән музыканы башкарырга ярамый башлый, ул тыела. Әмма Сәйдәш «калкандай булып кала бирә, үзгәрми». Театр мохитендә аның турында сүзләр йөри, гайбәтләр ишетелеп тора. Сәйдәш исә: «Эт өрә, кәрван йөри», – дип кенә җавап кайтара торган була. Үзе исә беркайчан да пәрдә арты бәхәсләренә, әңгәмәләренә катнашмый.

Бервакыт газета чыга, анда бүләккә тәкъдим ителүчеләрнең исемлеге басылган була. Сәйдәшнең бер танышы газетаны актарып чыга да Сәйдәшкә эндәшә: «Карале, синең исемең юк монда! Ә, Салих?» – ди. Сәйдәш үзенә генә хас нечкә юмор белән җавап кайтара: «Ничек инде мин булмыйм? Менә ич мин. Син яңа гына минем исемне атадың! Ул исем миндә һәрчак бар иде, хәзер дә бар!» Ул үз бәясен яхшы белә. Нык тора. Аны халкының мәхәббәте һәм җылысы коткара.

Тиздән тарихка кереп калган күңелсез вакыйга – композиторларның атаклы пленумы узачак. Сәйдәшне монда үз алдында ук оялмыйча пычратачаклар. Кайберәүләр трибунадан: «Сәйдәш – артта калган этап инде ул!» – дип кычкырачак. Аны кинәт, көтмәгәндә-уйламаганда, «музыканы үзлегеннән өйрәнгән талантлы җыр язучылар», ярымпрофессионаллар исемлегенә кертәләр, имеш, ул заманча музыкаль жанрларны бөтенләй белми. Дөрес, композиторны яклап чыгучылар да табыла…

1948 елда Сәйдәшне театрдагы эшеннән азат итәләр. Бер генә тантана, бәйрәм дә Сәйдәш иҗат иткән марштан башка узмый, ә композитор үзе очраклы һәм тиен-миен гонорарлар хисабына яшәргә мәҗбүр була. Ул елларда Сәйдәшкә музыкантларга караганда, язучылар һәм журналистлар күбрәк ярдәм итте, дип искә алалар. Каләм әһелләре композиторга үзләренең иң шәп шигырьләрен китерә, ә Сәйдәш аларны җырга әйләндерә.

«Елмаюы, кешеләргә карата булган игелекле мөнәсәбәте артында яшеренеп яткан сагышның, фаҗигале нотаның без шулай да шаһитлары була алмадык… Ә ул, күрәсең, кешеләрдән башка иҗат итә алмаган, ә иҗат итмичә, гомумән яшәүнең мәгънәсен тапмаган… Аның берәүгә дә зарланганын күргәнем булмады, ул бары соклангыч ак күлмәген кия, муенына «күбәләген» тага иде дә, капкадан дөньяга чыга… Аңа кемнеңдер җавап итеп елмаюы кирәк булган, мөгаен, кешелекле җылы сүз… Дулкын комга чыгарып бәргән кабырчыктагы әкәм-төкәмдәй кибәсе килмәде Сәйдәшнең, тулыканлы тормыш белән яшәргә теләде ул…» – дип яза композитор турында Празат Исәнбәт.

Һәм менә 1954 ел. Сәйдәш театр янындагы Горький урамы буйлап йөреп тора. Менә дигән урын – ыгы-зыгы юк, һәрчак тыныч… «Кыяфәте буенча да, үзен тотышы буенча да искиткеч оригиналь джентльмен» – әнә шундый булып кереп калган ул хәтеренә Әмирхан Еникинең. Бу аларның соңгы очрашуы була. Сәйдәш Мәскәүгә тикшеренергә китәргә тиеш була. Кыска гына вакытка, дип исәпләсә дә, чынлыкта мәңгегә китүе була аның. Бәлки, эчтән генә үзе сизгәндер, шуңа да аеруча сабыр, җыйнак һәм сагышлы булгандыр. Әйе, ул һәрчак кешеләр арасында – аңа эндәшәләр, сәламлиләр, уратып алалар… Әмма Еники ул көләч кояшлы көнне кинәт башка Сәйдәшне күреп ала һәм ихтыярсыздан пышылдый: «Йа Ходам! Ул коточкыч ялгыз бит!» Артыннан карап калганда, шулай ди. Ә Сәйдәш ак костюмыннан килеш урам буйлап китеп бара…



Салих Сәйдәшев ис. Зур концерт залы фойесында Салих Сәйдәшев бюсты.

ИҢ ЗУР БӘХЕТ – ЭШЛӘП ТАПКАН БӘХЕТ

Очрашуыбызның сәбәбе – ул алган дәрәҗәле бүләк. «Алтын битлек». Россия театр дөньясында кайнаган шәхесләр өчен бу бүләк Голливудның Оскарыннан һич тә ким түгел. Хәер, чагыштырырга кирәкми. Озын сүзнең кыскасы, очрашуыбызның сәбәбе – аның чираттагы уңышы. Шулай дип уйладым мин Ринат абый янына барганда. Әмма хикмәт анда гына булмаган икән.



Автор:
Луиза Янсуар

Аның белән театр коридорларында очрашканда, исәнләшеп йөрим. Ул да исәнләшә. Әмма без таныш түгел. Бу сәламләшү – табигый әдәплелек билгесе генә. Әңгәмә корырга килгәч, ул, беренче эш итеп, миннән гафу үтенде: «Бик таныш тоеласыз, күргәнем дә бар-барын, әмма никтер мин сезне белмим». «Бик яхшы, Ринат абый, димәк, сөйләшүебез ихласрак булыр», – дидем. Шуннан безнең танышу ноктасы башланды.

Ринат Таҗетдиновка «Алтын битлек» бирелгән, дигән хәбәрне ишеткәч, куандым. Балачактан хәтеремә кереп уелган образлар күз алдыннан йөгереп узды: Ильяс, Мирвәли, Муса, Кол Гали, Идегәй... Алар миндә тирән ихтирам уята иде. Актёрга карата. Ә менә Ринат абыйның шәхесе белән очрашкач, ихтирам тагын да тирәнәйде – инде кешегә карата. Гап-гади кеше белән очраштым һәм аңардагы нәкъ менә шул гадилеккә, хәтта ки тормышчан гадәтилеккә сокландым. Икенче сокландырган нәрсә – әңгәмә буенча рефрен булып кабатланган сүзләре булды: «Мин бик бәхетле кеше». «Дәрәҗәле исемнәр, бүләкләр... – бәхет бит аларда түгел, – ди Ринат абый. – Дөрес, эшләгән эшеңне бәяләсәләр, зур куаныч. Әмма бәяне аңарчы инде тамашачы биргән була. Иң зур бәхет – эшләп тапкан бәхет...»

Хәзер сүзне Ринат абыйның тулаем үзенә тапшырам.

Фотолар: Александр Эшкинин

«ЧЫН ЭШЕҢ ЮКМЫНИ, РИНАТ?»

Безне Вазыйх абый укытты математикадан, бик яхшы укытучы иде, әмма сәләтем булмагач, кем укытса да – барып чыкмады. Гуманитар фәннәр якын иде. Әпсәләмовларны укып саташып үстек бит без. Мәктәптә дә, авыл сәхнәсендә дә гел спектакльләр куела иде – мине кечкенә эпизодларга кертәләр. Урта мәктәпне күрше авылдан 5 км йөреп укыдым. Җәйләрен – сәпиттә, кышын – чаңгыда. Спектакльләр соң бетсә дә, баш тартмый идем.

Татар дөньясын әсир иткән Илһам Шакировның яңгырап торган чаклары. Минем дә шундый җырчы буласым килә... Мәктәпне тәмамлагач, киттем консерваториягә. Җиңел генә барып кереп була, дип уйлыйм. Нота-фәләнне дә белмим үзем, уен коралллары турында әйтеп тә торасы юк. Тыңладылар, тавышың бар, диделәр, музыка училищесына барырга киңәш иттеләр. Әти әйтә: улым, гәҗиттә Мәскәүдәге театр училищесына бер төркем татар балаларын җыялар, дип язганнар, бәлки, шунда барырсың, ди. Алты баласының да нәрсәгә сәләтле, нинди юлдан китәргә тиеш булуын анык белә иде. Ул чакта артист һөнәренә авыл җирендә җитди карамыйлар. Мин инде тәмам танылган актёр булгач та: «Ничә ел эшлисең инде театрда? Чын эшең һаман юкмыни, Ринат?» – дип сораучылар бар иде.

Музыка училищесына да уздым, әмма Илһам кебек фигуралар булганда, икенче сортлы җырчы булып тик йөрер идем. Ә үз эшеңнең иң югары сортлы остасы булырга кирәк!

1956 елда Мәскәүгә укырга киттек. Яхшы укыттылар. Актёрлык осталыгы турында гына әйтмим, безгә, авылдан килгән малай-кызларга, югары культура бирделәр – көн дә бушлай Мәскәү театрлары куйган спектакльләргә йөрибез, Европадан килгән театрларының постановкаларын карыйбыз, Третьяковкада лекцияләр уза... Кече театрда 5 ел буе массовкада йөрдек – халык булып. Зур дәрес, чөнки монда олпат артистларның осталыгын, профессиясенә булган мөнәсәбәтен күрәсең.

Казанда да ул чакта театр көчле иде! Мәскәүдәге укытучылар, тәнкыйтьчеләр дә әйтә иде моны. 1957 елда Мәскәүдә Татар театры декадасы булды, «Хуҗа Насретдин» белән «Король Лир»ны алып килделәр. Ниләр кичергәнемне сүз белән аңлатып бирә алмыйм, соклануга патриотик хис тә кушылгандыр, мөгаен...

Тырыш студия булдык: 23 кешедән 19ыбыз туган театрга әйләнеп кайттык. Көтеп алганнар иде. Бу зур бәхет – алган һөнәрең буенча сине кайдадыр эшкә көтеп торулары. Хәзер вазгыять күпкә катлаулы. Яшьләргә һөнәре буенча эш табу авыр. Актёр кешене бу бөтенләй бетереп ташларга мөмкин – сәхнәгә чыкмаса, сүнә ул, үлә.



БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ САТМАДЫК

Без, щепкинчылар, тату булдык. Ярдәмләшеп яшәдек, сатмадык бер-беребезне. Тормыш авыр иде, шул да берләштергәндер. Кайттык театрга, торыр урын юк. Театрның тулай торагы булмагач, төрле җирләргә таратып урнаштырдылар – иске йортлардагы кечкенә генә бүлмәләргә, подвалларга. Әмма без канәгать: эшебез бар, баш өстендә түбә дә булды, ялгыз кешегә тагын ни кирәк?! Эш хакы – 60–70 сум. Ашарга җитә, әмма өс-башны әллә ни хәстәрләрлек түгел. Акча булсын, дип, радиода эшли идек, телевидениедә – фильмнар дубляжлауда. Ул чакта радиоспектакльләр бик популяр – халык таңнан торып шуларны тыңлый да, ашап-эчеп, эшкә китә. Фондларда саклана безнең язмалар. Көн тәртибе мондый: иртән радиода язылабыз, аннан, сәгать 11ләрдә, театрда репетицияләргә керәбез, кичке спектакльгә кадәр вакыт калса, кабат радиога язылырга, йә дубляжга йөгерәбез, уйный торган көн булса, кичен спектакльгә чыгабыз, йә башкаларның уенын карыйбыз... Бәлки, вакытыбыз шундый тыгыз, тормышыбыз кайнап торгангадыр, без, бозылып, яман юлга кереп китмәдек. Хәтта җәйләрне дә көтеп ала идек – гастрольләрне. Беренче кызым Руфинәне тугач та, өч айдан соң гына күрдем.

КӨН АРАЛАШ ХАТ АЛЫША ИДЕК...

Щепкинда бергә укып кайткан кызлар безне «авыл» дип исәпләде, якын китермәделәр. Күбесе ялгыз калды, гаилә кора алмады. Без, егетләр, бәлки, һуш китәрдәй дә булмагандыбыздыр, интеллигентность та җитеп бетмәгәндер, әмма төпле идек. Хәзер дә күбебез беренче өйләнгән хатыннары белән яши.

Берсендә кибеткә азык-төлек алырга кердем. Сатучы ханым танып алды: «О, Ринат Таҗетдин... Сез бит инде анда театрда барыгыз да гулякалар», – ди бу. «Сез үзегез кияүдәме соң?» – дип сорыйм. «Дүртенче иргә чыгам инде, уңып булмый», – ди. Шунда әйттем: «Ә мин менә гомерем буе бер хатын белән яшим».

Хатыным, Рәйсә ханым, һөнәре буенча бухгалтер. Тәртип, дисциплина ярата торган, булдыклы кеше. Мәскәү кызы. 53 ел бергә гомер итәбез. Ике кыз үстердек. Тормышта үз юлларын таптылар. Өлкәне – Руфинә – башта, әнисе кебек, экономист белгечлеге алды. Артист булырга хыялланган икән, миңа сиздермәде. Яңадан Мәскәүдә ГИТИС бетерде, хәзер Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында укыта. Ул – минем зур тәнкыйтьчем, һәр нәрсәгә үз карашы бар, шул исәптән минем рольләргә, спектакльләргә дә. Кече кызыбыз Айсылу һөнәре буенча



Тормыш иптәше Рәйсә ханым белән



Щепкинчылар

– 53 ел элек апам белән Мәскәүдә Колонналар залына Илһам Шакиров концертына бардык. Очраклы гына. Карыйм: безнең рәттә ыспай кәчтүм-чалбардан 4 чибәр егет тезелеп утыра. Беренче күрүгә Ринатны ошаттым. Ул да минем якка караштыргалый. Соңынынан Наил Дунаев белән безне озата кайттылар.

Ринат – авыл малае бит ул, әллә ни «ухаживать» итә белми иде. Беренче свиданиебезгә ландышлар алып килде, кесәсенә яшергән булган үзе чәчәкләрне. Әмма зур ихтирам белән карый иде ул миңа. Җилбәзәк түгел. Танышуга, укытучысы Михаил Гладков белән күрешергә алып барды. Соңыннан, өйләнешкәч, әйтте: «Әйбәт кыз, өйлән, аның белән тормышта югалмассың», – дигән остазы. Бер айдан Казанга эшкә кайтып китте. Хатлар язышабыз. Тәкъдим ясады. Бер генә минутка да икеләнмәдем: кем икәнлеген дә, кем булачагын да баштан ук белә идем.

Уникаль кеше Ринат. Тормышта да төпле ир, әйбәт дус булды. Хәзер оныкларына – менә дигән бабай, – дип сөйли Рәйсә ханым ире турында.

Фотолар Р. Таҗетдинов архивыннан

геолог, шулай ук институтта укыта. Оныклар бәхетен күрү насыйп булды. Бер оныгыбызны югалттык, ул зур кайгыны да бергәләп кичердек. Рәйсә ханым балаларны кеше хакын хаклый торган итеп тәрбияләде. «Әтиегез йөзенә кызыллык китермәгез!» дип үстерде.

Руфинәгә исемне үзем куштым. Руфина Нифонтова дигән искиткеч чибәр актриса бар иде, шуның хөрмәтенә. Айсылу Мәскәүдә туды, ул туган көнне без Мәскәүдә «Миркәй белән Айсылу»ны уйнадык. «Кызым туды!» – дип сөенеп йөрим, театрдагылар: «Исеме Айсылу була инде, болай булгач!» – диделәр.

Мин, руслар әйтмешли, «однолюб». Без бит, артист халкы, икешәр-өчәр ай гастрольләрдә йөрибез. Рәйсә ханым ул яктан да мине аңлап яшәде. Көн аралаш диярлек хат алыша идек. Олыгайган саен күбрәк аңлыйсың гаилә кадерен. Картая башлагач, кеше гомумән бик сирәк, иң кадерле кешеләренә генә кирәк була башлый.



Актриса Нәҗибә Ихсанова белән «Көзге ачы җилләрдә» спектаклендә

АБЫЙ, МИН БОЛАЙ ГЫНА...

Гомерем буе партнершалардан уңдым: искиткеч чибәр, әйдәп баручы актрисалар белән уйнарга насыйп булды: Наилә Гәрәева, Алсу Гайнуллина... Яши генә башлаган чакларда хезмәттәшләре әйтә икән: «Менә, Ринатны телевизордан күрдек әле, бик каты кочаклашып тора иде анда». Рәйсә ханым: «Әйе, мин дә карадым, бик үк каты кочакламады шул, ул әйбәтрәк тә кочаклый ала», – дип көлгән дә, үзе барыбер кәефсезләнгән. Әмма Рәйсә ханымга көнләшерлек сәбәп булмады, үзе дә көнләшеп яшәмәде.

Мавыгулар, гашыйклыклар булмый калмый инде кешедә. Матур

актрисаларга, ханымнарга сокланмасам, агач бүкәне булыр идем. Әмма адәм баласының аңында сорау кабынырга тиеш: тукта, матур, тигез тормышымны җимереп, кайдадыр бәхетлерәк була алырмынмы? Чик булырга тиеш иҗади соклану белән тормыш чынбарлыгы арасында.

Шундый очрак булды. «Гүзәлем Әсәл»нең дөньяны шаулаткан вакыты. Һәр кич спектакльдән чыгам, артымнан бер кыз бала ияреп кайта. 10–15 адым ераклыкта. Ул чакта Жданов урамында яши идек. Бер кайта, ике. Якын да килми үзе, әмма өйгә кадәр ияреп кайта. Берсендә борылдым да: «Сеңлем, син ник болай йөрисең?» – дим. Югалып калды: «Абый, мин болай гына бит», – ди. Шунда әйттем: «Минем хатыным, балам бар, син болай йөрмә, үз тиңеңне тап та бәхетле бул».

Ул яктан безнең театрда тәртип. Яшь буында да шулай. Моңа бик сөенәм. Юкса рус театрларында ни генә эшләп бетмиләр – берсе аера хатынын, икенчесе аңа өйләнә, кабат алмашалар… Безнең тәрбиягә бөтенләй ят нәрсә.



МИН – МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВ АРТИСТЫ

1966 елда театрга Марсель Хәкимович кайтып төште. Һәр режиссёрның аеруча яхшы тоя торган актёрлары була. Ул аларның потенциалын максималь рәвештә эшкә җигә. Минем өчен шундый режиссёр Сәлимҗанов булды, үземне, курыкмыйча, аның артисты дип атыйм. Бик уңайлы булды аның белән эшләү. Әлбәттә, диктатор режиссёр иде, барысы да аныңча гына булырга тиеш. Әмма нәрсәне тотып алырга кирәклеген анык күрсәтә белде.

Аннан театрга Фәрит килде. Аның системасына ияләшү бик авыр булды. Миңа гына түгел, гомумән безнең буын артистларына. Аның үз буыны, тәрбияләгән артистлары бар – И.Хәйруллин, Р.Вәҗиев, Р.Бариев һ.б. Фәрит Рәфкатович – бөтенләй башка режиссёр. Нечкәрәк, интуитиврак, интеллектуальрәк…. «Менә болай эшлисең» дигән анык картина бирми ул, ә актёр белән бергә уйлый, шикләнә, гасабилана. Тора-бара аның логикасын аңладым: рольнең, спектакльнең нинди булырга тиешлеген баштаук кистереп әйтмәсә дә, эчке тоемы белән яхшы күзаллый, ахыр чиктә, төрле кыйпылчыклардан тулы бер ансамбль җыела. Бергә уйнаган коллегаларның сүзе, фикере дә бик мөһим. Без, буындашлар, бер-беребездән берни яшермибез. Ә яшьләр кискенрәк тә әйткәлиләр хәтта, чөнки алар инде дөньяны да, сәнгатьне дә бөтенләй башкача күрә.

«СИН ДӘ УЙНАМАДЫМ, ДИСӘҢ…»

Миңа «везунчик» диләр. Аның тамыры бит «возить» сүзеннән. Эшеңне җигелеп башкарасың икән, режиссёр моны күрә. Уңыш серемне әнә шул җигелеп эшләүдән күрәм. Режиссёрга бик читен: тулы бер труппа өчен җаваплы, андагы һәр актёрны эш белән тәэмин итәргә, тик утыртмаска тиеш. Читтән караганда, сизелмәгәндер, бәлки, әмма минем дә бик авыр чакларым булды театрда. Юк миңа ярардай рольләр, нишләтәсең… Киләм, уйныйм да кебек, әмма эчке канәгатьлек юк…

Шундый чорда Кол Гали роленең тәкъдим ителүе бик кадерле булды. Мусаны, Мирвәлиләрне яратып уйнадым заманында. «Моңлы бер җыр» бәхетле билетым кебек. Мине Мусага бик охшаган, диләр иде. Әминә ханым үзе дә әйтте. Мирвәли дә зур уңыш булды, катлаулы персонажларны уйнау актёрга яхшы сынау. Аның яхшы якларын табарга тырыштым. Станиславскийның кануны бар: нинди генә адәм актыгы булса да, яхшы ягын табарга кирәк, шул вакытта гына образны аңлап һәм башкаларга да аңлатып була.



Илгиз Зәйниев,
драматург, режиссёр

– Ринат абый – матур кеше, аның күңеле матур. Әйбәт кеше булып уйныйсы да юк, чөнки ул әйбәт кеше икәнлеген белә, үз эшендә профессионал кыяфәте чыгармый, чөнки ул үзенең профессионал икәнлеген белә. Тормышта да шулай – ул уйнамый, яши. Карт бүре булып килеп баса ул күз алдыма. Театр коридорларын ерып салмак кына атлаганда, сабыр, көчле рухлы токымнан булуын аңлыйсың. «Молодец!» дип аркаңнан кагып хуплаганда, бу бүредә физик көчнең дә сөбханалла булуына инанасың.

Камал театрында беренче куелган «Мәхәббәт турында сөйләшик» пьесамда Ринат абый уйнады. Аны сәхнәдән күзәткәндә, бу абзый һәрбер вакыйганы, фикерне генә түгел, һәрбер хәрефне дә аерым уйнап бирә аладыр, дигән уй килә башка. Шуңа икенче юлы язарга утыргач, җөмләләрне дә, хәрефләрне дә чамалабрак сайлыйсың һәм чиратлаштырасың. Саулык-сәламәтлек аңа!

«Кол Гали» заманы белән бик туры килде – илдә сәяси үзгәрешләр, милли күтәрелеш чоры. Бу фигураны мөмкин кадәр кешеләштереп, саграк итеп уйнарга тырыштым. Ул бит – халыкның яраткан әдибе, каһарманы. Нәкъ менә милли каһарманнар кирәк чор иде ул.

«Синең дә уйнамый калган ролең булса инде» диләр. Бар андый рольләр – Отелло, Ричард… Марсель Хәкимович Шекспирны куярга ничә тапкыр талпынып карады, тәки алынмады. Курыктымы шунда… Бездә журналистлар, театр тәнкыйтьчесе роленә керергә тырышып, язарга атлыгып тора: имеш, нигә чит телдән тәрҗемә итеп куясыз, ник классикага тотынасыз, татар театрында татар әсәрләре генә булсын. Тамырдан ялгыш фикер: классика театрда куелырга тиеш. Классика – театрның нәрсә булдыра алганын күрсәтүче өлге. Үзебезнең драматурглар өчен дә – планка. Классик әсәрләрне уйнау актёрларны да бер башка үстерә. Фәрит классикага мөрәҗәгать итеп бик дөрес эшли.

Менә Илгиз Зәйниев Шекспирга алынды, булдыра алганча башкарып та чыкты, молодец. Йөрәгең җитәргә кирәк бит! Аның Ричарды да, спектакльнең куелышы да бөтенләй мин күзаллаганча түгел, әмма «изюминкасы» бар. Мөгаен, шулай булырга тиеш тә – замана яшьләрнеке бит, режиссёр тәкъдим иткән вариантны тамашачы кабул итә икән, димәк, ул максатына ирешкән. Әмма миңа ул Ричардта тирәнлек, фаҗига җитми, аклау җитми башбаштаклыкларын. Мин уйнаган Ричард башка булыр иде, әмма миңа соң инде. Без хәзер, ни генә дисәң дә, «бывшийлар»…

АРТИСТ – СӘЯСӘТЧЕ ТҮГЕЛ

Ул – халык белән югары сәнгатьне тоташтыручы арадашчы. Аңа башка вазыйфа йөкләргә кирәкми. Әмма миңа үз гомеремдә озак еллар буе Театр әһелләре берлеген җитәкләргә туры килде. Бик авыр еллар иде. Акча юк, илдә бөтен нәрсәнең таралып яткан чагы. Милли республикалар азатлык яулаган еллар. Россия буйлап иҗат берлекләре таркала… Безгә әйтәләр: аерылып чыгыгыз Россия союзыннан, диләр. Юк, мин әйтәм, ярамый, театр үз эченә бикләнәчәк, аралашу, кан яңарту тукталачак. Әнә, молдован театры аерылды да, таркалды. Театрга фестивальләргә чыгу, декадаларга йөрү бик мөһим, үз-үзенә хозурланып, өендә бикләнеп ята алмый ул.

Тагын бер килешмәгән нәрсәм: репертуар театрын бетерергә кирәк, диюләре. Болай булса, халтура, үзешчәнлек башлана… Бездә, беләсез, республика театрлары күп, һәрберсе үз алдына куелган бурычны булдыра алганча башкара. Әмма хәлләре ал да гөл түгел, мең төрле кыенлык – акча мәсьәләсе булсынмы, бинамы, режиссёрларга кытлыкмы…

Үзем эшләгән елларда Театр әһелләре берлегенең Россия белән бәйләнешен һәм бинабызны саклап кала алдым, моның белән горурланам. Рус театрлары белән бәйланышларны да бозмадык, юкса милли хәрәкәт көчәйгән елларда үзара дуслыкка мөнәсәбәт шактый кискенләшеп алган иде. Миңа «Алтын битлек»не биргәндә, шушы эшчәнлегемне дә күздә тотканнар булса кирәк. «Театраль өлкәгә керткән өлешегез өчен» диелгән бит. Көтелмәгән бүләк булды… Фәрит, дөрес, әйткәләде: «Алтын битлек» алу мөмкинлегегез бар, Ринат Арифҗанович», – дип. «Кит әле, булмаганны», – дия идем. Тормышымда Россия мине ике тапкыр шаккатырды: РСФСРның Дәүләт премиясен биреп һәм менә – «Алтын битлек» белән. Бу театрыбызның җиңүе дә: димәк, аңа җитди карыйлар, димәк, Россиядә аның дәрәҗәсе югары.

БЛИЦ

ИҢ КӨЧЛЕ СЫЙФАТЫГЫЗ?
Кеше хакын хакларга тырышам, тик гел үз файдама булып чыкмый.

ИҢ ЙОМШАК ЯГЫГЫЗ?
Кырт кистереп, каты итеп әйтә белмим.

ИҢ ЗУР ЯЛГЫШЫГЫЗ?
Бик зур ялгышым бардыр, дип санамыйм. Дөрес яшәдем шикелле.

ИҢ ЗУР УҢЫШЫГЫЗ:
Татар театр дөньясына керткән өлешем.

ИҢ ЗУР ҖИҢҮЕГЕЗ?
Гаиләмне таркатмау.

ИҢ ЗУР КУРКУЫГЫЗ?
Балалар начар юлга басмасын, үзем бу тормышта инде бөтен нәрсәгә дә әзер.

ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛЕГЕЗ?
Барлык туганнарның гаиләләре белән җыелган мизгелләр. Театрда – эшемне җиренә җиткереп башкарганда.

ИҢ ИХТИРАМ ИТКӘН ШӘХЕСЕГЕЗ?
Минтимер Шәймиев. Ул безнең халык өчен бик күпне эшләде.

ТОРМЫШ КАНУНЫГЫЗ?
Мин бик ышанучан кеше. Аллаһка да, кеше бәхетенә дә ышанам. Ә тормыш мең хәйләле. Менә шул тормыш чатырманын сайлаган юлыма, иманыма тугры калып, бер үк вакытта тирәмдәге кешеләрне дә рәнҗетмичә үтә алу.


P.S. Язма әзерләнеп беткәч, Ринат абый: «Мин артык идеаль килеп чыгам бугай», – дип бераз пошынып алды. Мин исә – тормышымда тагын бер ихтирам итәрдәй кеше барлыкка килүенә сөендем.

ЗАТЛЫЛАРДАН ЗАТЛЫ – *КАЗ*



Автор:
Айсылу Хаҗиева

Безнең халык заманында рецептларны Интернеттан эзләп утырмаган. Интернет булмагач, эзләмәгән инде, дияргә ашыкмагыз. Хикмәт анда гына түгел. Хикмәт бу рецептларның үтә кадерле булуында. Әбиләрдән – әниләргә, әнисеннән кызына күчеп килгән ризык әзерләү серләре. Ягы-ягы белән, хәтта ки урамы, йорты, нәселе белән аерылып торган алар бер-берсеннән. Бүген без каз әзерләү серләренә төшенербез.



Фотолар: Ната Смирнова

Илсөя Зәкиҗанова рецепты:

Казны пешерү өчен:



Казны пешерү өчен:

- 10 литр җылымса су
- 700 гр тоз
- 2 тырнак сарымсак
- 6 дәфнә (лавр) яфрагы
- кипкән шөет (укроп) орлыклары
- 10-15 бөртек кара борыч

Чиләккә 10 литр җылымса су салырга, анда 700 гр тозны эретергә, шуңа сарымсак, дәфнә яфрагы, кара борыч, шөет орлыгы өстәргә. Шушы суга казны салырга, чиләкнең өстен капларга. Каз тулысынча суга күмелергә тиеш. Бүлмә температурасында 1 тәүлек тотарга. Болай эшләүнең өстенлекле ягы шул: каз тулысынча тәмләткечләрне һәм тозны үзенә сеңдерә.

Икенче көнне казны судан алып, салфетка белән корытабыз. Аджика һәм майонезны кушып, казның эчен-тышын сылыйбыз. Алманың үзәген алып, 4 өлешкә бүләбез. Караҗимешне юабыз, төшен алабыз. Аннары алманы караҗимеш белән катнаштырып, каз эченә тутырабыз. Казның ярылган җирен тегәбез һәм пешерү өчен махсус пакетка тыгабыз. Пакетның өстен энә белән берничә җирдән тишеп, духовкага 2 сәгатькә куябыз. Духовканы алдан җылытып кую зарур. Пешерү өчен оптималь температура – 180 градус. Каз пешкәннән соң, аның суынганын көтәргә кирәк. Телемләп турап, алма һәм караҗимеш белән бизәп табынга чыгаралар.



АВЫЛ КҮРКЕ, МӘҖЛЕС КҮРКЕ

Казлар – борын-борыннан авылның күрке булып саналган. Төрле төстәге буяулар сөртелгән казлар әллә кайдан күзгә ташланып тора иде без үскәндә. «Болары Сәхипҗамалларныкы, болары Зарифларныкы» дип, канатларына сөртелгән төсләреннән шунда ук аерып аласың. Көз җиттеме, авылларда каз өмәләре башлана. Бу – үзе бер матур йола. Өйдән-өйгә йөреп каз йолкулар, шул чакта җырлаган җырлар, бер-береңә сөйләнгән рецептлар. Яңа ел өстәленең дә бик матур бизәге ул казлар: каклаганы, дисеңме, тутырылганымы…

«Каз әзерләү йоласы» дип Интернеттан эзләп интекмәгез, юк андый мәгълүмат. Виртуаль дөньяда яшәүчеләрнең берсе дә каз пешерү йоласы татарларга карый, дип уйламыймы соң? Үзебезнекеләр дә әллә ни танытырга теләмиме? Ә менә азәрбайҗаннарның долмаларын, үзбәкләрнең пылауларын безгә язганнар да куйганнар.

Татарлар казны борын-борыннан әзерләгән. Ул моннан йөз ел элек тә, хәзер дә иң затлы ризыкларның берсе санала. Никахларга, туйларга кияү-кәләшнең якын туганнары бүләккә, күчтәнәчкә каз алып килә. Бәби чәйләре, Коръән ашлары, хәтта ки туганнарны кунак итү дә пешерелгән казсыз үтми.

ЭКОНОМ-КЛАСС ҺӘМ БИЗНЕС-КЛАСС

Элек ярлы татар кешесендә бәйрәм ризыгы булып тутырылган каз түгел, ә тавык саналган. Ә инде бай, хәленнән килә торган татарлар бәйрәмгә нәкъ менә каз пешергәннәр. Тутырылган казны да, тавыкны да бары тик олы бәйрәмнәргә генә әзерләгәннәр: никах мәҗлесләре, туйлар.

Туйга казны тәмле итеп пешереп, матур итеп бизәп бары тик кәләшнең әти-әнисе генә алып килгән. Һәм туй көнендә түгел, ә икенче көнне. Беренче көнне гөрләтеп туй үткәргәннән соң, яшь килен шунда ук кайнана-кайнаталары өендә яшәп кала торган булган. Ә икенче көнне зурлап килен чәе уздырылган. Килен чәе дә туйдан ким булмаган. Шундый ук мул табын, сый-нигъмәтләрдән сыгылып торган өстәлләр. Килен чәенә, билгеле, кызның әти-әнисен, аның якын туганнарын да чакырганнар. Һәм менә алар каз пешереп алып килгәннәр дә инде.

Ә казны нәрсә белән тутырырга икәнен һәр хуҗабикә үзе хәл иткән. Чөнки, без инде ияләшкәнчә, бар эконом-класс һәм бар бизнес-класс. Иң элек казны бәрәңге белән тутырырга була, аннан кала дөге һәм бодай ярмасы белән дә пешерәләр, ә инде иң затлысы булып, аңлашыла ки, алма, караҗимеш белән тутырылган каз санала. Юныс Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары» китабында шушы 3 төрле ризыкның да рецепты бар. Ләкин без бу казларның берсен генә пешерербез. Моның өчен Теләче районының Олы Нырсы авылына юл тоттык…

ҮЧТИ, ҮЧТИ, ҮС, КАЗЫМ!

Ара ерак булмаса да, казны пешерү шактый вакыт таләп итә, дип, иртәнге тугызда ук юлга кузгалдык. Олы Нырсы авылында безне Зәкиҗановлар гаиләсе каршы алды. Гаилә башлыгы Рушан абый, тормыш иптәше Илсөя апа һәм ак яулыклы мөлаем Сания әби. Каз мәсьәләсендә бу йортта вазыйфалар төгәл бүленгән. Рушан абый кошларны ризык белән тәэмин итеп торса, Сания әби карап үстерә, ә Илсөя ханым теленңне йотарлык итеп пешерә.

Каз асрау, үрчетү, ашату – керемле эшме? Бу сорау белән Сания әбигә мөрәҗәгать иттем. Аның сүзләренә караганда, ишле гаилә казсыз яши алмый. Беренчедән, туганнар еш җыела, ә инде якыннарны каз белән сыйлау гадәте канга сеңгән. Икенчедән, авылда кош-корт асрау үзе күңелгә рәхәтлек бирә торган эш. Ашатуга килгәндә, баштарак сохарилар җебетеп, шуңа кычыткан кушып казларга бирәләр. Соңрак комбикорма ашатуга күчәләр, шунысы да мөһим – әзер ашамлыкка балык мае кушу. Ул кошларның сау-сәламәт булып үсүенә зур йогынты ясый. Ә инде казлар үсеп җиткәндә аларны пешкән бәрәңге белән сыйлыйлар.

Шунысын да онытырга ярамый: казны ерткычлардан саклап үстерүе бик авыр. Бу елны, мәсәлән, котырган төлкеләр күп булды, ди Зәкиҗановлар. Әңгәмәгә Илсөя ханым кушылды. Бер дистә ел элек хуҗалыктагы 34 казның 9ын этләр харап иткән булган. Ә халыкта «казларны эт тотса, димәк башка казларның игелеген күреп булмаячак» дигән ышану яши икән. Шуннан Сания әби дә, Илсөя ханым да каз асраудан баш тартканнар. Ләкин алай да күңелгә якын авазларны кабат ишетәсе, тәмле кош ите белән якыннарны сыйлыйсы килү теләге өстен чыккан. Моннан 5 ел элек алар бу авыр, ләкин мактаулы эшне яңартып җибәрәләр.

ЧИШМӘ СУЫН ЭЧЕП ҮСКӘН, ЧИШМӘЛӘРДӘ ЮЫЛГАН…

Казларны ноябрь-декабрь айларында өмә җыеп суялар. Өмә вакытында Зәкиҗановлар йорты гөрли, чөнки бар хатын-кыз туганнар кайтып булыша. Бүгенге көндә һәр өйгә уты да, суы да кергән булуга карамастан, йолкынган каз түшкәләрен күрше Айдар авылы чишмәсенә барып юу гадәтеннән баш тартмаганнар. «Чишмә суында юылган казлар чистарак та, аларның ите дә тәмлерәк була», – дип өстәп куйды Сания әби. Шул ук чишмә суын эчеп тә үскәннәр бит әле алар! Бу гаиләдә бер генә нәрсә дә әрәмгә китми: каз мамыгын, сүрүгә салып, автомат машинада юганнан соң, киптереп, мендәрләр хәстәрлиләр, каз каурыйларыннан – май канатлары, ә канатларыннан идән себеркесе дә ясыйлар.





Зәкиҗановлар гаиләсендә өмә бик күңелле тәмамлана. Алар икенче көнне каз ите белән бәлеш пешерәләр, мәҗлес вакытында шушы авыр эштә булышкан туган-тумачага, күрше-күләнгә рәхмәт тә әйтәләр. Сания әби кыз чакта казның эчәкләрен юып, эшкәртеп, вак итеп турап, алардан хәтта бөккәннәр дә пешерә торган булганнар. Илсөя ханым да әбинең сүзен җөпләде: «Арча якларында әнием казның эч-башларыннан бәлеш тә сала торган иде. Мин дә киләсе елга, Алла боерса, шулай пешереп карарга телим».

Акча мәсьәләсенә килгәндә, казларны үзең үстерү сатып алуга караганда күпкә арзанракка төшә икән. Бу елны 20 каз үстергәннәр, шуларның 8е инде ашалган, 2се какланган. Керем алыр өчен, ким дигәндә, 50 баш каз асрарга кирәк икән. Мисал эзләп тә аптырамады Рушан абый: күрше Субаш авылында яшәүче Пётр атлы абзыйны гына искә төшерде. Ул бу елны 350 каз үстергән, шуларның 70ен каклап та куйган. Сатылганнары да хәйран икән.

КАКЛАП БУЛА ТӨРЛЕЧӘ!

Каз каклау темасын кузгатканбыз икән, бу процессны да сөйләп китик, Илсөя ханым белән Сания әбинең сер капчыгын да чишик. Казны ике ысул белән каклыйлар.

1нче ысул. Каз өмәләре узуга, каз эченә күпме сыя, шулкадәрле тоз тутырып, аны кәгазьгә төреп, Сабан туена кадәр элеп куялар. **2нче ысул**. Каз өмәсеннән соң, каз эченә шулай ук сыйган кадәрле бодай белән катнаштырып тоз салалар. **Пропорцияләре:** 1х1. Соңрак, кәгазьгә төреп, казны элеп куялар. Ә инде март айларында казны алып, тышын су белән юып, теплицага кояшта кызарырга, какланырга чыгаралар. Ә хәзер сер! Бодай белән тозны кушып какланган казның бар өлешләре дә бер дәрәҗәдә тозга байый, шуңа ул артык тозлы да булмый.

Сүз иярә сүз чыга, диләр, безнең очракта да шулай булды. Сания әби чираттагы хатирәсе белән уртаклашырга ашыкты. Баксаң, әбинең яшь чагында казларны тутыру гадәте булмаган. Туйларга каклаган казларны пешереп алып килә торган булганнар. Каклаган казны иң элек суда юганнар, аннары, табага салып, мичтә кыздырганнар. Каздан бүленеп чыккан май белән кошны сылый-сылый, әйләндерә-әйләндерә пешергәннәр. Казлар кызарып, йомшак булып пешә торган булганнар. Ә хәзер инде аш бүлмәсенә юл тотыйк…

Илсөя ханым алма белән тутырылган каз рецептын моннан шактый еллар элек хезмәттәшеннән ишеткән булган, шуннан беренче тапкыр Яңа ел бәйрәменә пешереп караган. Без бүген сезгә Илсөя Зәкиҗанова рецептын тәкъдим итәбез (71 бит). Табыннарыгыз мул булсын!



Арча якларында казны тутырып пешерү гадәте юк. Казга тоз сөртеп, камырга төреп пешерәләр икән. Камыр өчен, әлбәттә, он, йомырка кирәк булачак.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР / ТАРИХ



КАЗАН ТАРИХЫНЫҢ КАРАҢГЫ УРЫННАРЫНДАГЫ **АК ТАПЛАР**

Казан һәм аның иске йортлары серләр томанына төренгән. Ул серләр күренекле кешеләр артыннан күләгә булып ияреп йөри, тарихи вакыйгалар өстендә болыттай эленеп тора. Тормышта була торган хәлләрнең барысы да беркетмәләргә, документларга теркәлми һәм архивариус тарафыннан киштәләргә пөхтәләп урнаштырылмый, шуңа да тарихта һәрвакыт караңгы таплар кала – шулар нигезендә мул яңгырдан соң калыккан гөмбәләр кебек мифлар һәм уйдырмалар үсеп чыга. Бүген без шундый берничә тапка тукталырга уйладык. Аларның дөреслеккә туры килү-килмәвенә ышану – сезнең иркегездә.
Хәер, безгә алдашу нәрсәгә инде...



Автор:
Гадел Хәеров

БЕРЕНЧЕ ТАРИХ. «АЛТЫН» ЧЫРШЫ

Язучы һәм журналист Рафаэль Мостафинны күпләр Кабан күле төбендәге хан казнасы турындагы язмалары аша хәтерли. Ләкин бу аны кызыксындырган темаларның берсе генә иде. Казан ядкарьләре турында күп белә иде ул. Мәгълүматны архив һәм китапханәләрдә туплый, җирле туган якны өйрәнүчеләр һәм аксакаллардан сораштыра.

Бервакыт ул миңа Әмәт бистәсендә яшәүче Нәбиулла абый белән очрашуы турында сөйләгән иде. Нәбиулла абый әйтүенчә, 1921 елның кышы карлы килгән. Шулай бервакыт ул әтисе белән урманга утынга барган. Бистә халкы Әмәт урманына кагылмаска тырышкан, шәһәр читендәге корыган агачларны кисә торган булган. Әмәт урманы бүген дә метро станциясеннән башлап, тимер юл буйлап Гадел Кутуй урамындагы тулай торакларга кадәр сузыла. Нәбиулла абыйларга бу юлы якындарак утырган агачны сайларга туры килгән. Карт чыршы булган ул, алтын яшьләргә күмелеп утырган. Агачны аударганнар, кисәкләп тураганнар. Шуннан соң, метр ярымлы бүрәнәләрне чанага төяп, өйгә алып кайтканнар. Икенче көнне ишегалдына кәҗәләр куеп кисә башлаганнар. Кинәт кенә, дип сөйли карт, ике яклы пычкы зеңләп куйган, һәм карга куе сары төстәге пычкы чүбе коелган. Әтисе бүрәнәне балта белән яргалый башлаган, эченнән көтмәгәндә аяк астына авыр алтын коелмасы килеп төшкән.



Күрәсең, кемдер аны кеше буе биеклегендәге агач куышына яшергән, һәм берничә ел эчендә алтын кәүсәгә берегергә өлгергән. Берничә көн алар ялтыравык кисәккә карап соклanганнар. Буран тынгач, әтисе алтынны, гәзиткә төреп, милиция участогына илтеп биргән. Кайда анда рәхмәт сүзе ишетү, киресенчә, табылдыкны ник Ленин портреты төшерелгән гәзиткә төрдең, дип бәйләнгәннәр. Тапкыр татар абзые югалып калмаган: «Тозлы балык түгел, алтын төрдем бит!» – дип котылган. Тегеләре, моны ишеткәч, авызларын япканнар. Әлбәттә, бу хәлдән соң Әмәт урманын башта ЧК отрядлары, аннан соң җирле хәзинә эзләүчеләр тарап чыккан. Ләкин шуннан артык бернәрсә дә тапмаганнар.


Рафаэль Әхмәтович фикеренчә, әлеге алтын коелмасы турыдан-туры Россия империясенең алтын запасыннан була. Мәскәүне большевиклар алганнан соң, аны ашыгыч рәвештә Казанга эвакуацияләгәннәр һәм Проломная урамындагы (хәзерге Бауман) Милли банкның саклагычына урнаштырганнар. Бу тарих һәммәбезгә дә мәгълүм, матбугатта да тәфсилләп яктыртылган, шулай да аның караңгы таплары бар әле.

Кызыллар Казанга якынлашканда, генерал Каппель алтынны пассажир пароходларына төяп, Самарага илтергә боера. Бу эш бик ашыгыч эшләнә. Алтын тәңкәләрне урлап бетерәләр. Ничек кирәк алай итеп калган алтынны алып китәләр, тик банкка кереп карасалар, аның бер бүлегендә берәр килограмм авырлыктагы 216 коелма «онытылып» калган булуы ачыклана. Боларын да су юлы аша Кызыл армия һөҗүменнән ераккарак – Лаеш ягына таба озаталар. Алга таба исә алтыннар серле рәвештә юкка чыга. Бу хәлләр Сокуры һәм Никольское авыллары тирәсендә булган, дигән имеш-мимешләр генә ишетелгәли.

Юкка чыккан алтын олавында, исегезгә төшерәбез, 216 алтын кисәк булган. Мостафин версиясе буенча, алтын шәһәрдән чыкмаган да. Казаннан чыгып барганда, аны кызылармиячеләрнең атлы кешеләре куып тота, бәрелеш була. Олау өчен җаваплы булган полковник Протасов утырган арбага чолганыштан чыгып качу мөмкинлеге тәти. Кызылларның койрыкта утыруын аңлаган хәлдә полковник алтынны кая туры килә, шунда качыра башлый. Әмәтлеләр элек-электән хуҗалык өчен кирәк-яракка балчыкны тау битеннән ала торган булалар, һәм ул урыннарда күпсанлы чокырлар уелып, алар яз көне ишелә башлый. Алтыннарны яшереп куяр өчен шуннан да яхшырак урын табылмас та иде. Әрҗәләрнең берсе пулялар белән титкәләнгән, күрәсең, ул кулда килеш таралып төшә. Алтын коелмаларын чокырга ыргытып, полковник аларны ашык-пошык кына каплаштыра да арбага таба йөгерә – шунда ул үлән арасында төшеп калган «алтын кирпеч»не күреп ала. Агач куышына шуны яшерә дә инде ул. Протасовны шуннан соң ни үле килеш, ни тере килеш берәүнең дә күргәне булмый. Казна серен дә ул үзе белән алып китә – йә эмиграциягә, йә булмаса, алтын балчыктан да кыйммәт булмаган җиргә.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР / ТАРИХ

ИКЕНЧЕ ТАРИХ. МАКАКАЛАР БАСТЫ!



Казан шагыйре Саша Корольков тумышы белән Спас районының Полянки авылыннан. Кара көздә шәһәргә килеп, тулай торактан бүлмә дә бирә торган эшкә урнаша ул. Яз көне эштән китә дә Полянкига әйләнеп кайта. Үзе әйтмешли: «Туган нигезгә!» Бер тапкыр минем дә аңа кунакка кайтканым булды – балыкка. «Нигез» дигәне бабасыннан калган өч тәрәзәсе дә кадакланган өй икән. Һәм мондый хәрабәләр монда кыеклап сузылган бер урам тулы. Мине җирле кешеләрнең сөйләмендәге атамалар гаҗәпләндергән иде: «Бай урманына барабызмы?.. Бай күленә... Бай тавына...» Сәер!

Көз җитүгә, Корольков Казанга килә һәм миңа бабасының калын гына амбар кенәгәсен күрсәтә – ул аны чоланда чүп-чар арасыннан табып алган. Бабай ниндидер хуҗалык хисаплары алып барган, сәер-сәер язулар төртеп куйган: «17 декабря. Угрим исчо пуд соли взял. Вернуть обещалси хвостами». Һәм кинәт кенә, көтмәгәндә, шагыйрьнең бабасы маймыл сурәтләре төшерә башлаган. Менә берсе качып кына тәрәзәдән карый, икенчесе тәрәзә төбеннән төнәтмә шешәсен алып төшеп бара, өченчесе кәҗә имчәгенә ябышкан да ләззәтләнеп имә. Яисә маймыллар көтүләре белән түбә буйлап сикерешеп йөри, менә тагын ике гашыйк маймыл көймәдә йөзә, ә менә монда көтү башлыгы артын күрсәтә...

Кышкы озын кичләрдә рус авылында күзгә ни генә күренмәс, дип уйлыйм инде үземчә! Әлбәттә, керпеләр яки су кызлары күренсә, мантыйкка ярашлырак булыр иде. Ләкин маймыллар күренсен өчен Угрим белән күпме эчәргә кирәк булды икән?!

Соңрак шул мәгълүм булды: Полянкида кайчандыр археолог һәм нумизмат Андрей Федорович Лихачевның биләмәсе булган икән. Аның коллекциясе ТР Милли музеена нигез салган. Инкыйлабтан соң бай йортын җирле мужиклар ут төртеп яндыра. Озакламый минем кулга алпавыт оясын тузгытуның нәтиҗәләрен тасвирлаган кызыклы документ килеп эләкте:

– ихатадан байның зур көзгесен алып чыктылар. Ишек тәбәнәк булу сәбәпле, аны мужик яши торган өйгә кертеп булмады, шуңа күрә көзгене чүкеч белән ваттылар да ватыкларны бүлешеп алып бетерделәр;

– рояльне ишегалдына куйдылар һәм аны туйлар, искә алу кичәләре, армиягә озату җыеннары уздыру өчен өстәл буларак куллана башладылар;

– колхозда бай җигеп йөри торган арба рессорларында тирес түгә башладылар;

– Лихачёвлар ихатасында оранжерея белән зоопарк бар иде. Талау-тузгыту вакытында җәнлекләр качышып бетте, һәм әле бик озак вакыт дәвамында маймыллар түбәләрдән чабышып йөрде, бакчаларга төште, чебешләрне һәм мәче балаларын урлый, хатын-кызларга елга ярында кер чайкарга комачаулыйлар. Керләрне урлыйлар да агач башларына биеккә алып менеп эләләр. Кышларын бозаулар белән бергә абзарда йоклыйлар. Җирле халык алардан шайтаннан курыккан кебек курка.

Менә бит хикмәт нидә булган икән! Саша Корольковның бабасының күзләренә күренә башлаганмы әллә дип торам. Юк, чын маймыллар булган икән. Җитмәсә, берәү генә дә түгел!

ӨЧЕНЧЕ ТАРИХ. ПУШКИН ҺӘМ БОРЧА

1833 елда Пушкин Казанга килә. Монысы һәркемгә мәгълүм. Килгән, күргән, тыңлаган, халык белән очрашкан, трактирда ашаган, дусларына кунакка йөргән. Китәр алдыннан аны табиб һәм туган якны өйрәнүче Карл Фукс һәм аның хатыны шагыйрә Александра Андреевна Апехтина кичке ашка чакыралар. Шагыйрәнең дус кызына язган хаты аша безгә ул кич турында кайбер мәгълүматлар билгеле – өстәлгә нинди ризыклар куелган, хуҗабикә бу кичтә нәрсәләр укыган, шагыйрь аны нинди сүзләр белән мактаган һ.б.



Александра Андреевнаның 12 битлек озын хаты ахырында Пушкинны өйрәнүчеләр бу документны үзләренең текстларында кулланганда гадәттә төшереп калдыра торган бер җөмлә бар: «Ә инде, сөекле дустым, мин ахыргы өлешкә җиткәндә, нәкъ шушы урында Александр Сергеевич шундый итеп сикереп куйды, хәтта өстәлдәге шәмнәр дә сикерешкән кебек булды. Мин аны шигырьләрем белән тәэсирләндердемме әллә, дип тә уйлап куйдым. Ләкин, ни кызганыч... моңа борча гаепле иде!»

Бу турыда миңа Казан рәссамы һәм борынгы әйберләр җыючы Алексей Кубарев сөйләде. Сөйләгән мәлендә ул Вольтер кәнәфиендә утырып тора иде, имештер, кәнәфи дә Фукс йортыннан. Үзеннән үзе аңлашыла ки, «шигърият кояшыбызның» бер җиреннән тешләгән теге бөҗәк нәкъ шушы кәнәфи пружиналарында яшәгән, дип гоманларга кала. Борчаны Пушкин эләктерә һәм тырнагы белән сытарга да тели, ләкин Александра Андреевна әлеге бәхетсез җан иясен җәзаламавын үтенә һәм аны бәллүр капкачлы алтын медальонына салып куя. Мери дип исем дә бирә хәтта. Ул аны ядкарь итеп саклый, соңрак бөтенесенә дә бөек рус шагыйренең кан тамчысы сакланган, дип кабатлый-кабатлый күрсәтә торган була. Хуҗабикә өчен борча гына түгел, ә Грааль касәсенә тиң була ул!

ДҮРТЕНЧЕ ТАРИХ. АЖДАҺА БЕЛӘН ӘТӘЧ ГИБРИДЫ

Казан университеты студенты чагымда җәйге практиканы Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә үткән идем. Ул вакытта аны Вячеслав Аристов җитәкләде. Ул ерактан начар күрә һәм калын пыялалы күзлек киеп йөри. Библиофил беркайчан да үзенең зур фолиантларыннан аерылмыйдыр һәм, лимонлы чәй эчә-эчә, көне-төне дәфтәренә нидер яза-яза, китап актарадыр кебек тоела иде. Ничектер шулай су баскач, идән астыннан китаплар ташырга туры килде. Хезмәткәрләр аларны фен белән киптерә бара. Мин сафьян тышлы борынгы альбомны күтәреп бара идем, Вячеслав Васильевич, нәрсә тотып барганымны күреп, мине җиңемнән эләктереп алды. Шатлыгыннан кояш булып балкый үзе:



– Бәй, бу бит Юрген Такойтович! Күптән эзлим! Бөтен дөньяны актарып чыктым! – диде ул.

Ул китапны махсус китап куйгычка урнаштырды да сурәтләрне каплаган пергаментны чәнти бармагының озын тырнагы (чын һөнәри корал!) белән әйләндерә-әйләндерә, актара, карый да башлады. Мин аның артында сүзсез генә тыңлап басып тордым.

– Мондагы китаплар тере кебек, минем белән качышлы уйныйлар. Каталогта кайсы киштәдә нинди китап саклануы турында барысы да язылган югыйсә. Барасың. Ә ул юк – качкан! Бусы да шулай... Ел буе качып йөрде, – дип елмайды Аристов һәм немец рәссамы, аның картиналары турында сөйли башлады. Мин аның исемен генә хәтерләп калдым – Юрген.

Юрген Казанга Голштин илчелеге составында килгән булган икән, илчелекне герцог Фридрих III Московия белән Фарсы иленә җибәргән. Бу вакыйга шуннан кайтканда була. 1637 елның декабре. Идел буйлап чаналарда баралар. Илчелек сәркатибе Адам Олеарий, бер үк вакытта тарихчы һәм сурәт төшерүче дә буларак, юлда языштырып бара, гайбадәтханәләр, кальгалар, йортлар һәм җирле халыкларны сурәткә төшерә, ә менә Юргенны бары тик үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы гына кызыксындыра. Татар авылларының берсендә ул җитлеккән күркә зурлыгындагы гадәти булмаган әтәч токымын төшереп ала, сурәт астына җирле халык бу кошны «җылан-әтәч» дип атый һәм аны Казан аждаһасы белән кыю әтәч мәхәббәтенең җимеше дип саный, дип язып куя. «Малай» алагаем зур, агрессив һәм бер бөртек каурыйсыз булып чыга. Каурый урынына – тәңкәләр. Шундыйларның ике данәсен герцогка бүләккә алып китәләр, ләкин тегеләре юлда сугышып, яшьрәге картын тотып ашый, озакламый үзе дә ялгызлыктан җан тәслим кыла.

Вячеслав Васильевич Казан университеты типографиясендә (ул вакытта принтерлар юк иде әле) Казан гибриды сурәтенең төсле күчермәсен алып, миңа Яңа ел бүләге итеп бирде.

БИШЕНЧЕ ТАРИХ. САФАГӘРӘЙ КАЯ ЙӨРГӘН?

Иң беренче ватерклозет Казанда губернатор йортында барлыкка килгән дип санала.

Аны урнаштыру өчен Парижның үзеннән үк сызымнар белән коралланган белгечләр чакыртылган, ди. Әйтүләренчә, баштарак губернатор бу бүлмәгә унитазга сокланыр һәм су белән юдыртуны карар өчен генә керә торган булган. «Нинди фонтан! Ничек челтери!» – дип шакката һәм йомышы белән урамга, гадәтләнгән будкасына йөгерә икән.

XIX гасырның урталарыннан башлап, сантехника яңалыклары Казан кибетләрендә дә барлыкка килә башлый. Гәзитләр рекламалар белән тула: «Comet моделе үзенең нәзакәтле формалары белән фаянс вазаны хәтерләтә. Йомшак утыргычы да бар»; «Сезгә хәтта Людовик XVI көнләшер иде, Кояш патша гадәти чүлмәккә йөргән бит!»

1882 елның декабрендә Александр Пассажында Германиядә эшләнгән ватерклозетлар күргәзмәсе үтә. Анда шул чорда модада саналган скульпторларның әсәрләрен карарга йөргән кебек килә торган булганнар. «Әлеге җайланмалар чын мәгънәсендә сәнгать әсәрләрен хәтерләтә», – дип яза «Казанские губернские ведомости» гәзите.

Казанлылар очрашканда һава торышы турында түгел, ә унитазлар турында сөйләшкән. Мәзәкләр өчен дә ул популяр тема булган. Туган якны өйрәнүче һәм филокартист Вадим Валошинның «Хатын-кыз һәм ватерклозет» сериясеннән көлкеле открыткалар коллекциясе бар. Казан губернаторы йортында барлыкка килгән беренче унитаз турындагы фикернең ялгыш булуы турында да миңа ул сөйләде.



– Төгәлрәк булыйк дисәк, – дип сөйләгән иде коллекционер, – иң беренчесе Казан ханы Сафагәрәй сараенда торган. Бу җәһәттән фарсы сәяхәтчесе Нурбәк хатирәләре бар. Ул борынгы Рим бәдрәфләре принцибына нигезләнеп, бераз гына камилләштереп урнаштырылган булган – салкын вакытта җылытыла торган итеп. Суны Казансудан су башнясына куелган резервуарга ташыганнар, аннан ул зур булмаган акведук буйлап башта бакчадагы фонтанга агып төшкән, аннан тишекле мәрмәр плитә астыннан агып киткән. Плитә аш бүлмәсендәге учактан җылынган. Димәк, бернәрсә дә уйлап табасы юк, барысы да безгә кадәр күптәннән табылган, чын мәгәр.

МИН ҮСЕП ҖИТКӘЧ

Альберт Гатин фотолары

Проектта урын алган 25 фоторәсем ТР БРКХндә дәвалана торган нәни пациентларның үсеп җиткәч табиб, спортчы, укытучы, төзүче булу турындагы матур хыяллары хакында сөйли.











Әлеге проектны, хыяллана белүнең һәм киләчәккә якты карашның нәни пациентларга ни рәвешле авырлыкларны җиңәргә һәм каты авырулары белән көрәшергә ярдәм итүен күрсәтү максатыннан, «Роналд Макдоналд Йорты» Фонды һәм фотограф Игорь Заломский уйлап тапкан.

Күргәзмә Казан Ратушасында 2016 елның 31 гыйнварына чаклы барачак. Билетлары – теләсә нинди ирекле иганә. Бөтен җыелган акчалар «Роналд Макдоналд Йорты»ның Казандагы бушлай хезмәт күрсәтүче иганәчелек кунакханәсен карап тотуга юнәлдереләчәк. (Тулырак мәгълүмат: vyrastu.ru сайтында).



СЕЗ КАЙСЫ ДӨНЬЯДА ЯШИСЕЗ?

Сезгә ничектер, минем өчен гыйнвар – тылсым, могҗизалар ае. Менә зарыгып көткән Яңа ел төне үтеп китте, һәм озын-озакка сузылган яллар башланды. Ул ялларда, гадәттә, телеканаллар бертуктаусыз хоббитлар, Гарри Поттер, Сойка-пересмешница маҗараларын, Нарния хроникаларын, Тәхетләр уенын, «Сумерки» сагасын, «Дозор»ларны «әйләндерә». TV программасын төзүчеләр безнең могҗизаларга ышануыбызга чын күңелдән ышана, миңа калса.



Автор:
Луиза Янсуар

Кыскасы, гыйнвар безне параллель дөньяларда яшәтүен дәвам итә. Сүз уңаеннан, алда санап үтелгән фильмнарның барысының да нигезендә әдәби әсәрләр ята. Фэнтези, фантастика, мистика, триллер... Жанр мәсьәләсе ул кадәр мөһим дә түгел. Бу әсәрләрдә иң мөһиме, миңа калса, каһарманнар. Гап-гади генә, гадәти тормышлары – маҗарага, ә үзләре геройга әйләнгән «кечкенә кешеләр». Өстәвенә, алар әле сайланган затлар («избранный») булып чыга. Ә кайсыбыз теләми тормыш бертөрлелегенең чынлап та фэнтезига әверелүен? Шкафтагы киемнәрне актарганда, кинәт кенә, уйламаган җирдән, Нарниягә эләгүне? Яшьлек җүләрлеге генә, дип уйласак, ялгышабыз, социологлар әйтүенчә, тылсымга, могҗизага үсмерләр, яшьләр түгел, хәтта олыгайган кешеләр дә түгел, ә нәкъ менә урта яшьләрдәге, тормыш йөген җигелеп тартып баручы ир-атлар белән хатын-кызлар күбрәк сусый. Ләкин без бит инде ул яшькә җиткәндә, тормышта кагылып-сугылып, циникка әверелгән булабыз. Шуңа 30-40-50 яшьләрдәге кемне дә булса ачыктан-ачык «могҗиза көтәм» дип сөйләндерү мөмкин эш микән?

Ә шулай да: ни өчен сусыйбыз соң без уйдырмага? Кырыс чынбарлыктан качу ысулымы бу? Ә, бәлки, киресенчә, безне канәгатьләндерми торган чынбарлыкны яңадан төзергә омтылудыр? Үзебез теләгәнчә гадел, дөрес, миһербанлы, идеаль итеп. Әмма... һәркемнең – үз дөреслеге бит. Ничек кенә булмасын, әсәрләрдәге уйдырма дөньяда һәрвакыт яхшылык җиңеп чыга. Бәлки, анда барысының да яхшы тәмамланачагын алдан белеп тору ымсындырадыр кешене?

Бу юлы китап киштәләремдә яшәгән уйдырма дөньяларга, параллель пространстволарга илтүче, алар аша мондагы чынбарлыкка яңарып, үзгәреп кайтырга мөмкинлек бирүче китап үрнәкләренә тукталырга булдым. Хәерле сәфәр безгә!

ХАРУКИ МУРАКАМИ. «ХРОНИКИ ЗАВОДНОЙ ПТИЦЫ»

Бу китапны укыганнан соң, сез спагеттины бөтенләй башка төрле пешерә башлаячаксыз. Монысы – бер. Россини музыкасына мөнәсәбәтегез үзгәрәчәк. Монысы – ике. Гел тирән, сусыз калган коелар турында уйлап йөри башлаячаксыз. Монысы – өч.

Мураками, беренче карашка, бик тормышчан, хәтта ки детальләр белән «шыплап тулган» язучы кебек. Әмма ул детальләр – күз буяр өчен генә. Үзе дә шулай ди: «Нәрсә генә яза башласам да, барыбер мистикага әверелә». Әмма аның мистикасы башка, ул махсус уйлап чыгарылган түгел, ә тормышның нинди җепләрдән үрелгән булуын капшап, хәтта ки ул җепләрне сүтеп, яңадан үреп карарга теләүдән туган табигый форма.

«Хроники Заводной Птицы» романын язгандагы халәтен болай сурәтли Мураками: «Миңа һәрчак Орфей һәм аның тәмугка сәфәре турындагы кыйсса ошый иде. Менә синең алдыңда – Үләләр Патшалыгы, һәм син, куркасыңмы-юкмы, анда барыбер керергә мәҗбүрсең. Тәвәккәлләргә. Мин, язучы буларак, тәвәккәлләүнең нәрсә икәнлеген беләм... Китапны башлаган гына чакта, берни уйламыйча, яздым да, яздым. Һәм көннәрдән бер көнне теге Караңгылык килде – шулчак мин анда «керергә» әзер булуымны аңладым. Әмма моның өчен бик озак әзерлек кирәк булды. Бүген яза башлап, иртәгә үк анда эләгә алуың шикле. Моның өчен вакыт һәм концентрация кирәк...»



Беренче карашка, бу юллар абсурд булып тоеладыр. Сүз нәрсә турында бара соң, диярсез. Сүз әсәрнең коридорлары, этажлары, бүлмәләре, лабиринтлары хакында. «Заводная Птица», Мураками́ның башка әсәрләре кебек үк, бер генә катламнан тормый. Ул гап-гади шәһәр йортында гап-гади бер ир-атның ашарга әзерләп торган мизгеленнән һәм телефон шалтыравыннан башланып китә. Озак та үтми,



югалган мәчесен эзләп чыккан әлеге дә баягы ир күршедәге ташландык сәер йортның ишегалдында торган серле кош сынына юлыга, аңа даими рәвештә сәер кешеләр шалтырата башлый, көннәрдән бер көнне сәер рәвештә хатыны юкка чыга, янына сугыш ветераны килеп, Кытайдагы япон оккупациясе һәм СССР белән сугыш вакытындагы шомлы, сәер хәлләрне сөйли, үткәннән серле хәбәр тапшыра... 1945 елдагы вакыйгалар, шулай итеп, бүгенге чынбарлыкка үтеп керә һәм үз чишелешен таләп итә башлый. «Все переплелось и запуталось, как в стереоскопической головоломке, где истина не обязательно факт, а факт не всегда есть истина», – диелә бу хакта романда.

Ахыр чиктә, гади генә героебыз «Заводная Птица» дигән кушамат ала һәм үзе аша узып йөргән тарихларны, язмышларны күзәтә башлый. Җыры белән һәр иртә дөнья пружинасын эшләтеп җибәргән кошчыкның үзенә турыдан-туры мөнәсәбәте барлыгын аңлый ул. Гомеренең яртысын диярлек яшәгәннән соң, кеше инде үзе теләп маҗаралар эзләми башлый, тормыш баткаклыгына бата да, ойый, мүкләнә, әмма, аның тормышы тамырдан үзгәрергә, ул үзен яңадан эзләп табарга тиеш икән, маҗаралар да аны үзләре эзләп таба. Шул хакта әйтергә теләмиме Мураками безгә бу романы белән?

ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВ. «АЛБАСТЫЛАР»

Татарда фэнтези, мистика бармы, дигән сорау актуальлеген югалтмый. Жанр турында бара бу очракта сүз. Безнең халык һәрнәрсәне төгәл классификацияләргә, димәк ки, тиешле сандыгына салып, тиешле киштәсенә менгереп утыртырга ярата. Менә фантастика белән хәлләр азмы-күпме ачыкланды шикелле, бар бездә фантастлар, бармак белән генә санарлык булсалар да – бар. Хәер, алар үз әсәрләрен фантастика жанры кысаларына кертеп карауны өнәмиме, әллә русча терминологияне үз итеп бетермиме, нигездә, хыялый кыйсса/хыялый бәян кебек атамалар белән билгеләүне кулайрак, ә бәлки, татарчарак күрәләрдер. Галимҗан Гыйльманов та «Албастылар»ын шулай классификацияләгән. Мин дә, вакланып, бәйләнеп утырырга кирәкми, дип саныйм. Әсәрнең үзенә күчәм...

Китапны инде кибет киштәләреннән табу мөмкин түгелдер, әмма аны, «Татар электрон китапханәсе» ресурсына кереп (http://kitap.net.ru/gyilmanov/albastylar1.php), онлайн рәвештә тулысы белән укый аласыз. Үз заманында бу әсәр татар әдәби мохитендә шактый шау-шу куптарган иде. Ул хәзер дә укучы өчен кызыклы булудан туктамагандыр, дип уйлыйм.

«Албастылар»ның үзәк каһарманы Хәлим «Заводная Птица»га шактый охшаган. Дөрес, Хәлим бераз схематик һәм әдәбирәк тоела миңа. Аның әсәр герое икәнлеге никтер һәрчак хәтердә тора. Шулай да «Албастылар» үзенең сюжеты белән дә, мифик-символик катламы белән дә, геройлары белән дә татар әдәбиятына яңалык алып килгән әсәр.

Кеше һәм адәм баласыннан өстен көчләрнең каршылыгы турында сүз бара романда. Бу очракта, сюжетның мифологик сылтамага ия булуын күздә тоткан хәлдә, Яхшылык белән Явызлык көрәше дип тә тәгаенләп булыр иде. Әсәрне укый башлауга, син, әйтерсең, бүгенге чынбарлыктан кубып, моңарчы әкиятләрдән генә ишетеп белгән, әби-бабайлар сөйләгән кыйссалар аша күңелеңә сеңдергән Параллельгә кереп чумасың.

Сюжет гап-гади башлана: мари урманы уртасыннан сузылган юл буйлап япа-ялгызы Хәлим район үзәгеннән туган авылы Кампәрлегә кайтып килә. Уйларына ирек биреп, армия хатирәләрен искә алып кайтып килгән егетнең юлына кинәт ике карчык килеп чыга – кап-карадан киенгәннәр, сәлам биреп, егетне ял итәргә өндиләр. Менә шул мари урманы эчендә чынбарлык белән төшне бутаган Хәлим берара уянып китә дә авылына кайтып төшә. Ә авылда аны әнисе Сания белән күрше карты Ак бабай сөенечтән шашардай булып каршылый. Бер ел буе көттек, инде исән түгелдер, дип уйлаган идек, диләр. Шулай итеп, Хәлим, йокыга китеп торган арада, бер ел гомерен югалткан булып чыга. Ә аннан егетебез, югалган хәтерен һәм шулай бер ел гомерен эзләп, кабат урманга – албасты карчыклар утарына чыгып китә. Анда ул сөйгәне Майяны кабат очрата, албасты карчыкларның ни өчен албастыга әйләнүен ачыклый, урман эчендәге дөньяның авылдагы чынбарлык белән тәңгәл, әмма асты-өскә әйләнгән күчермәсе булуына инана.

Кайсы дөньяны сайларга бу геройга? Дөресрәге, ничек бу ике дөньяны, берәүгә дә зыян салмыйча, килештерергә, берләштерергә? Адәм баласы үз эчендәге албастыны җиңми торып, тышкы дөньяны үзгәртә, тигезли алмый, диелә дини кануннарда да, психологиядә дә. «Албастылар» концепциясе буенча да – шулай. Асылда, бу бер Хәлим генә түгел, ә һәрберебез үз тормышында кичәргә тиешле инициация.

СЕРГЕЙ ЛУКЬЯНЕНКО. «ЧЕРНОВИК»

Лукьяненко әсәрендәге геройны, югарыда искә алганча, рус әдәбияты традицияләренә ишарә итеп, «кечкенә кеше» дип атарга да мөмкин булыр иде. Яшәгән ди булган ди Кирилл Максимов исемле гап-гади егет. Компьютер кибетендә эшләгән ул. Мәскәү шәһәрендә гап-гади генә бер бүлмәле фатирда япа-ялгызы яшәп яткан... Көннәрдән бер көнне Кирилл фатирына кайтып керсә, анда таныш булмаган бер хатын яшәп ята һәм фатир чынлап та бу хатынныкы булып чыга, җитмәсә, өй эче Кирилл күрми торган 8 сәгать эчендә тәмам үзгәргән. Әйтерсең, Кирилл монда чынлап та беркайчан яшәмәгән. Хәтта аның кесә телефоны да башка кеше исеменә теркәлгән – фатир хуҗасыныкына. Ә эте, ул әле маэмай вакытыннан алып үстергән яраткан эте... ул да Кириллны танымый, теге хуҗаныкы дип исәпли үзен... Ахыр чиктә, Кириллның кесә телефонына шалтыраталар да Мәскәү читендәге иске су башнясына килергә тәкъдим ясыйлар. Биредә аны карават, өстәл, урындыклар, хәтта аш-су да көтеп тора...

Бигрәк идеаль чишелеш, дияргә ашыкмыйк. Бу әле – башы гына... Мәскәүнең ташландык тыкрыкларының берсендә урнашкан башня асылда биш дөньяны тоташтырып торучы үзәк булып чыга. Дөньяларның калган дүртесе дә азмы-күпме Җиргә охшаган, әмма арада яшәр өчен бик читеннәре бар, кешегә анда исән-имин калу мөмкин түгел диярлек. Ә Кириллның соң вазыйфасы нәрсә? Ул биредә Таможеник Функционал булып эшли башлый. Ягъни дөньялар арасындагы ишекләрне саклый. Ә гадәти, без ияләшкән тормыштагы танышлары, аның барлыгын бөтенләй оныталар.

Һәм менә Кирилл тормышында маҗаралар башлана: ишекләр бер дә тик тормый, дөньялар арасында йөреп торучылар шактый күп булып чыга. Һәркемнең – үз максаты. Тора-бара Функционал үзе дә ул дөньяларга чыгып карый – Кирилл, Җирдән кала, һәр 4 дөньяда да үз функциясен үти торган урыннан 15 километрга китә ала, аннан ары ярамый, лимит беткән очракта Функционалның көче югала.

Акрынлап Кириллның юкка гына сайланмавы ачыклана, ягъни аның гади генә Таможеник, гади генә Функционал түгеллеге. Дөньялар белән ишекләр дә, аңлашыла инде, бишәү генә түгел. Менә көннәрдән бер көнне Кириллыбыз Россиядә соңгы тапкыр 1953 елда ачылган ишекне ача... Һәм Җиргә, функция буларак, хәвеф яный башлый... Алга таба вакыйгалар романның икенче өлеше – «Чистовик»та дәвам итә.

Спойлерламыйм, юкса дәвамын уку кызык булмаячак. Ә инде укыган кешеләр мине болай да аңлагандыр, дип уйлыйм. Романны укыганда, башка дөньяларны күз алдына китереп, әсәрдә сурәтләнмәгәннәре нинди булырга мөмкин, дип юрап утырдым. Без бит һәрчак, башка җан иясе рәвешендә булса да, үзебезгә тиңдәш образлар уйлап чыгарабыз. Әсәрләрдә, фильмнарда. Апокалипсистан соң да, барыбер дөнья кешенеке булып кала...

Ә менә, кешенең әсәре дә юк дөнья, ди. Кешегә ишарә дә юк дөнья. Андый чынбарлык безгә кызыклы булыр иде микән? Файдаланыр өчен – бәлки. Никадәр территория, өйрәнелмәгән җир бит! Бәлки, нефть запаслары да бардыр, алтын шахталары... Кем белә! Алары булмаса, галимнәр өйрәнәчәк: нәрсәсе белән файдалы була ала безгә бу яңа Атлантида...

Юк, кирәкмидер ишекләрне әзерлексез килеш ачу. Шуңа да Лукьяненко әйтә: бик сирәкләр генә белә Җирдә Функционаллар барлыгын. Хәзер инде – аның әсәреннән соң – билгеле, күбрәк кеше хәбәрдар. Әмма ул бит җүләр түгел, безне башняга юлласа да, мөгаен, эз яшерер өчен генәдер. Асылда Функционаллар бөтенләй башка урыннарда утырадыр. Бу урында ирониясез булдыра алмадым, гафу итәрсез.

СЬЮЗЕН КОЛЛИНЗ. «ГОЛОДНЫЕ ИГРЫ»



Трилогиянең составы: «Голодные игры» (2008), «И вспыхнет пламя» (2009) һәм «Сойка-пересмешница» (2010).

Америка язучысы Сьюзен Коллинзның дөньяны шаулаткан бу тарихын, фильм буларак экраннарга чыккач, дөнья буйлап ябырылып карадылар, әмма укучылар саны чагыштырмача барыбер сирәгрәк. Ә укып чыгу начар булмас иде, чөнки әсәр буларак та ул шактый мавыктыргыч һәм сыйфатлы. Мин үзем, күпләр кебек, башта фильмын карадым. Ошады, кызыклы тоелды, әмма әллә ни әһәмият бирмәдем. Ә менә фильмның икенчесен карагач, инде чын мәгънәсендә мавыктырды. «Бу тарих безнең бүгенге чор, вазгыять белән шулкадәр аваздаш», – дип, авыз ачып калдым. Һич кенә дә борынгы Рим гладиаторлары, урта гасыр, ягъни фашизм чәчәк аткан Европа тарихына сылтама түгел бу, ә үзебез яшәгән Бүгенгегә ишарә. Әле фильмның икенче өлеше чыкканда илдәге ситуация хәзерге кебек киеренке дә түгел иде, югыйсә, әмма Коллинзның месседжы минем тарафтан шулай «укылды».

Сүз уңаеннан, «Голодные игры»ның беренче томына керәш сүзендә Сьюзен Коллинз аның идеясе ничек барлыкка килү турында үзе дә яза. «Сюжетның башлангыч ноктасы, этәргече Тесей белән Минотавр турындагы борынгы миф булды, – ди ул. – Әлеге миф буенча афиналылар Крит утравына 7 кыз белән 7 егетне җибәреп, аларны Минотавр яши торган лабиринтка ыргыта торган булалар...» Икенче этәргеч буларак ул әтисенең хәрби карьерасын атый, Сьюзен аның белән сугышлар барган урыннарга йөри торган була. Кызыклы бер факт: Коллинзның уенда йөргән бу оеткы реаль әсәр буларак языла башлау өчен соңгы, төп катализатор... телевизор була. Сьюзен, пультка басып бер-бер артлы каналларны күчереп утырганда, кинәт мизгел эчендә реалити-шоудан Гыйракта барган сугыш турындагы репортажга күчә һәм шулай итеп ике картинаribbon бербөтенгә оеша: сугыш һәм реалити-шоу.

Әсәрдә хәлләр Апокалипсистан соңгы дөньяда – Панем дип исемләнгән мәмләкәттә бара. Глобаль фаҗигадән соң калкып чыккан Капитолий каласы (борынгы грек полисларының кайтавазы) тирә-яктагы 12 дистриктны кул астында тота. Дистриктлар, асылда, Капитолийның затлы тормышын тәэмин итүгә хезмәт итә. 74 ел элек 13нче дистрикт Капитолийга каршы гыйсъян күтәреп караган була-булуын, әмма бунт дистриктның җир белән тигезләнүе белән тәгалләнә, һәм бу датаны искә алып, Капитолий ел саен тантаналы рәвештә «Голодные игры» турниры үткәрә. Шартлары бик гади: һәр дистрикттан Урак өсте церемониясендә бер малай белән бер кыз сайлап алына һәм алар Уенга юллана, ә Уен үзе реалити-шоу буларак Панем буенча турыдан-туры режимда трансляцияләнә. Һәм менә чираттагы Урак өстендә, кече сеңлесен Уеннан аралап калу өчен, үз теләге белән катнашырга алынган Китнисс Эвердинның өч томга сузылачак маҗаралы, данлы көрәш юлы башлана.

Ә хәзер әлеге дә баягы актуальлек турында... Мин безнең заманыбыз гына шундый тынгысыз, башбаштак, дияргә теләмим. Сьюзен Коллинз – бигрәк тә. Бу әсәр – үзенә күрә барлык чорларда булган режимнарга һәм шулай ук һәр режим кысаларында да очрап торган кешелеклелек белән каһарманлыкка бер күзәтү генә. Кемдер «Голодные игры»ны яшүсмерлек омтылышларына җавап бирердәй чираттагы фэнтези дип кенә күзаллыйдыр, бәлки, әмма мин аны никтер йөрәгемә якынрак кабул иттем – киңрәк контекстка тарттырып үлчәп карагангадыр, бәлки. Бу әсәр безне, Җимерү этабын кичеп, Җирне яңадан торгызу этабына чакырмыймы икән?

Һәм, ниһаять, нәтиҗә. Уйлап караганыгыз юкмы, бәлки, безнең уйдырмалар белән дә кемнәрдер идарә итәдер? Шуңа һәркемгә, булганнарына анализ ясап, үз Уйдырмасын булдырырга, һәм үзенә генә кадерле Дөньяда үз Чынбарлыгын төзергә телим Яңа Елда!

ТОРНАЛАР, ТОРНАЛАР!

Рөстәм Галиуллин исеме бүгенге татар әдәби мохитендә яхшы билгеле. Яшь язучылар сафында ул иң талантлы һәм өметле прозаиклардан исәпләнә. Аның дүрт китабы дөнья күрде – татар телендә «Гипнозчы малай» һәм «Юлларда җил ак иде...» проза җыентыклары һәм рус теленә тәрҗемәдә «На дорогах белый ветер» белән Мәскәүдә басылып чыккан «Одиночество» тупланмалары. Хәзерге вакытта Рөстәм Галиуллин Таҗетдин Ялчыгол иҗатына һәм шәхесенә багышланган «Васыять» романын төгәлләп килә. Әдәбият елы уңае белән ТР махсус акча бүлеп биреп, татарның тарихи шәхесләре турында күләмле, эпик әсәрләр иҗат итүне тәэмин иткән иде. Киләчәктә бу роман «Атаклы кешеләр» сериясендә басылып чыгар дип көтелә. Рөстәм Галиуллин – М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында гыйльми сәркатиб булып эшли. Журналның бу санында сезнең игътибарга яшь прозаикның «Торналар, торналар!» хикәясен тәкъдим итәбез.

Автор:
Рөстәм Галиуллин

Авыл кешесе теленә эләкмә... Эләктеңме – беттең! Синнән герой, каһарман ясыйлар. Ничек атлавыңа, нәрсә сөйләвеңә, ниләр кылуыңа карап, гомерлек кушамат та чәпәп куялар. И баста! Балаларыңа, оныкларыңа синнән иң зур «бүләк» бу.

Авыл кешесенең теле баллы, тәмле дә, шул ук вакытта үтеңне сытарлык ачы да. Син теләсә кайсы шәһәргә бар, кап-кара кәчтүм-чалбар, ак күлмәк киеп, муенчак тагып, иң югары дәрәҗәле кешеләр янында йөр, үзең турында «мин тегеләй, мин болай» дип мактанып сөйлә. Сиңа ышанырга мөмкиннәр. Тик авылга кайтып кына бу сүзләреңне сөйләмә! Юк инде, булмаганны! Иң шәп машиналарда йөр, ялтыравыклы портфель тотып кайт, әмма авыл агае өчен син барыбер кайчандыр борыныңнан сагызлар агызып, ертык чалбарыңның төбенә хәтле пычракка буялып, урамда уйнап йөргән Госманмы, Гомәрме малае. Кайчандыр, бакча баскандамы, әллә башка берәр этлек кылгандамы, ул агайларга эләгеп, каешының тәмен татыганың, кычыткан өтәләвен кичергән булуың бар. Юк инде, агайне! Синең кәкре аякларыңны көч-хәл белән чалыштырып атлап, әнкәңнең кулына чатырдап ябышып беренче тапкыр урамга чыккан көннәреңне, тавыкмы-әтәчме күргәч, куркудан чалбар төбен юешләтеп, шар ярып кычкырып елап җибәргәнеңне дә хәтерлиләр авылда.

...Авылда төрле кеше яши. Картлар яки яшьләргә генә бүленми ул. Бар эшчәне, бар ялкавы, бар шаяны, бар үз эченә бикләнеп йөргәне... Шул ук вакытта дөньяга нигә килгәнен белмәгәннәрне дә сыендыра авыл. Бигрәк тә бүгенгесе – яшьләре – бер-бер артлы читкә таралышкан, ятим калып барган авыл.

Декабрьнең чатнама суыгында «Торналар килгән!» дигән хәбәр таралды. Әллә дистәгә якын килгән диме шунда? Җыйнаулашып, сыерлар фермасы янында тезелешеп торалар, ди.

Нәрсә уйладыгыз? Озын томшыклы, озын муенлы, нечкә, озын аяклы саз кошлары турындамы? Ялгышасыз. Каяндыр авылга качакмы, йортсызмы гаилә килеп төшкән – алга таба анысына авылның «яңалык белешмәсе» ачыклык кертер – колхозга эшкә кермәкчеләр икән. Сәгать уздымы-юкмы, «торналар» дигән хәбәр һәр йортны йөреп чыкты. Кем беренче күргән аларны, кем беренче «торналар» дип әйткән – билгесез. Авыл өчен ул мөһим түгел. Шулай, агайне... авыл кешесе теленә эләкмә син.

Кызык гаилә иде бу. Өтек кенә сакал-мыеклы, озын чәчле ир, аннан нәп-нәкъ ике башка озынрак хатын һәм... бер оя бала... Хикмәт анда түгел, хикмәт авыл кешесенең тапкырлыгында. Һәммәсе ярты йөзне каплаган озын, нечкә борынлы, һәммәсе озын сыйраклы – чынлап та, болар торналарны хәтерләтә иде. Көлке түгел бу!

Торна тек торна, аптырыйсы юк. «Аю», «бүре», «күсе» һәм башкалар белән шыплап тулган авылга «торналар» өстәлү – катлаулы мәшәкать түгел.

Тик бу санап чыгарып булмастай гаиләнең яшәү рәвеше сәер иде. Фермада тирес түгеп кенә шуның хәтле гаиләне асрап булмаслыгы балалар бакчасындагы иң тыңлаусыз ташбашка да мәгълүм ләбаса.

Ярар, агайне, синең белән минем тамак түгел, болар да яшәп китте. Ара-тирә авылда «торналар»ның куллары «кыеграк» икән дигән хәбәрләр йөрсә дә, аларны каравыклык юлында тотучы, күрүче булмады.

Берзаман авылда «ана торна» кияүгә чыга икән» дигән хәбәр таралды. Кояшның урамдагы кар көртләрен эретеп, инде боз кантарлары белән «көрәшә» башлаган мәле – апрель ае иде бу. Яшь-җилкенчәк урынында тыныч кына басып тора алмаган вакытлар «ана торна»га да тәэсир иткән – күрше авылга «кияүгә» китеп барган.

– Кит инде, юкны сөйләмә, ничек алай булсын?

– Ире, балалары ни әйтә?

– Бөтенләйгә аерылып китте микәнни?

– Абау, абау, гомердә ишетмәгән-күрмәгән хәл...

Авыл аптыраштa калды. Яңалыкны иң беренче ишетүче гайбәтчеләрнең бу билгесезлектән тел очлары янды, көйде. Озак түзә алмадылар, күрше авыл белән «элемтәгә» кереп, мәсьәләне ачыкладылар. Чын икән – бер ир белән яшәп ята икән! Авылга һәр яңа көн яңа хәбәр алып килде.

– Үләм, Алла сакласын, Ходай каргышыннан да курыкмый микәнни, оятсыз? – диеште әби-чәби.

– Булса булыр икән Җир йөзендә ирләргә туялмаган берәү! – дип шаулады хатын-кыз.

– Теге ир нәрсәсенә кызыкты икән аның? – дип аптырашты ир-ат.

Кыскасы, «ана торна» авылда юк – ул кияүгә чыкты. Аңа карап гаиләдә үзгәреш сизелмәде. Ире һаман да сакал-мыеклы, озын чәчле, һәркөн иртән туры атлап эшкә бара, аякларын чабулап-сөртенгәләп кичен өенә кайта.

Беркөнне авыл шау-гөр килде. Җиләкләр пешеп, яшелчәләр дә берсен берсе узып өлгерә башлаган чаклар иде бу – «ана торна» кияүдән кайтып төште. Кайтты да, берни булмагандай, көн саен фермага эшкә йөри башлады. Аптырарлык берни юк. Ләкин авылга бер атна сөйләрлек яңалык «бүләк» итте.

Җәй көне күл буйларына барасызмы? Тыныч вакытта, кеше югында килеп чыксагыз, анда су, саз кошы – торналарны очратырсыз. Тыныч кына су янында йөргән бу кошлар җәйгә үзенә бер ямь өсти... Матур торналары белән күңелле җәй айлары узып бара, инде алмаларның иртә өлгерә торганнарына тәм керә башлаган иде – «ана торна» янә кияүгә китте. Монысында шактый еракка – район үзәгенә үк китеп барган. Бу хәбәр авылның һәр капкасына кагылып узды. Узды гынамы соң?! Һәр йортта аңа бер бизәк өстәлде.

...Сентябрь аеруча моңсу була. Кич җитеп, караңгы төшкәч, җәйнең соңгы җылы җиле белән көзнең хәрәкәтчән, астыртын җиле бергә кушылып, саргая башлаган бәрәңге сабакларының үзенчә бер хуш исен авыл урамнарына, басу-кырларга таратып йөргәндә, бигрәк тә күңелгә бушлык тула. Нәрсәдән бу? Аны кем белсен?!

Авыл моңсулыгын тагын да арттырып, бер-бер артлы кошлар җылы якларга китә. Кинәт тынлыкны бүлеп:

– Тор-рыйк! Торр-рыйк! – дигән тавышлар ишетелә. Чү, торналар түгелме соң бу? Шулар шул, икенче елга әйләнеп кайтырга дип авыл белән, төн үткәргән урманлыклары, көн уздырган күл буйлары белән саубуллашулары икән.

Шулвакыт авылга керүче юлдан ниндидер таныш гәүдәнең якынлашканы күренде. Кем беренче күргән аны, кем беренче таныган – анысы билгесез. Мөһим дә түгел. Тик төсен аерып булмаган зур чүпрәк сумкасын җилкәсенә салып, ашыгып атлап, авылга кайтып килүче «ана торна» иде...

– Теге азгын кайткан. Ничек Ходай бу якты дөньяларда яшәтә шуны?! – диеште әби-чәби.

– Төрләндереп кайткан, – дип шаулады хатын-кыз.

– Кайсы ахмагында «кияүдә» булды икән, – дип кызыксынды ир-ат.

Кеше күңелен аңламассың...

* * *

– Тор-рыйк, Торр-рыйк! – соңгы торналарның да тавышы ерагайды... «Торналар да китте...» – дип куйды кайсыдыр, уфтанып. «Ялгышасың, агайне, кайтты бит «торна», кайтты!» – дип төзәтте кемдер.

Авыл кешесе теленә эләкмә...

Иллюстрация: Александр Алёшин



НАЗЛЫ КИЯҮ

Яшь, буйдак Рәшитнең өйләнергә йөрү хәбәрен ишеткәч, бай кияүгә кәләш сайлап, аны башлы-күзле итәргә теләүчеләр саны шундук күбәеп китә. Һәм «яңа дусларның» мәкерле планы инде тормышка ашам, дигәндә генә, көтелмәгән бер сәбәп аркасында, бар да чәлпәрәмә килә. Чөнки әлеге явыз ниятләргә каршы торучы төп көч – чын мәхәббәт.

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТДДКТ
ТЕЛ.: 8 (843) 238-56-17



КҮРӘСЕМ КИЛГӘН ИДЕ

Ир белән хатын, үз балалары булмаганга, ятимнәр йортыннан уллыкка бала ала. Бу адым барысының да күңеленә хуш килә: әби-бабай да, туганнар да яңа гаилә әгъзасы пәйда булганга сөенеп бетә алмыйлар. Бала йортка куаныч, бәхет китерә. Ләкин Алмаз, үсеп җиткәч, очраклы рәвештә үзенең балалар йортыннан алынганын ишетә. Һәм ул тудырган әти-әнисен күрү теләге белән яна башлый… Тапкан анамы, әллә төн йокыларын калдырып бакканымы?

Спектакльне карагач, әлеге сорауга җавапны һәркем үзе табар.

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТДДКТ
ТЕЛ.: 8 (843) 238-56-17



«УТ КҮРШЕЛӘР»

Җәй җитү белән шәһәр халкының күбесе бакчаларына ашыга. Ял итәргә вакыты юк безнең халыкның. Җитмәсә, менә соңгы араларда көрәк, тырма, чиләк һ. б. эш кораллары эзсез югала башлый. Бу бакчачыларны бик борчый. Аларның төп максатлары – каракны тоту. Маҗараларга бай вакыйгалар аркасында геройларыбыз мәхәббәтләрен югалтып яңадан табарга да, урта яшь кризисын кичереп, аны уңышлы җиңеп чыгарга да өлгерәләр.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТДАТ
ТЕЛ.: (843) 293-03-74



ТИҢДӘШСЕЗ ИСПАНЛЫ ТАРИХЫ

Француз драматургы Жан-Батист Мольерның «Дон Жуан» комедиясе Качалов театры сәхнәсендә беренче мәртәбә куела. Режиссёр-куючы Григорий Дитятковский киңлеккә шартлылык керткән, ачыктан-ачык театраль алымнар кулланган, шул рәвешчә, әсәрдә сурәтләнгән сәхифәне вакыт һәм көнкүреш кысаларыннан читкә чыгарган. Тамашачы Дон Жуан һәм аның ялчысы Сганарельнең бәхәсенә яки уенына кереп чума. Эчкерлелек белән икейөзлелекнең, хакыйкать белән әхлакның ни-нәрсә икәнлеге риторик сорау булып кала.

КАЧАЛОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕАТР
ТЕЛ.: (843) 292-34-83



ДӨНЬЯ КИНОСЫНЫҢ ГҮЗӘЛ ӘСӘРЕ. ӘЙЛӘНЕП КАЙТУ

Бүгенге киноиндустриянең соңгы тренды – классикага әверелгән фильмнарны реставрацияләп яңадан чыгару. «Мир» кинотеатры, яңа сезоннан башлап, һәр айда кунакларын танылган һәм һәрчак көнүзәк булып кала биргән картиналар, дөнья кинематографының гүзәл әсәрләре белән сөендерәчәк. Гыйнварда зур экранда «Завтрак у Тиффани» һәм «В джазе только девушки» кинотасмаларын карап, хозурланып булачак.

КИНОТЕАТР «МИР»
ТЕЛ.: (843) 238-25-24



НӘНИ ЧЫРШЫНЫҢ НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ

Яңа ел – бөтен кешенең озак көтеп алган һәм иң яраткан бәйрәме. Һәр гаиләдә өй эчен бизиләр, купшы чыршы куялар, мул табын коралар, бүләкләр әзерлиләр. Әлеге гореф-гадәтнең чишмә башы кайдан соң? «Кышкы бәйрәмнәр традицияләре» күргәзмәсе төрки халыкларның һәм славяннарның борынгы бәйрәмнәре турында сөйли. Күрәзәлек итү йоласы кирәк-яраклары: борынгы көзгеләр, яктырткычлар, балдаклар һәм итекләр, шулай ук совет чорындагы һәм инкыйлабка чаклы дәвердәге фатирларның эчке күренешләре һ.б. күп нәрсәләр күргәзмәгә куелган.

ТР МИЛЛИ МУЗЕЕ
ТЕЛ.: (843) 292-89-84



REPEAT ФОРМАТЫНДАГЫ КҮРГӘЗМӘ*

Мәскәү рәссамнары төркеменең «Фильмны кабатлап күрсәтү кинотеатры» күргәзмәсе беренче мәртәбә алтынчы Мәскәү заманча сәнгать биенналы кысаларында күрсәтелгән иде. Аның авторларын совет заманы үткәне турындагы уртак хәтергә бәйле тирән шәхси иҗади хезмәт берләштерә, ә ул исә үзенең күзгә күренерлек чагылышын «милләтнең коллектив аңсызлыгы» буларак, кино архивында тапкан.

«АЛМАШ» ЗАМАНА СӘНГАТЕ ҮЗӘГЕ
ТЕЛ.: (843) 249-50-23

* Repite – кабатлау (ингл.).



ҖАНКИСӘККӘЕМ

Әгәр үткән гасырда мәкерле урман иясе Шүрәле ялгыз юлчыларны өркеткән булса, бүгенге көндә бөтенесе дә киресенчә: яшь һәм иреклеләр урманга (туган якның табигый мохитенә дип укы) куркыныч тудыручыларга әверелә. Ә беркатлы табигать баласы Шүрәле замана цивилизациясе вәкилләре каршында яклаучысыз кала. Камал исемендәге театрның зур сәхнәсенә куйган спектаклендә Фәрит Бикчәнтәев күп еллардан бирле халык арасында танылган сюжетны искиткеч шәп итеп яңача аңлатып биргән.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТДАТ
ТЕЛ.: (843) 293-03-74



МУЗЫКАЛЬ МИРАС ХӘЗИНӘСЕ

ТРның Дәүләт симфоник оркестры Казанда беренче мәртәбә Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» Татар музыкасы фестивален үткәрәчәк. Фестивальгә нигез салучы һәм сәнгать җитәкчесе – маэстро Александр Сладковский. Музыкаль форум Татарстанның искиткеч бай музыкаль мирасын: классик һәм бүгенге көндә иҗат итүче композиторларның кабатланмас милли рух белән сугарылган әсәрләрен тәкъдим итәчәк.

С.СӘЙДӘШЕВ ИС. ДЗКЗ
ТЕЛ.: (843) 236-72-72



КАНАДАДАН ПОСТ-ГРАНЖ

Канаданың ThreeDaysGrace төркемен ягымлы хард-рок катыш дәртле пост-гранж һәм альтернативалары башкалардан аерып тора. Иҗатларына мөкиббән китүчеләр аны көчле гитара рифлары һәм истә кала торган хәрәкәтчән вокалы өчен үз итә. Җырлары зур шәһәрдә яшәүче кешенең ялгызлыгы, якынлык һәм үз эчеңә кереп бикләнү, ирек һәм үз-үзеңне күрсәтү турында. Бу коллективның Россиядә икенче гастроль туры һәм шулай ук Казанда икенче чыгышы, бу юлы Eastern Europeantour 2016 кысаларында.

«ЭРМИТАЖ» КОНЦЕРТ-ХОЛЛЫ
ТЕЛ.: (843) 526-56-26



БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАЛАРЫ ЯРМИНКӘСЕ

«Мәгариф. Карьера» махсуслашкан күргәзмәсендә югары, урта, башлангыч һөнәри белем бирүче уку йортларының, шулай ук гомумбелем мәктәпләренең һәм мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең иң яхшы тәкъдимнәре күрсәтеләчәк. Студентлар өчен чит илдә укуның төрле мөмкинлекләре, белем күтәрү программалары, эш бирүчеләрдән турыдан-туры вакансияләр һ.б. Шулай ук биредә компьютер технологияләре өлкәсенә бәйле казанышлар, мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учакларына тәгаенләнгән өр-яңа җиһазлар һәм мебель күрсәтеләчәк.

«КАЗАН ЯРМИНКӘСЕ» ЯҮ
EXPOKAZAN.RU



КАЗАН РАТУШАСЫНДА ДЖАЗ

Hotelde Ville музыкаль фестиваленең чираттагы концертында Мариам Мерабова һәм Miraif джаз коллективы чыгыш ясаячак. «Беренче канал»да барган «Голос» телевизион проектында ясаган бик күркәм чыгышы белән Мариам күпләргә таныш инде. Гашыйклар көнендә музыкантлар махсус программа күрсәтәчәк, ә аңа шул исәптән джазның үзенчәлекле интерпретациясендәге мәхәббәт җырлары да җырланачак. Башкаручылар тамашачыларны кайчандыр Шаляпин һәм Рахманинов чыгыш ясаган кабатланмас акустикалы зиннәтле залда тәэсирләндерәчәк.

КАЗАН РАТУШАСЫ
ТЕЛ.: (843) 236-61-25



ТАТАРСТАН-2016

ҮЗГӘРЕШЛӘР ӨЧЬЕЛЛЫГЫНДА

Лариса Усманова, Россия дәүләт гуманитар университетының «Философия Востока» УНЦ доценты, трансперсональ психолог, социология докторы (PhD, Япония), Татарстанны 2016 елда ниләр көтүе турында.

Республика көнен без 30 августта билгеләп үтәбез, чөнки 1990 елның шушы көнендә ТР суверенитеты турында Декларация кабул ителде. Шушы дата Татарстанның яңа тормышында исәп ноктасы булып тора.

ФИНАНСЛАР – СОЦИАЛЬ ИХТЫЯҖЛАРГА

2016–2017 еллар финанс тотрыклылыгы күзлегеннән караганда катлаулы булачак. Социаль ихтыяҗларга акча җитәр, дип ышандырырга мөмкин, әмма амбициоз һәм яңа проектларны тормышка ашыруга – ай-һай. Шуңа да карамастан, Татарстанда актив халыкара контактлар дәвам итәчәк. Аларның нәтиҗәләрен 2017 ел ахырында һәм 2018 елда көтәргә кирәк булачак.

ОКТЯБРЬ АЕННАН ТАТАРСТАН БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУ КАБЫНЫП КИТӘ

Төбәкнең туристларны җәлеп итүчәнлеге керемнең җитди маддәсенә әверелә. 2016 елның октябреннән Казан һәм Татарстан белән кызыксынуның кабынуы күзәтеләчәк. Транспорт төеннәре һәм чишелешләренең, тимер юлның үсеше дәвам итәчәк.

КОЯШ ТОТЫЛГАНДА – ҺӘРВАКЫТ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Узган елдагы кебек үк, җитәкчелек алышыну вазгыяте саклана. Һәм ул Россия сәяси олимпында булырга мөмкин үзгәрешләргә бәйле. Үзгәрешләр булырга мөмкин вакыт – марттагы кояш тотылулар (9 һәм 23 март арасы) чоры һәм сентябрь ае. ТР Президентының йолдызнамәсе 9 марттагы кояш тотылу белән позитив яраша. Аның тирәсендәге үзгәрешләр бик җитди булырга мөмкин.

САТУРН ҺӘМ НЕПТУННАН НЕФТЬ СӘЛАМЕ

Гомумән алганда, россиялеләр өчен ел катлаулы, үзгәрешләр өчьеллыгы 2014 елдан 2016 елга кадәр (бу елны тулысынча кертеп) дәвам итә. Нефтькә бәяләр ел ахырынача күтәрелмәячәк (Сатурнның Нептун белән катлаулы квадратурасы саклана, һәм ул бөтен 20нче гасыр дәвамында, җитештерүне үзгәртеп корулар һәм бәяләр төшүгә бәйле рәвештә, нефть базарына кризис вакытларын китереп торды). Ил нефть энәсендә утырганлыктан, 2016 ел – аннан төшү һәм эчке тормышны һәм икътисадны үзгәртеп кору белән шөгыльләнүгә керешер өчен яхшы вакыт.

ҮЗГӘРТЕП КОРУЛАР ВАКЫТЫ

Бюджеттагылар өчен – катлаулы чор. Кече һәм урта бизнес өчен – өметләндерә торган. Үзгәртеп корулар вакыты җитте, һәм ул үзгәрешләрне элиталар үзләре ясарга тиеш. Җитди социаль чуалышлар булу мөмкинлеге бик түбән, «шөрепләрне катырак борган» очракта гына. Сәяси үзгәрешләр мөмкинлеге югары. Эшчәнлек активлыгы өчен гыйнвар ахырыннан башлап, апрель уртасына кадәрге вакыт яхшы.

ЕЛНЫҢ БОРЫЛЫШЛЫ ВАКЫЙГАЛАРЫ

Апрель уртасыннан башлап 1 июльгә кадәр техник чаралар һәм автомобильләр сатып алырга киңәш ителми. Бу – югары агрессия вакыты, ярсу-дулкынланулар чоры. Нәкъ шушы чорда һәм кояш тотылган вакытларда елның төп борылыш вакыйгалары булачак.

ИЮЛЬДӘН СОҢ ТЫНЫЧРАК БУЛА


Июльдән күчемсез милек һәм төзелеш базары җанланып китә. Елның икенче яртысы, беренчесе белән чагыштырганда, күпкә йомшаграк һәм тынычрак. Үзегезне һәм якыннарыгызны саклагыз!

2016
С Новым годом!
Пусть волшебные новогодние дни согреют Ваш семейный очаг теплом и любовью Ваших сердец.
KZN
КАЗАНЬ
ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯ
Реклама










ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАННЫ» УКЫ!